Безнең МИРАС

08

август 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

31 июль-1 августта Казанда Евразия илләренең җирле хакимият җитәкчеләре конгрессы узды. Россия, Казакъстан, Кыргызстан, Әрмәнстан, Молдавия, Монголия, Таҗикстан, Украина кебек чит илләрдән 100дән артык шәһәр башлыгы Евразия илләрен дөньякүләм үсешкә ирештерү өчен үз тәкъдимнәрен җиткерде.

М. Фролов фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
05(43)
август 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.



10



56 **АККА КАРА ТӨШСӘ, ЮГАЛМЫЙ…**
(Муса Җәлилнең яңа шигырьләре табылу тарихы)
Рәзин Нуруллин

94 **ШӨГЕР ЯГЫ — КАРА АЛТЫН ИЛЕ**
Гәрәй Рәхим

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Татар уены.** *Туфан Миңнуллин*

ТАТАР ГАМЕ

4 **«Халык рухы сүнмәсен!»** ***(Түгәрәк өстәл)***
18 **Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел**

ТАРИХИ МИРАС

24 **Болгар. Тарихи белешмә.** *Нурсөя Шәйдуллина*
27 **Яңа Смәил мулласы.** *Ләлә Мортазина, Илнур Газизуллин*
37 **Милли вә мөһим мәсьәлә.** *Габделкаюм Баһмани*

ХӘТЕР САГЫНДА

41 **Музыкаль коллекция.** *Гүзәлия Җәләлева*

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

42 **Германиядә татар телендәге беренче басма текст.** *Себастьян Цвиклински*

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

47 **Сибгат ага җырлый…** *Алмаз Хәмзин*

ӘДӘБИ МИРАС

48 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
53 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
55 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*
56 **Акка кара төшсә, югалмый…** *Рәзин Нуруллин*
60 **Муса Җәлилнең яңа табылган шигырьләре**
62 **Фатих Кәрими сәяхәтнамәләрендә публицистик катлам.** *Рифә Харрасова*
68 **Солдат йөрәге.** *Зариф Мөэминов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

90 **«Милли театр үлсә, тел дә бетә»**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ТАБИГЫЙ МИРАС

97 **Шөгер ягы — Кара Алтын иле.** *Гәрәй Рәхим*
100 **Иделнең борынгы үзәнлеге.** *Николай Петров*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

104 **«Ташны баш белән ярып үз юлын алдылар...»** *Нәкый Исәнбәт*
106 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **Сүз һәм сурәт.** *Әгъзам Фәйзрахманов*

КАЙТАВАЗ...

110 **Бер «ләкин»...**

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ...

111 **Нәни гигант Галимҗан.** *Атлас Гафиятов*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның август ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...** *Туфан Миңнуллин*

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Август*

Заказ №О-2124. Тираж — 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 05.08.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Абай». 1982 ел. *Б.Урманче рәсеме.*

Туфан МИҢНУЛЛИН
(1935-2012)

ТАТАР УЕНЫ

(Җылый-җылый уйнала)

Без, без, без идек,
Без күп миллион идек,
Дәүләт кордык — тоталмадык,
Сәүдә кылдык — оталмадык,
Сибелдек тәаралдык,
«Поганый»га саналдык.
Болгар, диеп даулаштык,
Мишәр, диеп шаулаштык.
Себер, дидек — саташтык,
Типтәр, дидек — адаштык.
Керәшен, дип карыштык,
Карыштык та талаштык,
Бүтәннәргә яраштык,
Яраштык та сытылдык,
Йөзләп-меңләп йотылдык,
Түрә булып сатылдык.
Денсез калдык, тәмам аздык,
Аздык-туздык, телдән яздык.
Марҗа күрдек — котырдык.
Галим булдык — чукындык.
Ак чук, кара чук —
Татар кызы — татарчук,
Хап та хуп,
Җитте Якуп,
Авызыңны ач та йом.

«ХАЛЫК РУХЫ СҮНМӘСЕН!»

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ

15 июльдә «Безнең мирас» журналы редакциясе Татарстанның яңа дәүләтчелек тарихына багышланган «түгәрәк өстәл» оештырды. Чарада Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, КФУ профессоры Индус Таһиров, сәясәт белгече Фәндәс Сафиуллин, Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе мөхбир әгъзасы, профессор Азат Зыятдинов, «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева, шагыйрь Газинур Морат катнашты. «Түгәрәк өстәл»не «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон алып барды.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Мөхтәрәм кунаклар, хөрмәтле каләмдәшләр!

Моннан 25 ел элек беренче тапкыр альтернатив нигездә XII чакырылыш Татарстан Югары Советы депутатлары сайланды, соңрак Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул иттек. Безнең арабызда Парламентның бу чакырылышында депутат булган һәм Декларацияне кабул итүдә актив катнашкан милләтпәрвәрләребез утыра.

Сиксәненче еллар ахыры-туксанынчы еллар башында милләтебез чын мәгънәсендә йокыдан уянды. «Ирек», «Азатлык», «Бәйсезлек», «Мөстәкыйльлек» дигән сүзләр еш-рак яңгырый башлады. Әүвәл кулуарларда гына ишетелгәләгән ул сүзләр тора-бара ялкынлы чыгышлар, үтемле нотыклар булып мәйданнарга чыкты. Милләтебезнең, халкыбызның киләчәге өчен чын күңелдән борчылучы фидакярләр гавам арасыннан трибунага күтәрелде. Татарстанның мөстәкыйль дәүләт булуын таләп итеп, бер төркем каһарман милләттәшебез хәтта ачлык игълан итүгә кадәр барып җитте.

Чыннан да, халкыбыз иреккә сусаган иде. Казанда гына түгел, Түбән Кама һәм Чаллы, Әлмәт белән Азнакайда Татар иҗтимагый үзәкләре оешты, аларның күп санлы әгъзалары актив эшчәнлек күрсәтә башлады. Халык таләбен күренекле сәясәтчеләребез, милләтебез хәлен тирәнтен аңлаган депутатларыбыз (алар арасында күренекле язучыларыбыз да бар!) күтәреп алды.

Телен югалта язган милләткә кабат җан кергәндәй тоелды...

Индус ТАҺИРОВ:

— Мин бу елларны «данлыклы еллар» дип атар идем. Аның һәр минуты, һәр сәгате гасырны сыйдырган. Кайбер мизгеле бүгенгә кадәр үзен күрсәтеп, ялтырап тора. Мәсәлән, Декларациябез. Күпләр үз декларациясен безгә ияреп кабул итте. Вәләкин безнеке бөтенләй башка документ, чөнки ул Бәйсезлек Декларациясе. Аны төзегән вакытта без мөстәкыйль дәүләт оештыруны, Россия белән махсус мөнәсәбәтләрдә булуны һәм яңартылган СССР шартнамәсенә мөстәкыйль рәвештә кул куюны максат итеп куйдык. Бу — Татарстанның махсус позициясе дип аталды. Без Россиянең бөтенлеген саклау шарты белән үз бәйсезлегебезне игълан иттек. Мондый нәрсә — тарихта булмаган хәл. Соңрак аны халыкара документ итеп таныдылар. Косовоның суверенлыгын тикшерүчеләр өстәленә дә безнең Шартнамә куелган иде.

Ни өчен Бәйсезлек Декларациясе дип атыйм мин аны? Чөнки ул бәхәс тудырды. Сез үзегезне СССРда таныйсызмы? Юк, СССРда икәнне күрсәтә алмыйбыз, чөнки безнең әле мөстәкыйль рәвештә (союздаш республика сыйфатында, ягъни турыдан-туры) моны танып кул куйганыбыз юк. Ә Россия? Россия составында икәнлегебезне декларациядә күрсәтмәскә! Аның белән без махсус мөнәсәбәтләрдә булырга тиеш. Шулай эшләдек тә. Әгәр дә без булачак шартнамәгә Россия составында икәнлегебезне танып кул куйсак, суверен дәүләтле булмый идек.

Декларациянең берничә варианты бар иде. Шушы вариантларны берләштереп сессиягә чыгару — төп бурыч. Сессия 27 августта башлан-

ды, 30ына кадәр дәвам итте. Шушы көннәрдә Декларациянең язмышы хәл ителде дә инде. Минтимер Шәрип улы Шәймиев сессиянең һәм шул ук вакытта килештерү комиссиясенең дә рәисе булды. Комиссия составында 29 кеше идек. Без бернинди бәхәссез Декларациянең атамасыннан «Татарская Советская Социалистическая Республика»ны алып аттык, «Республика Татарстан» гына калды. Тәнәфестә М.Шәймиев: «Сез бу сүзләрне кая куйдыгыз?» — дип сорады. Без дөресен әйттек. Ул: «Сез Декларацияне кабул итәсез дә кайтып китәсез. Ә минем иртәгә Мәскәүгә барасым, җавап тотасым бар. Вакыты җиткәч, ул сүзләр үзеннән-үзе төшеп калачак», — диде. Шулай булды да.

Депутатларның «Народовластие» төркеме Татарстанны Россия составында танымавыбызга каршы чыкты. **Декларациядә дәүләт теле бер — татар теле генә күрсәтелгән иде. Бәйсез дәүләт икән, аның дәүләт теле бер булырга тиеш!** Тегеләр моңа да катгый рәвештә риза түгел. Без аларга: «Әйдәгез, алайса, сез җөмһүриятебезне Россия составында итеп күрсәтмәүгә ризалашасыз, ә без икетеллелекне кертәбез», — дидек. Алар килеште. Шунда ТИҮ активисты Гаял Мортазин, көрсенеп: «Их, егетләр, саттык без телебезне!» — диде. Бер телле генә булсак, әлбәттә, вазгыять бөтенләй башкача булыр иде. Менә шушы рәвештә Декларацияне кабул иттек. Декларацияне уку, аны сессиядә яңгырату Фәндәс Сафиуллинга тапшырылды.

Фәндәс САФИУЛЛИН:

— Хәзер Татарстанның бәйсезлеге турындагы Декларациянең статусы бетте, бернәрсә дә барып чыкмады, дип бәяләргә тырышалар. Мин алай дип уйламыйм. **Безнең ул чорда кабул ителгән Декларация дә, Референдум да, Конституция дә алга таба үзенең әһәмиятен күрсәтәчәк әле! Киләчәктә яңарыш булган чакта, ул шулар өчен зур әхлакый, сәяси, фәнни, тарихи нигез булачак. Яшьләр дә шуңа таянып көрәшәчәкләр. Декларация — милләтнең аңына, хәтеренә сеңеп калачак һәм кайчан да булса халык янәдән уяначак.** Мин монысына ышанам.

Безгә союздаш республика буларак үсү кирәк булды. Бу СССР исән булганда гына мөмкин иде. Әмма СССР юкка чыкты. Шунлыктан суверенлыгыбызның да күп өлешен югалттык. Ул безнең генә гаеп түгел. Төп сәбәп — СССРның җимерелүе. Без аның составында союздаш республика булырга тиеш идек. Безгә әлеге макстака ирешергә өч көн җитмәде. Яңа Союздашлык шартнамәсенә кул куярга өлгерә алмый калдык, ГКЧП килеп чыкты.

Татарстан сайлаган юл, Татарстан сайлаган язмыш Россия өчен дә, СССР өчен дә дөньяви әһәмияткә ия булачак иде. Әгәр без союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрелеп өлгерә алсак, башкалар да безнең арттан күтәрелер иде. СССР тамырдан үзгәрергә тиеш иде. Тирән реформа үткәреп, илне тигез хокуклы халыклар берлеге итә алган очракта, аның исән калу мөмкинлеге булды. Хәзерге глобализация чорында ул халыклар берләшүенең альтернатив проекты булырга лаеклы иде. Глобализация — кешелекнең табигый рәвештә үсеше: кабиләләрдән — милләт, аннан дәүләтләр, ә аннары исә Җир шарында гомуми бер җәмгыять төзүгә юнәлдерелгән объектив юл. Яңартылган СССР шул юл берәү генә булмасын, бер генә диктат идарә итмәсен өчен кирәк иде. Безнең эш барып чыккан булса, шушы глобаль проектның нигезе буласы иде... Без аны максат итеп куймасак та, ул турыда уйламасак та, хыялланмасак

та шуңа барып җитәчәк идек. Әмма, ни кызганыч, Татарстанның язмышы хәл ителгән көннәрдә СССРны җимереп Россия үз язмышына үзе балта чапты һәм дөнья күләмендә бара торган глобализация процессына бик зур бәла-кайгы китерде.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Республикабызның яңа сәяси сулыш алуы, әлбәттә, беренче чиратта Декларациябезгә бәйле. ТАССР белән бүгенге Татарстанның аермасы бик зур. Һәр ике дәвердә табышларыбыз да, югалтуларыбыз да җитәрлек.

Кулымда әле яңа гына матбугатта чыккан кызыклы бер белешмә. Анда болай дип язылган: «95 ел эчендә республикабыз белән барлыгы 23 кеше идарә иткән (сүз партия җитәкчеләре турында бара). Бөек Ватан сугышына кадәр беренче секретарьларның җидесе — урыс, алтысы — яһүд, берсе латыш булган. Араларында бер генә татар да юк...» Ленин бабай әйтмешли, «факт — вещь упрямая!..»

Бүгенге «түгәрәк өстәл»дә без туксанынчы елларда яулап алынган уңышлардан эйфориягә бирелеп, оеп утырырга түгел, ә киләчәгебез ничек булыр, дип үткәннәрдән гыйбрәт алып, алдагы үсеш юнәлешләре турында да сөйләшергә тиешбездер.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Мин туксанынчы елларны тарихи еллар, татар халкының дәүләтчелеккә омтылышында булган берничә тарихи вакыйганың берсе, дип атар идем. XX гасырда гына да шундый өч талпыныш була. Беренче — 1905 ел. Тукайны хәтерлисездер: «Без бишенче елны уяндык таң белән». Татар берничә ел эчендә матди һәм рухи яктан күтәрелә, байый. Бу озакка бармый, тагын сүрелү башлана. 1917-1922 елларда янә зур күтәрелеш. Сталин чорында милли хәрәкәт кабат артка китә, чигенә. Өченче дулкын 1980 елларның урталарында башланды һәм 2000 елларга кадәр дәвам итте, аннары янәдән сүрелү, артка таба чигенү китте...

Без туксанынчы еллардагы милли күтәрелешнең эчендә кайнадык. Ул чордагы вакыйгалар минем бүген дә күз алдымда, хәтта төшләрдә күрәм мин аларны. Декларация кабул иткәндә төрле вариант булды, без дә үзебезнең вариантны эшләгән идек. Мин аны төн буе утырып яздым, Дамир Сираҗиев трибунадан игълан итте. Әмма безнең вариант үтмәде. Дөрес, кайбер өлешләре керде. Тел мәсьәләсенә килгәндә без татар телен — дәүләт теле, урыс телен — рәсми, милләтара аралашу теле, дип язган идек.

Ул чорның дулкыны, аның тәэсире бүген юк, дип әйтсәм, мин намусыма, хакыйкатькә хилафлык китерер идем. Кайвакыт: «Суверенитет сезгә нәрсә бирде инде?» — дип әйтеп куялар. **Бүген безнең нindидер зур уңышларыбыз бар икән, ул туксанынчы еллардагы карарларыбызга, шулвакытта кылган гамәлләребезгә барып тоташа.** Аңа ул вакыттагы вакыйгаларны, тормышны белмәгән һәм чагыштырып карый алмаган кеше генә тискәре бәя бирергә мөмкин. Берничә көн элек «Независимая газета»да Глеб Постнов, гадәттәгечә һәрвакыт татарларга каршы чыга торган автор, «Судороги татарстанского суверенитета» дип исемләнгән мәкалә язды. Ни өчен Татарстан Парламенты өстендә бер генә

байрак тора, ди. Аңа бернәрсә дә ошамый! Татарстан Парламенты өстендә бер генә байрак тора икән, ул аны Россиягә каршы булу, дип аңлатырга тырыша. Анда бер генә байрак торса да, аның тирә-ягында Россия байраклары бик күп. Без бүген Республикабызда РФ кануннарына каршы килгән бер генә карар да кабул итә алмыйбыз. Ул аларны искә алмый. Бигрәк тә безнең соңгы елларда мәгариф өлкәсендә күпме артка чигенешләребез булды. Әлеге автор аның нәрсә аркасында килеп чыкканын искә дә алмый.

Билгеле, ул вакыттагы казанышларыбызны һәм ул казанышларның бүгенге уңай тәэсирен искә алу белән бергә, бик күп урыннарда артка чигенүне дә әйтми булмый. Артка чигенүдә мин кемнедер гаепләргә җыенмыйм. Аның бик күп объектив һәм субъектив сәбәпләре бар. Бу — Россиянең милли сәясәте белән турыдантуры бәйләнгән. Шулай да, үзебездән дә бик күп нәрсә тора. Без бүгенге көндә, ни кызганыч, үзебездән торган бик күп нәрсәләрне эшләп бетерә алмыйбыз. Татарстанда, Казанда мәгариф, мәдәният өлкәсендә булсын, яки башка тармакларда булсын, безнең хокукларыбыз шактый күп. Мин аеруча мәгариф өлкәсенә караган мәсьәләләр белән Дәүләт Думасына бик еш барам, төрле бәхәсләрдә, Парламент тыңлауларында катнашам. Без Мәгариф комитетына килеп керү белән: «О, татары приехали, опять будут с нами воевать!» — диләр. Мин әйтәм: «Һич кенә дә сезнең белән сугышырга килмәдем, мин сездән Россия Конституциясен якларга килдем. Сез Конституцияне бозасыз. БДИын гына алыгыз. Сез аны «урыс телендә генә бирергә мөмкин», дигән карар чыгарып, турыдан-туры Конституциягә каршы килдегез!» Алар әйтә: «Ничек каршы килдек?» Мин: «РФ Конституциясендә теләсә кайсы гражданин үз туган телендә белем алырга хокуклы диелгән. БДИ белем алу түгелме? Ул бит белем алуның

иң җаваплы мизгеле. Сез БДИын мәгарифтән аерып куйдыгыз. Бу турыдан-туры РФ Конституциясенә каршы килә. Ә каршы килгән закон-карарларыгыз сезнең искиткеч күп. Шунысы безне бик нык борчый. Татарстанның бик күп законнарын РФнекенә тәңгәлләштерергә мәҗбүр итәсез. Без аларның шактые белән килешәбез, чыннан да, тәңгәллек кирәктер. Әмма сезнең үзегезнең бик күп законнарыгыз РФ Конституциясенә каршы килә. Безнең юристлар Россиянең 27 кануны Россиянең үз Конституциясенә каршы килгәнен ачыклады. Шул ук вакытта, Татарстан законнарының Россия Конституциясенә тәңгәл килүен даулыйсыз. Моны ничек аңларга? Сез бүгенге хокукый кырда, дәүләт һәм җәмгыять тормышында нинди буталчыклар китереп чыгарасыз!» — дим.

Билгеле, без бүген күсәк күтәреп урамга чыгып, бу мәсьәләләрне хәл итә алмыйбыз. Матбугатта, телевидение, интернет сәхифәләрендә фәнни, кануни нигездә үзебезнең хаклыгыбызны, дөреслегебезне исбат итәбез. Каршы якның моңа бернинди аргументы да юк, чөнки без Халыкара хокук нормалары һәм РФ Конституциясе буенча гамәл кылабыз. Ә Халыкара хокук нормалары һәм Конституция безгә бик күп мөмкинлек бирә! Безнең әле аны тулысынча файдаланып бетерә алганыбыз юк.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Сүз уңаеннан шуны да ассызыклап китәргә кирәк: Декларациябез кабул ителгән бу данлыклы сессиядә 5 язучы-депутат чыгыш ясады — Фәүзия Бәйрәмова, Роберт Миңнуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев һәм мин. Безнең тәэсирле һәм дәлилле чыгышлар әлеге мөһим документны кабул итүдә зур йогынты ясады, дип уйлыйм. Бу чыгышлар язучыларыбыз яшәеше тарихында матур сәхифә булып калды[1].

Индус ТАҺИРОВ. Әгәр дә без Декларацияне кабул иткәнбез икән, моңа төп сәбәпче — безнең халкыбыз булды. Ул вакытта мәйданнар тулы иде. Түбән Кама, Чаллыдан җыелышып киләләр, сессия вакытында Казан кайнап тора. Аннан бигрәк, сессия башланыр алдыннан һәрбер депутатка наказ биреп кертәләр иде. Фәүзия Бәйрәмова, Зәки Зәйнуллиннарның ачлык тотулары... **Халык шушы рәвештә күтәрелмәгән булса, без Декларацияне кабул итә алмас идек тә. Халыкны һич кенә дә онытырга ярамый.** Ике-өч кеше белән генә бу идеяне берничек тә тормышка ашырып булмас иде. Халыкны күтәреп чыгучыларның берсе — Азат Шәймулла улы безнең арабызда утыра.

Азат ЗЫЯТДИНОВ:

— Әлбәттә, ирешелгән уңышлар һәммәсе дә халык казанышы. Казан халкы бик акрн, бик аз уянды. Ә Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләреннән кырыгышар автобус шыгрым тулып Казанга килә иде.

Бик күпләр мөстәкыйль респбулика статусын алды. Казакъстан, Украина, Белоруссия, Эстония, Кыргызстан... Боларның кайсы «Аллага шөкер, без мөстәкыйль дәүләт статусын алдык та куанып яшибез», дип әйтә ала? Кыргызстанда булдым... Аллам сакласын, алай яшәргә язмасын! Төрекмәнстанда да хокук, ирек дигән нәрсә юк. Белоруссиядә система кырыс. Дөрес, тамаклары тук, өсләре бөтен,

[1] Әлеге чыгышлар «Казан утлары» журналының 1990 елгы декабрь санында басылып чыккан.

АТЛЫК

ЛЕНИН
ЕЛ
ТАТАР ХАЛКЫН
КОЛЛЫККА
ДУЧАР ИТТ

АЗАТ

Саулык кирәк, сәламәтлек кирәк,
Барыннан да бигрәк — Азатлык!

Сибгат Хәким

әмма демократиянең «д» хәрефе дә юк. Мин төрки халыклардан казакъларга сокланам. Менә аларга җитәкченең көчлесе эләкте. Назарбаев тулаем Европа стандартларына якынаймакчы була. Бигрәк тә хокук, икътисад өлкәсендә.

Бездә миллилек булса, бар да була. Мин татар миллиардерлары барлыкка килүгә бик куанам. Әмма аларның кайсысы милләткә ярдәм итә?

Разил ВӘЛИЕВ. Берәрсе милли мәктәп яки милли гимназия ачтымы?

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Татарча укыгыз, дип балаларга ниндидер ярдәм күрсәтәме?

Декларация кабул иткәннән соң приватизация үткәрделәр. Мин кырык ел эшләгән Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсенә дә дүрт миллиардер хуҗа булып алды. Алар анда бер көн эшләгән кешеләр түгел!

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә бар. **Кулыбызда булганда без мөстәкыйльлекнең кадерен белмәгәнбез. Ханнар, хан балалары талашкан да сугышкан, барысының да хан буласы килгән…** Инде киләчәктә миллилекне сакларга кирәк. Ул очракта без нәрсәгәдер ирешә алабыз әле. Хокук даулап кына көчле булып булмый. Һәрберебез әрмәннәр, яһүдләр кебек милли рухлы булырга тиеш! Яһүд кайда гына, нинди генә вазифада утырмасын, ул — милли. Ә без түбәтәй кидек тә, менә без нинди, дип йөрибез. Безнең рухыбыз миллилек нигезендә көчле булырга тиеш! Без белемле, һөнәрле һәм үз хокукыбызны белгән горур халык булсак иде!

Разил ВӘЛИЕВ. Сез Кыргызстанны мисал итеп китердегез. Чыннан да, анда тормыш бик авыр. Мин БДБ илләренең күбесендә булдым. Дөрес, аларда демократия юктыр. Әмма ул аларга кайчан да булса килер. Дөрес, икъктисадлары начардыр… Әмма анысын да төзәтергә мөмкин. Аларның бүген үз дәүләтләре бар! **Безнең бүген тамагыбыз да туктыр, әмма милләтебезне бөтенләй югалту куркынычы бар. Аннан да зуррак хәвеф булуы мөмкин түгел.**

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Безнең рухыбыз сүнеп бара. Бөтен бәла дә шунда. Без кайда булсак та миллилекне үзебезнең гаиләдән башларга тиеш. Үз гаиләмә мин үзем хуҗа бит! Әгәр дә балаң татарча сөйләшә белми икән, ул синең дәүләтчелегең өчен берни эшләмәячәк.

Разил ВӘЛИЕВ. Туксанынчы еллардан бирле Татарстанда дәүләт, муниципалитет хезмәткәрләре ике дәүләт телен дә мәҗбүри белергә тиеш, дигән мәсьәләне күтәреп килдек. Татарстанда Президент ике дәүләт телен белергә тиеш бит. Ә ни өчен әле министр, депутат, судья, хакимият башлыклары белергә тиеш түгел? Әгәр дә дәүләт хезмәткәрләре ике телне мәҗбүри рәвештә белергә тиеш, дигән закон кабул итсәк, вазгыять бик нык үзгәрәчәк. Ата-аналар да: «Татар теленең дәрәҗәсе югары икән, ул кирәк икән, үскәч, улым, син дә, бәлки, президент, министр яки дәүләт эшлеклесе булырсың», — дип балаларын тәрбияләр иде. Әмма әлеге законны бүгенге көнгә кадәр кабул иттерә алганыбыз юк.

Индус ТАҺИРОВ. Узган гасырның егерменче елларында кайбер түрәләр менә шушындый закон кабул ителә калса, безгә китәргә туры килер инде, дигәннәр. Чөнки алар татарча белмәгән. Шул вакытта да мондый канунны кабул итәргә өлгермиләр. Ул бүген дә, һичшиксез, кирәкле канун.

Фәндәс САФИУЛЛИН. Мин миллиардерларда миллилек юк, дигән сүз белән бик килешеп бетә алмыйм. Миллилеге булган шәхесләргә баерга юл ачылса, миллилек булыр иде ул! Юл бит миллилеге булмаганнарга ачылды. Ә милли җанлы

кешеләргә эшләргә, хезмәте белән баеп китәргә, иленә, халкына ярдәм итәргә ирек бирелмәде. Киресенчә, суверенитетны үз кесәләре өчен файдаланганнар өчен ирек ачылды.

Икенче мәсьәлә — хәзер халык та сүнде. Халыкны сүндерү бик җиңел! Син аны ярты ел чынбарлыктан, реаль информациядән аерып кына тор. Халык башта аптырый, аннары күнегә, аннары төкерә! Аннан соң чынбарлык аңа кирәк тә булмый башлый! Без инде ничә ел буе халыкның аңын сүндереп киләбез. Аның төп коралы — Татарстанга гомумцензура кертү булды. Цензура, халыкка чынбарлыкны җиткермәү, хәбәрдарлык дигән нәрсәне бетерү нәтиҗәсендә халык сүндерелде. Ни өчен сүндерелде? Саран байларга юл ачу өчен! Шулар иркенләп, баеп йөрсеннәр өчен.

Һәр халык бөек булырга лаеклы һәм аның моңа барлык мөмкинлеге бар. Әгәр халык бөек максат һәм шуңа ирешүне бурыч итеп куя икән, шуны тормышка ашырырга тырыша икән, халык бердәм була. Безнең дә бөек максатлар бар иде. Милли университетны булдыру — иң бөек мәсьәләләрнең берсе булды.

Разил ВӘЛИЕВ. Түбән Кама халкы бер атна эчендә Милли университетны яклап 15 мең имза җыйды.

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Миллионны да җыя идек, тиздән ачабыз, дип вәгъдә биреп туктаттылар.

Индус ТАҺИРОВ. Без телгә алган төрки халыкларга бәйсезлекне Аллаһы Тәгалә сорамаган килеш кулларына тоттырды. Заманында кыргыз, казакълар үзләренә союздаш республика статусы бирелүен белми дә калды. Ә безнекеләр союздаш булу өчен никадәр көрәште! Сталин: «Татарии и Башкирии не видать союзного статуса как своих собственных ушей», — диде.

Казакъстан Республикасы исеменең беренче атамасы — Кыргыз Республикасы, башкаласы Оренбург шәһәрендә булган. Ул халык союздаш статуска ирешкән чагында үз атамасын да белмәгән! Казакъ-

ларны кыргызлар дип йөргәннәр. Ә кыргызларны каракыргызлар дип. Атамаңны да төгәл белмәгән килеш дәүләтле булу — зур бәхет.

Төрки халыклар арасында иң авыр язмышлы милләт — татарлар. Башкортлар Россиягә ирекле рәвештә кердек, дип күп нәрсәгә ирешә алды. Кермәделәр, әлбәттә. Дәүләт тоткан бер генә халыкның да үз теләге белән мөстәкыйльлектән баш тартканын тарих белми. Шулай да, башкортлар зур җирләр хуҗасы булдылар. Ә без җирсез калдык. Татарлар Россиядә, үз ватанында, иң аз җирле халык.

Аның каравы, туксанынчы елларда бердәнбер күтәрелгән халык та шул татар булды! Мондый Декларация бер генә милләттә дә юк. Мәскәү аптырашта калды. Татарстан Союздашлык шартнамәсенә мөстәкыйль рәвештә кул куярга тели…

Без ни өчен союздашлык статусын дәгъваладык соң? Беренчедән, дәүләтле чорыбыз халык хәтереннән сөртелмәгән, исән-имин сакланган булып чыкты. Һәм ул бүген (туксанынчы елларда) уянды. Моны берничек тә инкяр итеп булмый. Икенчедән, без Россияне федерация дип игълан иткән документларга таянып эш итттек[2]. Мәскәү җитәкчеләре аны күптән оныткан булганнар. Күрәселәре дә килмәде. Без Декларациябезнең бер генә законны да бозмавын дәлилләдек. Өченчедән, без Россияне таркату юлында түгел идек. Без аны чын мәгънәсендә халыкларның хокукларын таный торган дәүләт итүне максат итеп куйдык.

Эчке эшләр дә, халыкара мөнәсәбәтләр дә — бар да үзебезнең карамакта булырга тиеш иде. Шуларны саный башлагач, Сергей Шахрай: «Сез Россиядән чыгасызмыни?» — дип сорады. Мин аңа: «Безнең кергәнебез дә юк бит әле», — дидем. Шахрай: «Димәк, Татарстан Россия составына керми дә, аннан чыкмый да», — диде.

Декларацияне кабул иткәч, Минтимер Шәрип улы Шәймиев безне — мине һәм КПСС өлкә комитетының идеология буенча секретаре Р.Р.Идиатуллинны — башкортлар да безнекенә тәңгәл декларация кабул итмәсме икән, дип Башкортстанга җибәрде. Өч көн буе алар белән сөйләшү алып бардык. Ризалаштылар, күнделәр, вәләкин Югары Советлары аркылы үткәрә алмадылар. Республикаларын «Россия Федерациясенең субъекты» дип таныган декларация кабул иттеләр. Шунда Минтимер Шәрип улы: «Их, союзникларсыз калдык бит!» — диде. Мин: «Алар берни дә югалтмады», — дидем. Аның: «Ничек инде?» — дигән соравына: «Алар үз вакытында Россия составына ирекле керүләрен таныдылар, хәзер моны янә кабатладылар гына, — дип җавап кайтардым. — Ә бездә андый документның булганы да юк. Әгәр дә без декларация кабул итеп, үзебезнең Россия составында икәнне күрсәткән булсак, өстәвенә, анда сезнең имзагыз да булса, «Ниһаять, 438 елдан соң Россиягә ирекле керүне таныган татар табылды», дип әйтерләр иде», — дидем. Моны ишеткәч, Минтимер Шәрип улы сискәнеп китте.

Разил ВӘЛИЕВ. Илне бер йодрыкка җыюның төрле ысуллары мәгълүм. Аның берсе — мәҗбүрият, икенчесе — ирек бирү. Конфуцийның бик кызык бер фикере бар: *«Әгәр дә кешене мәҗбүри рәвештә бәйләп тотсаң, аның бу бәйдән качасы килә. Әгәр дә ирек бирсәң, хөрмәтен күрсәтеп, ул синең якыная гына»*. Россияне бердәм, куәтле дәүләт итәргә теләсәләр, һичшиксез, әүвәл халыклар, субъектлар арасында үзара ихтирамлы мөнәсәбәт урнаштыру

[2] Сүз 1918 елда кабул ителгән «Эксплуатацияләнүче халыклар хокуклары декларациясе» турында бара.

мөһим. Әгәр дә кем дә булса мине хөрмәт итми икән, мин, күпме теләсәм дә, үзем дә аны хөрмәт итә алмыйм. Бу бит халык белән дәүләт арасында да шулай. **Әгәр дә дәүләт халыкны ихтирам итми икән, халык та дәүләтне ихтирам итми.** Димәк, бу дәүләт ныгып, берләшкән дәүләткә әверелә алмый. Шуңа күрә татар халкына да (Россиядәге башка халыкларга да) ихтирам белән карарга кирәк. Әгәр дә татар халкы мәңгегә бу илдә булырга тели икән, аның теленә дә, гореф-гадәтләренә дә, тарихына да ихтирам булырга тиеш.

Индус ТАҺИРОВ. 1991 елның 19 августында Минтимер Шәймиев белән Борис Ельцин очрашып, бер елга якын барган ике яклы сөйләшүләргә нокта куярга тиеш иде. Кабатлап әйтәм: союздаш республика булу өчен безгә өч көн җитмәде! Ул вакытта безнең җитәкчеләребез үткен пычак өстеннән йөрде. Генерал Макашовның 150 кешелек спецназы танклар белән урамга чыгарга әзер иде. Шушы авыр көннәрдә безнекеләр һич кенә дә бирешмәде. Халык: **«Камыр булма, Минтимер!»** — дигән лозунглар күтәреп чыкты.

Разил ВӘЛИЕВ. 1990 елның 27-30 августында иң зур бәхәс Татарстанның сәяси статусы турында барды. Икенчесе — мөлкәт, өченчесе — тел турында. Безнең ул вакыттагы таләпләребез катгый иде.

Индус ТАҺИРОВ. Без 1992 елның август аенда Василий Лихачёв белән янәдән Мәскәүгә килдек. Безне Казан вокзалында хөрмәтләп каршы алдылар. Кремльдә Г.Э.Бурбулис һәм В.А.Тишков белән очраштык. Янәдән хокуклар турында сөйләштек. Бурбулис: «За год переговоров с Татарстаном мы очень сильно изменились и теперь считаем, что Россия должна быть асимметричной федерацией с элементами конфедерации», — диде. Бу безнең өчен бик зур җиңү иде. Хәтта Лихачёв белән кочаклашып, бер-беребезне котлап та алдык.

Статусны саклауның тулы мөмкинлеге бар, дип саныйм. Шартнамәнең ике Конституция (РФ һәм Татарстанныкы) һәм 1992 елда үткәрелгән Референдум нигезендә төзелгәнлеге язылган. Референдумның танылуы безнең өчен бик зур нәрсә. Федераль үзәк белән ике арадагы Шартнамәнең 2017 елда срогы бетә. Аннары яңаны төзисе була.

Милек мәсьәләсендә без Декларацияне боздык. Декларациядә: *«Татарстан территориясендәге җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора»*, — дип әйтелгән.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Җир кемнеке булса — җил шуныкы, ди халык...

Индус ТАҺИРОВ. Акционерлаштыру үткәрәбез дигән булып, бар милекне бер төркем кеше үзенә генә алып калды. Акционерлаштыру — безнең Декларациягә капма-каршы чара булды. **Әгәр дә милек, җир асты байлыклары, чыннан да, халыкныкы булып калса, без бүген бензинның литрына 30 сумнан артык акча түләмәгән булыр идек, ул күпкә түбән, бәлки, бушлай ук булыр иде...**

Газинур МОРАТ: Заманында кайнар башлы, кызу канлы кайбер гаярьләребез «суверенитет» дигән изге төшенчәне «сувениритет»ка алыштырып сөйли, яза башлагач, мин дә үземчә кайнарланып, «суверенитетны ипигә ягып ашап булмый», дип матбугатта сүз әйткән идем. Хәзер уйлыйм да, ул чакта әйткәнем бик үк дөрес булып чыкмаган икән бит, диярга кала. Үтә дә меркантильләшкән заман каланчасыннан караганда, адәм баласын суверенитетның, асылда, матди ягы гына кызыксындыруы бик тә яхшы аңлашыла. Бу җәһәттән җөмһүриятебез халкының тормыш-көнкүрешен мотлак уңай якка үзгәрткән берничә зур дәүләти эшне генә атап үтсәк тә, суверенитетның акчалата кыйммәте дә кулга тотып карар дәрәҗәдә тәгаенләнә төшәр. Әйтик, Татарстан авылларын тоташ газлаштыру, зур юлларны тәртипкә китерү, тузган торакны бетерү программасы... Газлаштыруның асыл бәясен ел әйләнәсе утын хәстәрләп интеккән халык үзе генә белә торгандыр. Кайчандыр Саескан тавы кичүендә көнетөне чират көтеп тилмергән мосафир-юлаучылар да «суверенитет күпере»нә бик тә рәхмәтледер. Ә инде ярымҗимерек йортларда, кеше почмакларында җан асрап, заманча фатирларга күченеп яши башлаган күпмеңләгән ватандашларыбыз турында әйтеп тә торасы юк.

Сүз дә юк, хәзер вазгыять нык үзгәрде. Татарстан халкы эшләп тапкан малның 80%ы кабат үзәккә китеп бара башлады. Әгәр дә 50/50 принцибы элеккечә сакланса, тырыш халкыбыз таулар күчерер иде, билгеле. Шуңа да карамастан, республикабызда бүген дә зур проектлар гамәлгә ашырылып килә.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Шушы 25 ел эчендә Татарстан үз юлын егетләрчә үтте. Кыргызстан, Азәрбәйҗан, Казакъстан, Татарстан — һәрберсенең үз юлы. Хокукларыбыз чикләнгән шартларда да шактый зур уңышларга ирештек. Татарстанның сәяси, хокукый, икъктисади үткән юлын башка ил-халыклар, аеруча төрки дәүләтләрнеке белән чагыштырып тикшергән җитди хезмәтләр кирәк. Бу дөнья җәмәгатьчелеге өчен гыйбрәтле булачак. Үткән йөз ел вакыт эчендә «без кем идек тә кем булдык!» Чагыштырулар миллилек ягыннан күп чакта безнең файдага түгел шул...

Без Россия Федерациясендә яшибез дип саналабыз, ләкин соңгы вакытта «федерация» сүзе телдән төшеп калып бара. Миңа калса, Россиядә «федерация» дип әйтерлек сәяси һәм икътисади гамәлләр фәкать Татарстан белән генә бәйле булып кала бара... Мин моны РФ һәм ТР арасында төзелгән тарихи Шартнамәләрне дә күздә тотып әйтәм.

Разил ВӘЛИЕВ. Соңгы вакытта республикабыз тормышында Шартнамәнең роле шактый кимеде. Әмма аны һич кенә дә

сәяси кырдан алып ташлау дөрес булмас иде. Без 2015 елның 1 гыйнварыннан Президент атамасыннан баш тартырга тиеш идек. Хәзер аны Шартнамәгә таянып 2016 елга кадәр калдырдылар. 2017 елда Шартнамәнең срогы чыга, әгәр дә без Россия белән яңа Шартнамә төземәсәк, Россиядән читтә калабыз, дигән сүз. Чөнки беркайчан да, калган республикалар кебек, Федератив Шартнамәгә кул куймадык.

Индус ТАҺИРОВ. Безнең Президент постын саклап калу өчен аргументлар күп, бөтен юридик нигезләребез бар. Без Президент сайлаулары үткәрәчәкбез. Ул сайланганнан соң Конституцияне тотып ант итәчәк. Конституциядә дә Президент посты күрсәтелгән. Ант итә икән, димәк, ул әлеге постны да сакларга тиеш булачак! Владимир Путин моңа каршы килер, дип уйламыйм. Аңа бер очрашуда Татарстанның Президенты мәсьәләсенә ничек карыйсыз, дип сорау бирделәр. Республика үзе хәл итсен, диде ул. Хәл итик! Менә аннан да файдаланырга кирәк. Бу ни өчен әһәмиятле? Монда халыкның хокукы турында сүз бара. Республика башлыгы исемен булдырсак, безне мәҗбүр иттеләр, без буйсындык булып чыга. Башкортлар буйсынды. Дөресен әйтергә кирәк, алар соңгы елларда безнең өчен союздаш, аркадаш була алмады. Федератив Шартнамәгә без кул куймадык, безгә ияреп Башкортстан һәм Якутия дә кул куймаячакбыз, диделәр, вәләкин куйдылар. Аларны Бурбулис менә сезгә фәлән-фәлән хокуклар бирәбез, кул куегыз, дип күндергән. Мин Башкортстанга баргач: «Менә сезгә хокуклар вәгъдә иттеләр, бирделәр, ә хәзер ул хокукларыгыз кайда?» — дидем. Кем ул хокукны биргән, ул аны кире дә ала алачак! Ә безнең позиция иkенче. Без артык хокук таләп итмибез, ләкин ул безнең хокук булсын, Россия аны таныргa тиеш.

Разил ВӘЛИЕВ. Безнең алда Президент сайлаулары тора. Соңрак Президент атамасын саклап калу өчен көрәш булачак, ул җиңел генә бирелмәс, дип уйлыйм. Аннан Россия белән Татарстан арасында вәкаләтләрне бүлешү турында яңа Шартнамә төзү эше башланачак. Бу бик катлаулы эш. Мин үткән 2007 елда кабул ителгән Шартнамәне төзегәндә эшче төркемдә идем. Ел ярым вакыт Мәскәү белән ике араны таптадык. Туксанынчы елларда башланган эш әле бүген дә дәвам итә. Безнең эшлисе эшләребез бик күп.

Индус ТАҺИРОВ. Бүгенге көндә Татарстан бердәнбер махсус шартнамәле Республика. Әгәр дә шартнамә принцибы бетә икән, Федерация юк була. Шунлыктан яңа шартнамә, һичшиксез, булырга тиеш. Татарстан — закон буенча махсус статуслы Республика, Россиянең федератив нигезен саклап торучы нечкә генә булса да бер кыл.

Ә инде киләчәк — көрәштә. Әгәр дә татар халкы көрәшне туктатмый икән, әгәр дә депутатларыбызга, хөкүмәтебезгә, Президентыбызга төрле рәвештә ярдәмебезне күрсәтмибез икән, мәйданнарыбыз кирәк вакытта тулмый икән, әлбәттә, бик тә авыр булачак.

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Без яңадан бер кайтып, шул заманда уянган халыкка рәхмәт әйтергә тиеш. Халык ташкын булып уянмаса, без мондый бөек эшләрне эшли алмас идек һәм моның кадәр көчле, үз сүзләрен әйтә торган депутатлар Дәүләт Советына, Дәүләт Думасына үтмәс иде. Миллилек киләчәктә дә саклансын иде! Халыкның рухы сүнмәсен иде!

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Рөстәм Миңнеханов: *«Күренекле драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Габдулла улы Миңнуллин — эшгамәлләре белән халык хәтерендә истә калырга лаек булган көчле шәхесләрнең берсе. Замана җилләре ничек исүгә карамастан, туган халкының кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычларын үзенеке дип кабул итүче, шуны җырлаучы Туфан ага безнең аксакалыбыз, олуг остазыбыз иде…*

…Олуг язучының исеме, аның зирәк сүзе безне бүген дә озатып бара. Бу һәрвакыт шулай булыр, дип ышанам».

Минтимер Шәймиев: *«Мин иң элек аны халкыбызның иң булган, иң лаеклы улларының берсе, дип саныйм. Уйлавымча, аны Ходай бу дөньяга татар халкының яклаучысы, аның телен, моңын, җанын саклаучы итеп яраткан. Халык күңеленең гел чыңлап торган сизгер бер кылы, дип әйтер идем хәтта. Аңа Туфан исеме дә очраклы бирелмәгән, дигән фикер белән килешәм. Зур шәхес. Көчле шәхес».*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ТУРЫНДА КАЛӘМДӘШЛӘРЕ

Илдар ЮЗЕЕВ
КОТЛАУ

Халкыбызның яшәү дәртен
Син расларга туган көк,
Әдәбиятыбызның көче —
Хәтта ике Туфанлык!
Үзең иҗат иткән Тукай
Тәбрикләп кочар иде,
«Моңлы бер җыр»ыңнан Муса
Кулыңны кысар иде.
Театрыбызның атасы
Г.Камал бүген сөеп,
Сиңа сокланып карый көк:
«Афәрин, балам!» — диеп.
Туфаның — бөек адашың
Котларга кайтыр кебек,
«Минем исемне акладың,
Рәхмәт!» — дип әйтер кебек.
Бер Тукайлы, бер Такташлы
Һәм дә ике Туфанлы
Бик бәхетле әдәбият
Котлый бүген Туфанны!
Театрның гына түгел,
Син — халыкның баласы,
Барыр юлларың бик ерак —
Яңа үрләр аласы!
Күз тимәсен, рухы көчле,
Җәлилләрчә — Туфан нык,
Син сәнгатьнең яшәү көчен
Раслау өчен туган көк,
Гомер юрый сиңа халкың,
Ике, өч, дүрт Туфанлык!

25 август, 1985 ел



БАТУЛЛА
АБРУЙЛЫ УРЫН

Туфан Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр»дән башка бер генә җөмлә язмаган булса да татар әдәбияты, татар театрының тарихында иң абруйлы урыннарның берсен яулаган булыр иде.

1995



Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

БӘҺАСЕЗ ЗАТ

Әйтәләр бит: кояшта да
Гыйбрәтле таплар була.
Халыкта да мәңге калыр
Бәһасез затлар була.

Андыйлар бездә дә бар ул,
Тарихта кала торган:
Әлдермештән — Әлмәндәр карт,
Мәрәтхуҗадан — Туфан.

Кайсы кайсын тудырган соң? —
Бу кечкенә мәсьәлә!
Алар яши,
Ә калганын
Белү безгә нәрсәгә?!

Кайсы кайсына охшаган? —
Бәхәс кузгату — юкка:
Берсе — Миңнуллинга тарткан,
Берсе — Биктимеровка.

Меңләп татар баласыннан
Актарып табып алып,
Зирәклек, тапкырлык дигән
Мәгънәви орлык салып,
Аларны безнең күңелгә
Алган да чөйгән халык.

Гыйбрәтләр ала торган шул,
Таңнарга кала торган:
Әлдермештән — Әлмәндәр карт,
Мәрәтхуҗадан — Туфан.

1995

Марсель ГАЛИЕВ

ГАЛӘМИ ӨЛЕШ

Аның һәрбер әсәре — үзе бер шигърият. Ул — цензура балтасының хәтәр чорында да хикмәтле фикерләр әйтә алган кыю әдип. Театрны үстерүгә Туфан галәми өлеш кертте. Ничә дистә еллар буена ул халкыбызны елатты да, уйлатты да, юатты да, уятты да.

2000

Разил ВӘЛИЕВ

МИҢНУЛЛИН ТЕАТРЫ

«Татар бетә», — дип кемнәрдер
Астыртын хәйлә корды.
Халкыбызны саклап калды
Академ театры.

Телсезләргә тел бирде ул,
Уйсызларны уйлаттырды:
Т.Миңнуллин яза торды,
Сәлимҗан куя торды.

Йоклаганны уяттырды,
Көлдерде, уйнаттырды
Г.Камал исемендәге
Миңнуллин театры.

1995

Мәгъсум ХУҖИН

ИХЛАСЛЫК

Туфан Миңнуллинның ихласлыгы башка яхшы якларыннан — эшчәнлектән, дуслыкта тугрылыктан, тәвәккәллектән һәм башкалардан — калкурак булып күренә миңа. Әйе, язганында да, бүтән гамәлендә дә ихлас ул. Укучылар һәм тамашачылар аның әсәрләрен тормышны әчкерсез чагылдырулары өчен ихластан кабул итә. Язган һәр сүзендә риясыз Туфан.

1995

Роберт МИҢНУЛЛИН

ТУФАНГА КИЛЕШӘ УЛ!..

Бу нәрсә бу? Туфан таша,
Татарны Туфан баса:
Театр гына ярар иде,
Парламент туфанлаша.

Парламент дигән театр...
Ул анда йөзә генә.
Өзә генә — түрәләрнең
Ну үтә үзәгенә.
Юк аңа закон-канун да,
Юк аңа регламент та.
Шекспир трагедияләрен
Уйный ул парламентта.

Сессияләрдә дә Туфан
Еш кына кызыштыра,
Әзер сценарийларны
Еш кына бозыштыра.

Министрлар уянсынга,
Түрәләр оялсынга,
Таяк тыга парламентның
Кырмыска оясына.

Туфан кирәк дөньяларны
Болгатып торыр өчен,
Маңкортларның кайчагында
Колагын борыр өчен.

Без чыксак кына, рәис
Шунда ук бармак яный.
Ә Туфанга килешә ул,
Аңа ничек тә ярый.

Нишлисең бит, ул шундыйрак,
Ул шундыйрак гадәтле.
Парламентта арыслан ул,
Парламентта — гайрәтле...

Әйе шул, усал гына ул,
Югыйсә, тешле генә...
Тик театрда утыра
Ул песи төсле генә.

Ул анда актёр түгел шул,
Автор гына ул анда.
Яшәр Камал театры
Андый автор булганда!

Театр түренә Туфан
Үрләде Камал аша.
Камал туфанлашкан саен
Туфан да камаллаша!

25 август, 2005 ел

КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Президиумда: Гомәр Усманов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Туфан Миңнуллин. 1980 нче еллар

ПЭН-клубта узган утырыштан соң. 31 октябрь, 2008 ел

Татарстан халык шагыйрьләре һәм язучылары. 2005

Т.Миңнуллин бер төркем каләмдәшләре арасында. 2005

Телевидениедә. 2010

Ташлык авылында (Түбән Кама) музей ачылган көн. 2010

«Казан утлары» редакциясендә. 1990 нчы еллар

Изге Болгарда. Юлга кузгалыр алдыннан. 14 июнь, 2008 ел

БОЛГАР. ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

X-XI гасырларда Болгар шәһәре — Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы, аннан соң, XIII-XIV гасырларда — Алтын Урданың беренче башкаласы, Алтын Урда составындагы Болгар (Җүчи) олысы үзәге.

Көнчыгыш Европаның стратегия һәм сәүдә ягыннан иң әһәмиятле урыннарының берсендә — Чулман һәм Идел кушылган урында урнашу сәбәпле, Болгар, барлыкка килгән вакытыннан ук, Идел буе халыклары һәм, гомумән, бөтен Көнчыгыш Европа тарихында җитди роль уйнаган.

922 елда бирелдә болгарлар — хәзерге Казан татарларының ата-бабалары — рәсми рәвештә ислам динен кабул иткән. X гасырда Болгарда яңа дәүләтнең символы — акча-тәңкә сугылган. Шәһәр ул заманда ук чит ил кешеләренең игътибарын җәлеп иткән, аның турында гарәп, фарсы елъязмачылары һәм географлары язып калдырган. Язма чыганакларда,

башлыча көнчыгыш чыганакларда, Болгар шәһәре бирегә Ибне Фадлан килгәнче үк телгә алынган. Нумизматика материаллары анализы да әлеге мәгълүматка каршы килми.

Болар Көнчыгыш Европаның Урта Азия белән сәүдә итүендә төп урынны алып торган. Аның аша көнчыгышка әһәмиятле товарлар — төньяк халыкларның һөнәри һәм аучылык эшләнмәләре сатылган. Рус товарлары да аның аша үткән. Тора-бара Болгарда төрле һөнәрләр үсеш алган. XII гасырда Болгар, үзенең халыкара базар буларак әһәмиятен югалтмыйча, башкала ролен Биләр шәһәренә биргән. Бу хәл монголларга кадәрге чорда шәһәрнең берничә кат җимерелүе аркасында да килеп чыккан.

Бу дәвердә Болгарның икътисады, һөнәрчелеге, сәүдә элемтәләре үскән, биләмәләре арткан, шәһәр тирәли яңа фортификация рәте төзелгән. Шәһәрнең ныгытылган өлеше 1236 елга 24 га тәшкил иткән. Бу чорда

Болгарның Русь белән бәйләнешләре көчәйгән.

1236 елда Болгар монголлар тарафыннан яулап алынган һәм яндырылган. Шәһәрнең ныгытмалары җир белән тигезләнгән. Шәһәр үзенең иле белән бергә Җүчиләргә буйсынучы олыслар системасына кертелгән, ягъни Алтын Урда составына кергән. Аның беренче башкаласы итеп 1242 елда Батый хан Болгарны сайлаган.

XIII гасыр уртасында Болгар яңадан аякка баскан һәм монголлар тарафыннан үз империяләренең көнбатыш кырыйларында оештырылган яңа дәүләтнең әһәмиятле ноктасына әйләнгән.

....

Урдадагы туктаусыз феодаль чуалышлар Болгарны әкренләп һәлакәткә алып барган. Шуларның берсе – Булат Тимернең 1361 елда Болгарга һөҗүме, ушкуйникларның һәм рус кенәзләренең XIV гасыр ахыры-XV гасыр башындагы һөҗүмнәре...
Шул заманнан бирле Болгар тарихи аренадан мәңгегә юкка чыккан

....

XIII гасырда Болгар Алтын Урдада алдынгы рольне уйнаган. XIII гасырның 50 нче елларында рус, әрмән һәм болгар кенәзләре Батый ханга кенәзлек итү ярлыклары сорап килә торган булган. Соңрак, Мәнге Тимур, Бәркә хан һәм аеруча Үзбәк хан вакытында Болгар Алтын Урданың иң төп икътисади, сәүдә, мәдәни һәм дини үзәкләренең берсе булып кала биргән. Ул Җүчи олысында мондый беренче корылма саналган. Болгар 1250 елларда Алтын Урданың бөек ханнары — Мәнге һәм Арык Бога исеменнән акча сугучы беренче шәһәре булган.

XIV гасырда, Алтын Урданың сәяси үзәкләре көньякка, Сарайга күчүенә карамастан, Болгар зур һәм куәтле шәһәргә әверелгән. Бу чорда шәһәр төньяк, көньяк, көнбатыш якларга шактый киңәйгән, туфрак өемнәреннән, агач диварлардан һәм манаралардан торган ныгытмалар рәте белән әйләндереп алынган. Ныгытылган өлеше 415 га тәшкил иткән.

Шәһәрнең Түбән Идел буе, Иран, Хәрәзем, Кавказ, Кырым, рус кенәзлекләре белән сәүдә элемтәләре киңәйгән. Күптармаклы махсус һөнәри җитештерү үсеш алган. Монда XIV гасырда ук, Көнбатыш Европадан 2 гасыр элек чуен коя башлаганнар. Монументаль архитектура корылмалары — сарайлар, феодал-аксөякләр йортлары, кәрван сарайлар, җамигъ һәм квартал мәчетләре, мәктәпләр һәм мәдрәсәләр, җәмәгать мунчалары, төрбәләр һәм башка биналар: Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләр, Кара, Ак, Кызыл, Көнчыгыш пулатлар, кече манара, Ханнар төрбәләре барлыкка килгән. Иң төп җамигъ мәчете яңадан корылган. Шәһәрнең төзеклеге югары дәрәҗәгә ирешкән. Күпер һәм сууткәргеч корылмалар, киптерү системалары төзелгән.

Урдадагы туктаусыз феодаль чуалышлар Болгарны әкренләп һәлакәткә алып барган. Шуларның берсе — Булат Тимернең 1361 елда Болгарга һөҗүме, ушкуйникларның һәм рус кенәзләренең XIV гасыр ахыры-XV гасыр башындагы һөҗүмнәре һәм, ниһаять, Василий II тарафыннан җибәрелгән кенәз Фёдор Пёстрый җитәкчелегендәге Мәскәү гаскәрләре һөҗүме шәһәрне һәлакәткә дучар иткән. Шул заманнан бирле Болгар тарихи аренадан мәңгегә юкка чыккан һәм мөселманнарның изге җиргә зыярәт кылу урыны гына булып калган. Биредә мөхтәрәм мөселманнар җирләнгән, руханилар һәм дәрвишләр яшәгән. Мәгълүм ки, XVI-XVII йөз татар шагыйрьләре Мөхәммәдьяр һәм Мәүлә Колый үз әсәрләрен Болгарда язган. XYI гасырда элеккеге Болгар дәүләте җирләре Рус дәүләте составына кертелгән. ■

ЯҢА СМӘИЛ МУЛЛАСЫ

Ләлә Мортазина, Илнур Газизуллин

Соңгы елларда татарның зыялы уллары — мәгърифәтчеләрен, педагогларын, дини белем бирү өлкәсендә эшләгән шәхесләрне барлау, авыллар тарихын өйрәнүгә игътибар артты. Совет чорында онытылуга дучар булган мәчет һәм мәхәлләләр, аларда төрле елларда хезмәт куйган имамнар, муллалар һәм башка дин әһелләренең эшчәнлеге яңа күзлектән чыгып өйрәнелә башлады. Шул эшнең нәтиҗәсе буларак, авыллар, мәчетләр һәм аерым шәхесләрнең тормышына багышланган хезмәтләр дөнья күрде, күбесенең исемнәре төрле белешмә басмаларга (Татар энциклопедиясенә, Татар педагогик фикере антологиясенә) кертелде. Әмма әлегәчә күләгәдә калып килүче, тиешенчә өйрәнелмәгән, һичшиксез, тарих мәйданына кайтарылырга тиешле шәхесләр, хәтта династияләр дә байтак. Татар зыялылары Бәхтияровлар әнә шундыйлардан. Сүзебез бу нәселнең бер вәкиле Мөхәммәтзыя Бәхтияров турында.

Мөхәммәтзыя Бәхтияров

1901 елның февралендә Нократ губернасы Малмыж өязе Яңа Смәил авылы халкы староста Н.Мөхәммәдиев һәм дин гыйлеме бирүче И.Фарушин җитәкчелегендә бер ел элек шул авылның мулласы, чыгышы белән Сембер губернасыннан булган Закир Юнысов соравы белән ачылган урыс-татар мәктәбен ябуны таләп итеп күтәрелә[1]. Мөселманнар арасында әлеге мәктәп татарларны чукындыру максаты белән ачылган дигән сүз тарала, мәктәпкә йөрүче балалар саны бермә-бер кими. «Тәрҗеман» газетасы язуынча, ачылган вакытта анда барлыгы 50 укучы булса, 1901 елда нибары 8 бала йөри[2]. Авыл халкы икегә бүленә — берәүләр мәктәптә дин сабагы бирүче Закир Юнысовны яклый, калганнар исә элекке гореф-гадәтләрне саклап калу ягында була. «Тәрҗеман» газетасы татар җәмәгатьчелеге арасында чыккан низагны мулланың халык белән эшли белмәвендә һәм балаларны аваз ысулы белән укытырга теләмәвендә дип аңлата[3]. Урыс-татар мәктәбе ябыла. Закир хәзрәт урынына 1902 елда Түнтәр мәдрәсәсен тәмамлаган Мөхәммәтзыя (Зыя) Бәхтияровны мулла итеп билгелиләр.

Мөхәммәтзыя Бәхтияр углы әл-Мәмдәли 1877 елның 28 февралендә хәзерге Биектау районы Мәмдәл авылында указлы имам Бәхтияр хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Әнисе Бибифаизә Мөхәммәтсадыйк кызы да Мәмдәл авылыннан[4]. Бу укымышлы, затлы нәсел күрше-тирә авылларда да бик мәшһүр була. Нәсел башы (бүгенге көнгә билгеле булган мәгълүматлар нигезендә) Габдулла хәзрәт хәзерге Биектау районына караган Юртыш авылында гомер иткән (кабере дә шунда). Аның улы Габделҗәлил хәзрәт Чар өязе Сотнур волостеның Күлбаш авылында (Марий Эл республикасы), оныгы Бәхтияр хәзрәт хәзерге ТРның Биектау районы Мәмдәл авылындагы икенче мәхәлләдә имам-хатыйп булып торган (кабере Мәмдәл зиратында). Бәхтиярның уллары Габделһади Мәмдәлдә, Мөхәммәтзыя Яңа Смәилдә, Габдрахман Зур Сәрдектә (хәзер ТРның Кукмара районына карый) озак еллар буена мулла вазифасын үтәгән, балаларга белем биргән.

[1] Касимова Д.Г. Религии народов Вятского края. — Киров, 2009. — С.195-198.
[2] Тәрҗеман. — 1903. — 7 февраль.
[3] Шунда ук.
[4] ТР МА, 204 ф., 177 тасв., 157 а эш, 176 б.

Мөхәммәтзыя Бәхтияров үзенең авылдашы белән



Мөхәммәтзыя Бәхтияровның «Горрәи даими» китабының титул бите

Мөхәммәтзыя мулла гаиләсендә борынгы бабаларының әсирлеккә төшкән төрекләр белән бәйле булулары турындагы риваять сакланган[5].

З.Бәхтияров, башлангыч белемне этисеннән алганнан соң, укуын Түнтәр мәдрәсәсендә дәвам итә. Түнтәрдә укыган дәверендә ике китап яза[6]. 1898 елда Казан университеты типолитографиясендә «Каванин әл-хисаб» (арифметика), 1903 елда бертуган Кәримовлар типографиясендә «Горрәи даими» («Мәңгелек календарь») исемле китаплары[7] дөнья күрә.

«Каванин әл-хисаб» — башлап өйрәнүчеләр өчен татар телендә язылган арифметика китабы. Заманында мәктәп-мәдрәсәләрдә файдаланылган бу китапның методик һәм бер үк вакыт-

[5] Алсу Харис кызы Галиева (1934 елда туган) истәлекләре. 2013 елның 8 февралендә И.Газизуллин тарафыннан телефон аша язып алынды.

[6] Берсенең кулъязмасы КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә саклана: Каванин әл-хисаб. Рисаләи зыяия. Түнтәр авылы. 1897. Автограф. 34 кгз. 1502 т. (э. №5393)

[7] Бәхтияр Мөхәммәтзыя. Каванин әл-хисаб. — Казань: Типо-литография Императорскаго Университета, 1898. — 88 б.; Бәхтияр Мөхәммәтзыя. Горрәи даими. — Казань: Тип. Лит. и Словолитня Т.Д. Бр. Каримовых, 1903. - 23 б.



Мөхәммәтзыя Бәхтияровның «Каванин әл-хисаб» дәреслегенең бер бите.
«Робгы мөҗиб» (секстант) рәсеме

та фәнни яктан да нигезле, камил булуы шиксез. Галим Альберт Фәтхи тарафыннан әзерләнгән «Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары» тасвирламасына кертелүе Зыя мулланың галимлеген тагын бер кат раслый[8]. Китап өч кисәктән гыйбарәт, татар телендә язылса да, атамалар гарәп телендә бирелгән. Бөтен саннар, кушу, алу, тапкырлау, бүлү, тамыр, вакланмалар, пропорция, градус, дуга кебек төп математик терминнар аңлатылган, мәсьәләләр һәм күнегүләр тәкъдим ителгән. Китапның «Рисаләи зыяия фи гамәле би-р-робгъ әд-дәстүрият» (астрономия) дип аталган икенче өлешендә «робгы мөҗиб» исемле җиһаз (секстант) ярдәмендә вакытны ничек билгеләү хакында сөйләнә, аның рәсеме бирелә.

Әлеге китапларны язган вакытта Зыя Бәхтияров, кирәкле киңәшләр алу максаты белән, Казанга атаклы гыйлем иясе Каюм Насыйри янына килеп йөри. *«Бу вакытта ул хәзерге Галиәсгар Камал урамында үзенең туганы Габделмән (Габделхәйнең улы) Казанский йортында тора иде. Өсбашы һәм бүлмәсе бик гади иде. Үзе бик әкрен сөйләшә, китапны өстәлгә ятып карый. Китаплары бик күп иде. Күбесе язма китаплар. Үзе китаплар уртасына кереп, тәбәнәк өстәл янына аякларын бөкләп утырган иде. Үзе*

[8] Кулъязмалар тасвирламасы. X чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. Өченче бүлек / Төз. А.Фәтхи. — Казан: 1968. — 77 б.

утырган өстәл янындагы стенага эре хәрефләр белән тар-озын кәгазьгә: «38 ел эшләдем, ләкин гыйлемгә мәхәббәтле кеше тапмадым», — дип язып ябыштырган иде. Гыйльми мәсьәлә турында үзеннән киңәш сорап килүемә бик кәефе килде. «Менә бу «Фазиле мадани» дигән китап. Син үзеңә кирәкле мәсьәләләр турында шуннан җавап таба аласың, — дип, китапның аерым битләрен миңа укып һәм аңлатып бирде», — дип сөйли үзенең истәлекләрендә З.Бәхтияров[9]. Беренче китабы басылып чыкканнан соң да Зыя, Казанга килү белән, остазының хәлен белгән. Аны бигрәк тә К.Насыйриның медицина өлкәсендәге гыйлемнәре кызыксындыра. Бу елларда Зыя мулла авыруларны дәвалау ысуллары, шифалы үләннәрне файдалану буенча зур гына тәҗрибә туплый. *«Аерым авыруларны ничек дәвалау турында ул авыл врачлары белмәгән нәрсәләрне белә һәм шул турыда яхшы киңәшләр бирә иде. Күбрәк үләннәр белән дәвалау кирәклеге турында сөйли иде»*, — дип искә ала ул остазы турында[10]. Соңыннан алган белемнәрен Яңа Смәилдә төпләнгәннән соң файдалана.

Яшь мулла (бу вакытта аңа 25 яшь була) озакламый 1883 елда Зур Сәрдек авылында туган Фатыйма Нигъмәтулла кызы белән никахлаша. Әлеге никахтан Габделхәй (24 яшендә вафат), Сәйдә, Рәшидә, Хәсәнә, Харис, Мәхмүт, Хәкимә исемле балалар дөньяга килә. Мулла булуының беренче елларында ук, Зыя Бәхтияров, иске мәчет кечкенә булу сәбәпле, яңа мәчет бинасын салу эшенә керешә. Халык, бигрәк тә Иске Йөрек авылыннан Гыйззәтулла бай аңа матди ярдәм итә. Мулла гаиләсенә өч бүлмәле йорт, янәшәдә генә ике катлы

Яңа Смәил мәдрәсәсе бинасы

[9] Зыя Бәхтияров истәлеге (Истәлекне язып алучы — М.Гали) // Каюм Насыйри. 1825-1945 (Туыына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). — Казан: Татгосиздат, 1948. — Б.145.
[10] Шунда ук.

мәдрәсә бинасын да өлгертәләр[11]. Шул мәдрәсәдә Зыя мулла балаларга дин гыйлемен укыткан, шәкертләргә карата бик таләпчән булган.

Зыя мулланың әнисе Бибифаизә Мөхәммәтсадыйк кызы 1909 елда 65 яшендә вафат була. Кабере Яңа Смәил зиратында. 1890 елның 13 ноябрендә ире Бәхтияр хәзрәт вафат булганнан соң[12], Бибифаизә уллары карамагында була. Мөхәммәтзыя, үзе Яңа Смәилгә күченеп килгәннән соң, Мәмдәлдән әнисен дә үз янына алдырган булса кирәк.

Зыя тиз арада яңа авылдашлары алдында үзен таныта, абруй казана. Фикерле, белемле, ипле-җайлы, олылар белән дә, яшьләр белән дә уртак тел таба, җитмәсә, дәвалый белә — аның авыл халкы алдында дәрәҗәсе бик тиз күтәрелә. Табиблык серләрен белүе авылда шифаханәләр, медицина белемле кешеләр булмаган заманда бигрәк тә ярап куя. Инде авылда медпункт ачылганнан соң да Зыя мулладан ярдәм сорап килүчеләр сирәгәйми. Аның янына авырып киткәннәр дә, кайгы-борчуы булганнар да, шатлыгы белән уртаклашучылар да — барысы да агыла. Имамның төпле белемле булуы тормышның күп өлкәләрендә халыкка киңәшләр бирергә мөмкинлек бирә. Ә аның нинди оста бакчачы булганлыгы турында авылдашлары әле дә сокланып искә ала. Мулланың йорты су буендагы бик матур җиргә урнашкан, йортны һәрьяктан алмагачлар һәм башка күптөрле җиләк-җимеш агачлары утыртылган зур бакча әйләндереп алган була.

Хатын-кызларга мәчеткә керү рөхсәт ителмәгәнгә күрә, мулла абзый җәмәгате Фатыйма абыстайга үзенең кечкенә өенә хатыннарны җыярга, бергәләп җомга вәгазьләре укырга рөхсәт итә. Корбан гаете, Ураза гаете, Кадер кичәсе, нинди генә дини бәйрәм булмасын, авылның хатын-кызлары Зыя мулла өенә җыелган. Бу гадәт совет чорында да дәвам итә. *«Бервакыт әниемнең ипи пешереп, сәдакага он, ярма алып Кадер кичәсенә барганы хәтеремдә калган»*, — дип яза үзенең истәлекләрендә Яңа Смәилдә туып-үскән Халисә Газизуллина.

Шулай җай гына яшәп яткан вакытта илдә зур үзгәрешләр башлана. Совет чорында дин эшлекләләре эзәрлекләнә, мәчетләр ябыла, бинолары клуб, мәктәп, хәтта амбар һ.б. итеп файдаланыла башлый. Татарның бик күп зыялылары сөргенгә озатыла, күбесе юк ителә. Гарәп графикасында язылган меңнәрчә китап яндырыла, мәчет манаралары кисеп аударыла, халык көчләп гасырлар буена үзен саклап, тәрбияләп торган диннән читләштерелә. Бу хәтәр җилләр Яңа Смәил мулласын да эзләп таба…

Гыйлем иясе өчен иң куркыныч — кадерле китаплары юкка чыгу. Зыя мулланың да озак еллар дәвамында туплаган бай китапханәсе тарала. Алар арасында Мөхәммәтзыяның үзе, шулай ук әтисе Бәхтияр Габделҗәлилов тарафыннан язылган китаплар да була[13]. Бик күпләрен, эзәрлекләүләр башлангач, үз туганнарына һәм күршеләренә тапшыра[14], калганнары

[11] Мәгълүматлар Рәхимулла Әхмәдуллинның 1974 елда язган истәлекләреннән алынды. Габдрәхимова Гадилә Солтан кызының (1957 елда туган) шәхси архивында саклана.
[12] ТР МА, 2 ф., 2 тасв., 3986 эш, 10 б.
[13] Бәхтияр Габделҗәлиловның вафатыннан соң 14 ел узгач басылып чыккан китабы КФУның Н.И.Лобачевский ис. Фәнни китапханәсендә саклана. Кара: Бәхтияр әл-Мәмдәли. Рисаләи тәүхид. — Казан: Кәримия, 1904. - 8 б.
[14] Мәгълүмат Габдрәхимова Гадилә Солтан кызы (1957 елда туган) истәлекләреннән алынды.

соңрак авылда чыккан коточкыч янгын вакытында юкка чыга.

Менә шундый көннәрнең берсендә авылга районнан вәкил килеп төшә. Бу вакытта авыл советы рәисе булган Гафи Ситдыйков авыл мулласын алып китәр өчен килгән вәкилне каршы ала. Тегесенең сораштыруларына карата Зыя мулланың Советларга каршы бернинди дә эш алып бармавы, алдынгы карашлы булуы, халыкны аңлыбелемле итү өчен җаны-тәне белән тырышуы хакында сөйли. Боларның барысына ышанса да, вәкилнең үз миссиясен үтәмичә китмәячәге билгеле. Гафи агай ике ут арасында кала: бер яктан, ул властька каршы килә алмый, әгәр инде бер гөнаһсыз Зыя мулланы шушы адәм кулына биреп җибәрсә, гомере буена үзен гафу итмәячәген аңлый. Аннан соң кеше, авыл халкы да бар бит әле, алар күзенә ничек карарсың?

Совет урнашкан йорт белән хәзрәт өе арасындагы ераклык әллә ничә чакрым кебек тоела Гафи агайга. Соңыннан ул үзе бу турыда: «Әйтерсең лә мин үзем конвой белән барам, күзләрем җиргә төбәлгән, каршыма очраган берәүгә дә күтәрелеп карый алмыйм», — дип сөйләгән.

Гафи Ситдыйков белән район вәкиле килеп кергәндә Зыя мулла, алдына алъяпкыч ябып, кулына себерке тотып ишегалды себереп йөргән була. Шулвакыт Гафи агайның башына бер уй килә һәм ул кычкырып: «Хазрат дома ли?» — дип сорый. Бу хәйләне аңлап алган Зыя: «Дома, дома, заходите», — ди дә, үзе, алар өйгә кереп китү белән, арткы як ишектән бакча буйлап чыгып йөгерә. Аның кемлеге турында кызыксынган вәкилгә Гафи абзый: «Зыя мулланың хезмәтчесе, бераз йорт эшләрендә булышкалый», — дип җавап кайтара. Күпме генә эзләсәләр дә, ни өйдән, ни бакчадан мулланы да, аның «хезмәтчесен» дә таба алмыйлар.

Зыя хәзрәт исә авылдан ике генә чакрым ераклыктагы Алма-Ата дигән авылга[15] барып җитә. Соңыннан аны ат белән Шәмәрдән станциясенә озаталар. Кайбер мәгълүматлар буенча ул берара Уразай авылында Газизулла абзый, Малмыжда Газизулла улы Тимергали өендә качып ята. Берничә ел Казанда яши. Кулга алулар, эзәрлекләүләр шаукымы бераз тынычланганнан соң, кире Яңа Смәилгә әйләнеп кайта. Казан шәһәрен үз иткән мулла анда олыгайгач та барып йөри әле. Ябык кына гәүдәле, күк төсле зәп-зәңгәр күзле, әкрен тавыш белән, салмак кына сөйләшүче, һәрвакыт үзе алып килгән нindидер үлән чәен эчүче, сөйләшкәндә бик еш кына Аллаһ исемен искә алучы («Безнеңчә Аллаһ, сезнеңчә Табигать», — дияргә яраткан) Зыя мулланың Танкодромга килеп йөргәнен бертуган сеңлесе Кәримәнең кызы Алсу Харис кызы Галиева (1934 елда туган) әле дә юксынып искә ала. Казанга килгәч, ул намазга Мәрҗани мәчетенә килгән. *«Безгә әйтеп торып хат яздырганы хәтеремдә. Уфага мөселманнарның дини идарәсенә Корбан гаете белән тәбрик итеп хат язып, аны конвертка салып, почтага илтә идем»*, — дип сөйли Алсу ханым[16].

Революциядән соң Зыя мулла йортын мәктәп итеп үзгәртәләр, ә мәдрәсәне төрле елларда китапханә, клуб бинасы итеп файдаланалар. Җәй

[15] Киров өлкәсе Малмыж районында XX гасырның 20 нче елларында төзелгән авыл. Бөек Ватан сугышы чорында юкка чыккан.
[16] Истәлекләрне И.Газизуллин 2013 елның 8 февралендә телефон аша язып алды.

көне «Туры юл» колхозы таш клубта балалар бакчасы оештырган, шунда әти-әниләре эштә вакытта авыл балаларын карап, ашатып торганнар. Ул бина 1940 елда сүтелә. Бераз читкәрәк дүртъеллык яңа мәктәп төзелә[17].

Йортсыз калган Зыя муллага авылдашларыннан Җәләй ага бушка кечкенә генә бер йорт бирә[18]. Муллалар нәселеннән чыккан Мөхәммәтзыя шушы ярлы, әмма бик пөхтә йортта гомеренең ахырына кадәр яши. Ишегалдының икенче бер почмагында тагын бер йорт төзиләр, анда Зыя мулланың кызы Сәйдә һәм киявe Бәхтигани яши. Соңыннан Сәйдә әти-әнисе йортына күченә, аларны тәрбияли, соңгы юлга озата. Үзе шул авылның абыстае булып, 1980 елның 10 декабрендә вафат була.

Авылдашларының истәлекләреннән күренгәнчә, Зыя мулла заманында дәвалау буенча К.Насыйридан алган белемнәрен гомере буе файдаланган: аның янына суык тисә дә, эч-баш авыртса да, пешкән-киселгән җирләрне төзәтергә дә йөргәннәр. Язын болын-кырлар кардан ачылу белән, З.Бәхтияров шифалы үләннәр җыя башлаган. Еш кына үзе белән 6-7 яшьлек балаларны да алган. Җәйләрен балаларны ат арбасына утыртып, авылдан өч чакрым ераклыкта урнашкан урманга йөргән. Һәрберсенең кулына бертөрле үлән тоттырып, бары тик шундыйларны гына җыярга куша торган була. Шул дару үләннәрен киптереп, кайсысыннан төнәтмә, кайсысыннан шифалы майлар ясаган. Зыя мулла белән урманга экскурсиягә

Мөхәммәтзыя Бәхтияров һәм Мостафа Ногман

йөргән кыз-малайлар хәзер инде үзләре олы яшьтә, дөньядан киткәннәре дә шактый. Алар юлда барганда Зыя мулланың балаларга сөйләгән хикмәтле сүзләрен әле дә искә алалар. Мулла абзый шул вакытларда ук әле авыл халкы бөтенләй белмәгән-ишетмәгән радио, телевизор, машина дигән хикмәтләрне күргән, белгән булган. Зыя абзый: *«Көтүче кулында кечкенә генә бер букча булыр, шул букча бөтен ил хәбәрләрен сөйләп торыр; почмакта кара чемодан торыр, түбәгә аркылы такта куйсаң, шул тартмадан кешеләр күренер»*, — дип сөйләгән. Шулай ук дүрт тәгәрмәчле арбага утырып Малмыжга тиз арада төшеп җитү мөмкин булуын сөйләп тә балаларны шаккатырган. Авыл

[17] Газизуллина Халисә Хәбибрахман кызы (1934 елда туган) истәлекләре. 2014 елның 10 мендa И.Газизуллин тарафыннан язып алынды.

[18] Алда искә алынган Р.Әхмәдуллин истәлекләре буенча, күрше Алдар авылыннан Федор Копылов үз өен мулла өчен күчереп салып бирә. Федор Александрович Копылов 1956-1960 елларда берничә авылны, шул исәптән Яңа Смәилне дә, берләштергән «Красный Октябрь» колхозы рәисе булып эшли.

Мөхәммәтзыя Бәхтияровның кабер ташы. Яңа Смәил зираты

Мөхәммәтзыя хәзрәтнең хатыны Фатыйма Бәхтиярованың кабер ташы

балалары бик кызыксынып, шул ук вакытта бераз куркып, мулла абзый сөйләгәннәрне тылсымлы әкият кебек тыңлаган[19].

Зыя мулланы гаҗәеп киң күңелле, ачык йөзле кеше буларак искә алалар. Алар Фатыйма абыстай белән бергә оныкларын – сугышта һәлак булган киявенең балалары Илһам белән Әнисәне, Ташкентта яшәүче кызы Хәсәнәнең Наилә исемле кызын тәрбияләп үстерә. Мөхәммәтзыя мулла шул ук вакытта бик юмарт, туганнарына гына түгел, авылдашларына да хәленнән килгәнчә матди яктан ярдәм иткән. Мәсәлән, 1932 елгы Раушания Хәбиевага урман кисәргә китәр алдыннан үзенең бүреген һәм бишмәтен (телогрейкасын) салып бирүе турында әле дә искә алып сөйлиләр.

Зыя Бәхтияров турындагы янә шундый бер вакыйга искә алына. Мулла, хатыны вафат булганнан соң (Фатыйма абыстай 1969 елда 86 яшендә вафат була), өйдә берүзе төн саклаган һәм шунда утырып чәй эчкән. Бу хәлгә аптырап караган авылдашларына: «Коръәндә чәй эчмәскә дигән сүз юк. Мин гомер буе бергә яшәгән хатынымнан курыкмыйм, барыбер бергә булачакбыз бит», – дип җавап биргән[20].

Мөхәммәтзыя Бәхтияровны тирә-як авылларда гына түгел, башка өлкәләрдә дә яхшы белгәннәр, аның белән кызыксынганнар. Бигрәк тә мулла үзенең язган хезмәтләре аша мәшһүр булган. Казан дәүләт университетының фарсы теле

[19] Мәгълүмат Абдулхакова Миннеракиядән 2011 елның 11 апрелендә А.Шәйхетдинова тарафыннан язып алынган истәлекләр буенча бирелә. Г.Габдрәхимованың шәхси архивында саклана.
[20] Алсу Харис кызы Галиева (1934 елда туган) истәлекләре. 2013 елның 8 февралендә телефон аша И.Газизуллин язып алды.

укытучысы Мостафа Ногман, 1968 елда бер төркем язучылар белән (алар арасында Ә.Еники, Ф.Хөсни, Ш.Галиев, Г.Минский һ.б. була) Яңа Смәил авылына очрашуга килгәннән соң, хәзрәт белән күрешәсе килүе турында әйтә. Мөгаен, ул аның университет китапханәсендә саклана торган әсәрләре белән таныш булгандыр. Шушы очрашу хакына галим башка иптәшләреннән аерылып, авылда кунарга карар кыла.

Хәзрәтнең өен эзләп тапкан Мостафа Ногман, мөселман гадәте буенча хуҗага сәлам бирә, дога кыла, йортка бәрәкәт тели. Аннан соң нинди йомыш белән, ни өчен килүе турында сөйли. Баштарак әлләни игътибар бирми генә тыңлаган хәзрәт, галим авызыннан Каюм Насыйри исемен ишеткәч, җанланып китә, кунакны үзенә якынрак утырырга дәшә. Зыя мулла үзенең Каюм ага белән ничек танышуы, аның янына йөреп белем алуы турында тәфсилләп сөйли. 91 яшьлек Зыя хәзрәтнең хәтере яхшы, зиһене куәтле булган. Ике галимнең серләре килешә: алар озак кына сөйләшеп утыра, бергәләп мулланың кульязмаларын барлый. Бу очрашуның шаһиты булган Эдуард Исламов Зыя хәзрәтнең университетка бүләк итү өчен Мостафа Ногманга китаплар бирүе турында әйтә[21]. Соңыннан ике галим, очрашу истәлеге дип, ишегалдында бергәләп фотога төшә. Аерылышканда Мостафа Ногман, янәдән очрашу кирәклеген ассызыклап, Мөхәммәтзыя мулланы Казанга кунакка чакыра. Мулла абзый бик теләп чакыруны кабул итә.

Шул ук кичне Мостафа Ногман Яңа Смәил мәктәбе укытучылары белән күрешә. Аларга мөрәҗәгать итеп: *«Хөрмәтле укытучылар, авылыгызда нинди бай тарихлы кеше яши. Без бу кешенең эзенә төшү өчен күпме көч куйдык. Аңа зур хөрмәт белән карагыз, кирәк вакытта, зинһар, ярдәм итә күрегез»*[22], — ди. Зыя мулла турындагы хәлләрдән хәбәрдар булып өлгергән галим репрессия елларында авыл халкының аны ничек итеп саклап кала алуы, аңа качарга ярдәм иткән кешенең нинди батыр йөрәкле булганлыгы турында исе китеп сөйли.

Шул җәйне Зыя мулланы Казанга алып китәләр. Аның башкаладаниләр белән шөгыльләнгәнлеге тәгаен билгеле түгел, әмма ул үзе, авылга кайткач: *«Бер атна буе профессорларны укытып кайттым әле»*, — дип шаяртып сөйләгән.

Мөхәммәтзыя Бәхтияров 1974 елның 18 гыйнварында җомга көнне кичке сәгать алтыда вафат була. Икенче көнне аны күмәргә Яңа Смәил һәм күрше авыллардан шактый күп халык җыела. Алар яраткан муллаларын соңгы юлга бик зурлап, хөрмәтләп озата.

Бүген Мөхәммәтзыя мулла нәселен дәвам итүчеләр авылда юк инде. Ләкин зыялылыгы, гыйлеме, тапкырлыгы, җор телле, юмартлыгы белән дан казанган Мөхәммәтзыя мулла турындагы хатирәләрне Яңа Смәилдә генә түгел, күрше-тирә авылларда яшәүчеләр дә саклый, аны «Смәил мулласы» дип, олылап искә ала, догадан калдырмый.

** Мәкаләне язу өчен мәгълүмат туплауда ярдәм иткән Яңа Смәил мәктәбе укытучысы һәм музей мөдире Габдрәхимова Гадилә Солтан кызына рәхмәтебезне җиткерәбез.*

[21] Исламов Э. Олы галим, җырчы, шагыйрь // Дуслык.- 1998. - №7 (9-15 февраль).
[22] Шунда ук.

МИЛЛИ ВӘ МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘ

Габделкаюм Баһмани*

1

Мөһим мәсьәләләр мәкаләсенең иң беренче бабын имамнар мәсьәләсе илә башлауга ихтимал укучыларның кайсылары гаҗәпләнерләр. Ләкин безнең күп мөһим мәсьәләләребезнең арасында, ошбу имамнар мәсьәләсе дә милли тәрәккыятебезнең әсаси [нигез] мәсьәләләреннәндер. Бу мәсьәлә моңа кадәр дә матбугатыбызда төрле вакытлар вә төрле мәүзугъ [проблема] берлә мөзакәрәгә куелды. Мин исә бер имамнар мәсьәләсен генә түгел, бәлки үзем эчендә кайнашкан берничә мәсьәләләрдән бәхәс итәргә телим. Минем бәхәс итә торган мәсьәләләрем берсе гарәп саче кебек бәйләнеп беткәнлекләр мәгълүм. Минем имамнар мәсьәләсе илә башлавым бу мәсьәлә күпләрнең мөрәҗәгате булуы сәбәбеннән икәнлекне сөйләдем. Бик күп мөселманнарның дин илә милли тәрәккыйбезне бергә җыярга тырышуы мәгълүм. Аның өстенә безнең мәхәллә мәктәпләребез имамнар мөсьүлияте [җаваплылыгы] тәхетендә булганлыктан, мәктәпнең алга китүе яки артка калуына акчадан соң имамнар сәбәп булалар. Шуның өчен дә милләтебез тарафыннан һәрвакытта имамнар тәнкыйть ителеп, күп эшләрнең алга китүенә алар тормоз хисапланды.

Мелланың авыл җирләрендә әһәмияте зур. Имам авылның бердәнбер аңлы вә укыган кешесе булганга, бөтен эшләргә дә юлбашчылык итү аларга гына кала. Әүвәлдә матбугатыбыз имамнарны мөтагассыйблар [фанатик] дип сүгә вә бөтен тәрәккый мәхвәребездә [нигезебездә] аларны зур тормоз күрә иде. Хәзер иске, фикерсез имамнар бетеп бара, меллаларның 60%ы яңа фикерледән тәшкил ителә, ләкин аңа карап зур үзгәреш юк. Мәктәпләр исляхы, школлар мәсьәләсе һаман да бер эздән чыкмый. 15 ел элек

* Габделкаюм Баһмани – Саба районы Юлбат авылыннан, Сатыш мәдрәсәсенең мөгаллиме, публицист, дин галиме. Мөхәммәт Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә» исемле әсәрендә Габделкаюм хәзрәтне әтисе Сөнгатулланың мөгаллиме буларак искә ала. Габделкаюм Баһманиның дини, дөньяви мәсьәләләргә караган фәнни, фәлсәфи һәм публицистик язмалары Оренбургта «Шура» һәм Казанда «Әд-дин вәл-әдәб» журналларында басылган. Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкалә «Шура» журналының 1916 елгы 9-10 нчы саннарында дөнья күргән.

ничә мәктәп вә ничә школа булса, саннары һаман да бер дәрәҗәдәрәк тора. Шулай булгач, боларның алга китә алмаулары, имамнарның мөтагассыйб вә тәрәкъкый дошманы булуларында гына түгел.

Моның сәбәбе исә имамнарыбызның мәгыйшәтләре тәэмин ителмәгәнлектән, мәктәп вә мәхәллә эшләрен ихлас илә эшли алмауларыдыр. Матбугатыбызда иске меллаларны сүгәбез дип, меллалар тотып капчыкка салынып селкенде. Затән «аршин»нан гына каләмгә күчкән яшьләрнең бәгъзесенә бу мәүзугъ бер азык кебек булды. Инде хәзер дә шуның әче җимешен бу көндә эш эшләрлек яшь имамнарыбыз җыялар. Әле моның зарары бу гына да түгел, бу эш төпле вә гыйлемле яшьләребезнең меллалык урыныннан суынуларына сәбәп булды. Имамлыкка яхшы кешеләр кермәсә, истихаксыз [лаексыз] кешеләр тулып, бу мәнсабнең кызганыч сурәттә калачагы табыгый.

Әүвәлдәрәк имамнарыбызга халыкның варидәте [акчасы] җитә, халык биргән илә иркен мәгыйшәт кылып була иде. Хәзер исә, доходлар киму өстенә, расходлар да өч өлеш артканлыктан, билгеле бер кәсеп, тамак туйдырырлык бер эш кирәк. Бу эш, кирәк нинди генә булмасын, имамның мәхәллә хезмәтләренә, мәктәп тәрбия кылуларына зарар китерәчәге мәгълүм.

Аның өстенә, әүвәлдә имамнарыбызның сүзләре мәхәллә халкы өчен мөкатдәс бер һатиф [серле тавыш] кебек тыңлана, мелланың тарткан юлына гавам иярә иде. Хәзер исә ул тыңлаулар юк. Бу тыңламау карт меллаларның тәгассыйбенә иярмәү генә булса, бик яхшы булыр иде. Моның зарары бигрәк яшь меллаларның тәрәкъкый вә мәгарифкә өндәүләрендә күренә. Матбугатыбыздагы имамнар хакындагы голүләр [арт-



«Шура» журналы. 1908 ел

тырып җибәрүләр] тәрәкъкыйпәрвәр имамнарның эшенә куәтле киртә була. Яхшырак эш эшләрлек кешеләр, тәкъдир сәвекы [кушуы] илә мелла булсалар да, үзләренең сүзләрен ишеттерә алмагач, вөҗдан газабы сәбәпле урыннарын ташларга мәҗбүр булачаклары табигый. Мондый кеше истигъфа кылгач [хезмәттән азат ителгәч], аның урынына күбесенчә бер тәрәкъкый дошманы утыра.

Минем бу мөкадимәләрдән максудым шул: **әгәр имамнарыбызның кадерләре югары күтәрелмәсә, мәгыйшәтләре тәэмин ителмәсә, меллалык урыны иң түбәнге кешеләр кулына калып, безнең авылларыбыз өчен тәрәкъкый тиз генә булмас.** Ач ат чыбыркы берлә генә бара алмаганы кебек, тамакларны туйдыру кайгысында булган имамнарны матбугатта сүгеп кенә безнең эшләр төзәлү ихтималы юк. Шәһәрдәге берничә йөз бай баласының тәртипле мәктәпләрдә укулары вә берничә дистә байбәтчәләрнең

тиҗарәт [сәүдә] мәктәпләрендә укулары милли тәрәккыйбез өчен җитәрлек түгел. Бөтен авыл халкының белемле булуын тәвәккъыф кыла [тоткарлый] торган ошбу мәсьәлә хәзердән уйланырга тиешле.

Бер мәшһүр язучыбызның «безнең милләт авылда» дигән сүзе хәтеремдә калган. Шулай булгач, авыл халкының тәрәккыйсе җәһәтеннән бу мәсьәлә әһәмиятле мәсьәлә булуы мәгълүмдер.

2

Имамнарыбызның кадерләре китү, мәгыйшәтләре тараюга тагы да сәбәпләр бар. Аларның берсе исә: имамнарыбызның кирәктән артык күбәюләредер. **Бездә бер имамга җитмәслек мәхәлләгә ике имам алу, бер мәхәлләгә дә кечкенә авыллар мәхәллә арттыру ягын карыйлар.** Моның да сәбәбе арабызда искедән бирле таралган бозык тәрбия кәсафәте [тупаслыгы] идеге мәгълүм. **Имамына дошманлык яки бер мәхдүмгә вә яки бай киявенә урын кирәк булуы сәбәпле алынган меллалар, салынган мәсҗедләр бездә бик күп очрый.** Мәхәлләдәге бер мәсҗедне (мәктәпне әйткән дә юк) тәэмин итә алмаган кешеләр икенчене салырга ашыгалар. Мәхәллә аерылып яңа мәсҗед салынган бер авылда, яңа мәсҗеднең манарасын күтәргән көндә, иске мәхәллә мәсҗеденең тузу сәбәпле манарасы җимерелеп төшүне мин үз күзем белән күрдем.

Инде һәр көн өстеннән мелла алыну яки мәхәлләсе аерылу хәвефендә булган мелланың, гавамга каршы килеп, үз фикерен кыюлык берлә сөйли алмаячагы мәгълүм. Өстеннән көндәш килү хәвефе булган татар хатыны иренә каршы нинди мөгамәләдә булса, мелла да мәхәлләгә шундый мөгамәләдә булынырга мәҗбүр.

Тагы моңа өченче бер сәбәп бар: мәгълүмдер ки, бездә борынгы вакыттан бирле дини мәдрәсәләр булына килгән. Бер адәм Бохарадамы, бүтән җирдәме торып азрак гыйлем тәхсил итеп кайтса, һичнәрсәгә карамый үзенең имам булган авылына дини мәдрәсә ачарга вә шәкерт җыярга керешкән. Сатыш, Мәчкәрә, Кышкар кеби иске мәдрәсәләрнең тарихына каралса, анда борынгы заманда Самара, Саратов, Уфа, Оренбург, Ханкирмән тарафларыннан шәкертләр булган. Әлбәттә, ул заманда ул тарафларда зур мәдрәсәләр булмагандыр. **Соңгы елларда исә дини мәдрәсәләр күбәеп, шәкерт җитми башлаган. Менә шуннан соң мәдрәсәләр вә мөдәррисләр арасында конкуренция башлана.** Һәр мөдәррис үз шәкертенә урын табарга тырыша. **Бер җирдә бер генә урын бушап мелла кирәк булса, утыз мәдрәсәдән 60 шәкерт килә. Гавам күрә: мелланы эзләп йөрисе юк, үзләре ялынып киләләр.** Инде мужик каравыл өендә аркасын ныграк терәп сөйли. Чөнки ул хәзер шушы 60 кеше борылып кайтып китсә, аның урынына 120 кеше киләчәк икәнен факт буларак белә. Башлана конкуренция, һәр мөдәррис үз шәкертен мактый, ул гына җитмәгән дип, шул мәдрәсәдә укып чыккан меллалар да эшкә килеп тыгылалар. Шулай итеп, мужик алдында меллалык урынының тәмам базарын төшергәч, никадәр кешенең хөббеннәфесе [мин-минлеге] мыскыл ителгәч, арадан берсе сайлана. Инде берәү шушы кадәр ялынулар илә меллалыкка кергәндә, ул кеше сайланганда үз файдасына нинди шарт куя алсын? Ничек итеп үзенең мәгыйшәтен тәэмин итү хакында халыктан вәгъдә алсын?.. Бер урынга шулкадәр кандидат булып торгач, гавамга үзен нинди шартлар илә бәйләсен?

Бер мелла кирәк авылда җыелган шәкертләрнең берсе: «Мин бернәрсә дә сорамыйм, Хода рәззак [ризык бирүче], ризыкны бирер», — дип гавамга нотык сөйләгәнен үзем ишеткәнем бар.

Инде берәү шушы кадәр ялынулар илә мелла булгач, гавам каршында

көтүче кадәрле дә кадере булмаячагы табигый. Инде бу мелла, гәрчә тәрәккъыйпәрвәр дә булсын, үзенең ризыгы киселүдән куркып гомере үтүе билгеле. Бу кеше күпме халыкны тәрәккъый юлына сала алсын?..

Менә минем фикеремчә, меллаларның кадерләре китү, елдан-ел доход киму — мәгыйшәтләре тараюга сәбәпләр шушылар.

3.

Дини мәдрәсәләрнең күплеге, меллаларның кадерләре киту, мәгыйшәтләре тараюга сәбәп булуны сөйләдек. Асыл сәбәпләрнең иң куәтлесе дә шул. 1914 нче елгы Казанский справочный календарь хисабына караганда, Казан губернасында меңгә якын мелла бар. Казан һәм губернасында мин белгәннәре генә дини зур мәдрәсәләр утызга тула. Утыз мәдрәсәдә ике мең кеше меллалыкка хәзерләнә. Бу утыз мәдрәсәнең өчесен генә калдырып, 27сен тәртипле рөшди [урта] мәктәпләргә генә әйләндерәсе бар. Казандагы Духовная семинария илә Духовная Академия никадәр җиргә рухани җитештереп торуы мәгълүм.

Шулай булгач, бер губернага өч дини мәдрәсә бик җитә. **Әгәр шул 27 мәдрәсә рөшдигә әйләндерелсә, милләтебез өчен зарар урынына файда китерер. Бу 27 мәктәптә 1500 күзе ачык, дөньяга тугры карашлы, тәрбияле мужик җитештереп булыр иде. Безнең өчен тәрбияле имамнар илә бергә тәрбияле мужиклар да һава илә су дәрәҗәсендә кирәк.** Һәр авылда мелла илә бер фикердә булырлык берәр генә тәрбияле мужик булса да, каравыл йорты илә мелла арасында тәрҗеман булу җәһәтеннән гаять мөһимдер.

Бер-ике дистә мелланың мөдәррис исемен күтәреп, халык арасында сыйланып йөрүе өчен генә булган дини мәдрәсәләребез рөшди мәктәпкә әйләндерелсә, аңа карап мөдәрриснең дәрәҗәсе төшмәс, бәлки кадере генә артыр һәм милли тәрәккъыйбез өчен дә олуг бер адым булыр иде.

Без ошбу эшне хөрмәтле мөдәррисләребезнең хәтерләренә төшереп милләтнең мөхакәмәсенә [хөкеменә] гарыз итәбез. Имамнар мәсьәләсен ислях вә аларның мәгыйшәтләрен тәэмин өчен иң тугры юл шушы булырга кирәк. Чөнки дини мәдрәсәләребез киметелеп, меллалыкка хәзерләнүчеләр азайса, Собраниядә имтихан мәсьәләсе дә үзгәртелеп, әһле булмаган кешеләргә бу мөкатдәс мәнсабкә [вазифага] керергә юл калдырылмаса имамнарның хәлләре үзүзеннән ислях ителеп, мәгыйшәтләре дә тәэмин кылыныр.

Бер урынга егермешәр кеше кандидат булу түгел, бәлки ул вакытта гавам үзе эзләп алыр. **Эзләп табылган нәрсәнең кадерле булачагы табигый.** Бу вакытта бер мелланың биш угылы бар икән, барын да меллалыкка хәзерләмәс, күбесен дөньяви юлга кертеп җибәрер. Моңарчы исә меллаларның бишәр угылы гына түгел, мелласымаграк байгуралар да угылларын меллалыкка хәзерлиләр иде. Матбугатыбыз тарафыннан кузгатылган имамнарга жалуния бирү, сайланганда тәэмин мәгыйшәт[1] вәгъдәсе алу кеби эшләр менә шул вакытта мөмкин булыр. Егерме буш урынга 200 кандидат булып торганда, ул эшләрне гамәлгә ашыру мөмкин булачак түгел.

Дәвамы бар

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде. ■

[1] Бу очракта хезмәт өчен хак, йорт-җир һәм башкалар күз алдында тотыла.

МУЗЫКАЛЬ КОЛЛЕКЦИЯ

Гүзәлия Җәләлева әзерләде.

Татарстан Республикасы Милли музееның музыка уен кораллары тупланмасында өч йөздән артык уен коралы саклана. Алар — Татарстан, Идел-Урал, Россия, ерак һәм якын чит ил халыкларыныкы. Тынлы уен коралларыннан биредә балчыктан ясалган таш сыбызгылар, камыштан, агачтан, металлдан эшләнгән флейта-курайлар, шыбырлар, гармуннарның төрле системасы, алты кырлы гармуннар, баяннар, аккордеоннар, металлдан һәм мөгездән ясалган быргылар; кыллы уен коралларыннан — гөсләләр, балалайкалар, думбралар, мандолиналар, фортепиано, рояльләр; мембраналы уен коралларыннан — барабаннар, шөлдерле барабаннар, мирлитоннар; тавышлы уен коралларыннан — металлдан ясалган кубызлар, кыңгыраулар, чаңнар, шакылдавыклар, тукмаклар һәм үзләреннән тавыш чыгара торган башка көндәлек тормыш әйберләре: механик уен коралларыннан — төрле музыкаль шкатулкалар, шулай ук тавыш яздыручы һәм тавыш чыгаручы җайланмалар — фонографлар, граммофоннар, патефоннар һ.б. бар. ■

ГЕРМАНИЯДӘ ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ БЕРЕНЧЕ БАСМА ТЕКСТ

Себастьян Цвиклински
Берлин әдәбият һәм мәдәният фәнни-тикшеренү үзәгенең фәнни хезмәткәре, фәлсәфә фәннәре докторы

Германиядә татар публицистикасының барлыкка килүе Беренче Бөтендөнья сугышы дәверенә бәйле. Алманнар ислам дөньясына йогынты ясар өчен панисламизм сәясәтен алып бара. Әлеге сәясәтнең төп максаты — мөселманнарны Англия, Франция һәм Рәсәйгә каршы баш күтәрергә өндәү. Германия хөкүмәте төрле телләрдә панисламизм идеяләрен пропагандалар өчен Чит ил эшләре министрлыгы каршында Көнчыгыш мәгълүмат үзәге (Nachrichtenstelle fur den Orient) оештыра. Гарәп, һинд һәм соңрак татарлар бу идеяне яклап, Германия Чит ил эшләре министрлыгы соравы буенча, Англия, Франция һәм Рәсәйгә каршы мәкалә, брошюра һәм китаплар язган. Германия җирендә басылган беренче татар текстлары да нәкъ менә Көнчыгыш мәгълүмат үзәге тарафыннан бастырыла. 1915-1918 елларда Германиядә дөнья күргән беренче төрки-татар газетасы «Әл-Җиһад» та әлеге сәясәтнең бер нәтиҗәсе[1].

Германия җирендә басылган беренче татар текстлары нәкъ менә Көнчыгыш мәгълүмат үзәге тарафыннан бастырыла.

Укучыларга тәкъдим ителгән текст «Әл-Җиһад» газетасы чыга башлаганчы ук, 1915 елның башында листовка буларак бастырылган. Мөгаен, әлеге язманы Германиядә татар телендә басылган иң әүвәлге текст, дип тә әйтергә мөмкиндер. Аның авторы — Туниста туган әл-җәзаирлы дин галиме Салих әш-Шәриф әт-Туниси (1869-1920). Галим Туниста Зәүтүнә дини университетында дәрес биргәннән соң, 1906 елда Истанбулга, аннары Дәмашкъка күченә. Ә 1914 елда янәдән госманлылар дәүләтенең башкаласына килә. Анда яшь төрекләр җитәкчесе Әнвәр паша белән танышкан әт-Туниси, Германиядә панисламизм сәясәтен үткәрү вазифасын ала. 1914 елның ноябрендә Истанбулда Англия, Франция һәм Рәсәй империясенә каршы җиһад игъланы да нәкъ менә аның тарафыннан укыла. Әт-Туниси, җиһад игълан ителгәннән соң, Берлинга килә һәм Көнчыгыш мәгълүмат үзәгенең төп пропагандистына әверелә. 1915 елның март аенда Истанбулга кайткан һәм шул ук елның азагында янәдән Берлинга килгән пропагандачы, Көнчыгыш мәгълүмат үзәге соравы буенча, тагын берничә текст яза. Гарәпчә язылган текстлар алман, рус, француз, итальян һәм татар телләренә дә тәрҗемә итеп бастырылган.

Укучыларга тәкъдим ителгән текстның бер нөсхәсе Германиянең Хайдельберг университеты китапханәсендәге Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында таратылган листовкалар коллекциясендә саклана. Ул факсимиле буларак 1990 елда алман тарихчысы Готтфрид Хаген тарафыннан бастырылган, әмма тәрҗемәсе бирелмәгән. Германия Чит ил эшләре министрлыгының сәяси архивында да документның бер данәсе бар. Без кулланган нөсхә исә шәхси архивыбызда саклана.

Текст татар телендә булса да, госманлы, Урта Азия төрки телләренең сүзләре белән чуарланган. Тагын бер күзгә ташланган үзенчәлек: рус сүзләренең һәм тел-стиль, орфографик хаталарның күплеге. Листовканы басмага әзерләгәндә текстның тел-стиль үзенчәлекләрен мөмкин булганча сакларга тырыштык, әмма орфографик хаталарны төзәттек.

[1] Германиянең ислам сәясәте турында кара: Себастьян Цвиклински. Габдрәшит Ибраһимның «Әл-Җиһад» исемле төрки-татар әсирләр газетасында 1915 елда басылган мәкаләләре // Чын Мирас. —2013. — №12. — Б.28-36.

Ислам хәлифәсенең хакында инглиз тарафыннан таратылган ялган хәбәрләр. Шәйх Салих әт-Туниси тарафыннан язылган.

اسلام خلیفه سینک حقنده
انگلیز طرفندن تاراتلغان یالغان خبرلر
«شیخ صالح تونیسی طرفندن یازیلغان»

معتبر استوچنیکدن آلنغان خبرلره کوره جناب لوید دژوردژ شریعتنی تنقید «قریتقه» ایدوب شولای ایته حضرت محمد پیغمبر دنیادن کیدکندان صکره آننک اورننه خدای تعالی طرفندن هیچ کم تعین قلنمغان. غزیته‌لرده سلرده شوفتوانی یازارغه لاکین سنزور طرفندن رخصت بیرلمگان.

این اول بز تلیمز ثبوت ایتک حضرت پیغمبرنک قارشی سنده خلیفه‌نک نه درجه‌ده اهمیه‌تی بولونی و آندان صون مینسترنک اوللاوسیز سؤاله جواب بیروب بزیم دلیل لریمزدن بللی بولور انگلیز حکومتی تریشقان دنیانی آلداترغه لاکین اوزننک یوروتکن پالیتقه سندن حاضرده آبدارب قالدی. هر بر امتکه خدای تعالی طرفندن کوندرلن پیغمبرلر امتلرینه تربیه و تعلم بیروب دنیانک بعض عش عشره تینه مشغول بولماسونلر و هر بر معتبر پیغمبرلر اوز درجه‌لرینه کوره خدای تعالی‌نک خلیفه‌سی بولغانلر.

داود پیغمبر حقنده قرآن شریفده حق تعالی حضرتلری شولای بویورغان یا داود سینی دنیاده مینم وکیلم اولاراق انسان عالمنه حاکم بولورغه تعین قلامن و دنیانک عشرتنه تابع وقول بولماچونکی

1 бит

Могтәбәр источниктан алган хәбәрләрә күрә, җәнап Ллойд Джордж[2] шәригатьне тәнкыйть «критика» итеп шулай әйтә: Хәзрәт Мөхәммәт пәйгамбәр дөньядан киткәннән соңра аның урынына Ходай Тәгалә тарафыннан һичкем тәгаен кылынмаган. Газетәләр теләсәләр дә шу[3] фәтваны язарга, ләкин цензур тарафыннан рөхсәт бирелмәгән.

Иң әүвәл без телимез — сөбүт[4] итик. Хәзрәт Пәйгамбәрнең каршысында хәлифәнең ни дәрәҗәдә әһәмияте булуны вә аннан соң министрның уйлаусыз сөаленә җавап биреп, бәзем[5] дәлилләремездән бәлли булыр инглиз хөкүмәте тырышкан дөньяны алдатырга, ләкин үзенең йөреткән политикасыннан хәзер дә аптырап калды. Һәрбер өммәткә Ходай Тәгалә тарафыннан күндерел[г]ән пәйгамбәрләр өммәтләренә тәрбия вә тәгаллем[6] биреп, дөньяның бәгъзе гаш гашрәтенә[7] мәшгуль булмасыннар [өчен тырышкан] вә һәрбер могтәбәр пәйгамбәрләр үз дәрәҗәләренә күрә Ходай Тәгаләнең хәлифәсе булганнар.

Давыт пәйгамбәр [хакында] Коръән Шәрифтә Хак Тәгалә [хәзрәтләре] шулай боерган: *«Я Давыт, сине дөньяда минем вәкилем уларак инсан галәменә хаким булырга тәгаен кыламын вә дөньяның гашрәтенә табигъ[8] вә кол булма, чөнки Ходай Тәгаләнең юлыннан, боерган тарикыннан[9] йөрергә манигъ[10] булыр».*

Ничек ки Хәзрәт Мөхәммәт пәйгамбәр дөньяда иң зур пәйгамбәрләрдәндер, димәк ки, аның вәкилләре дә зур кешеләрдер. Хәзрәт Пәйгамбәрнең дөньяга килүеннән максат инсаннарның намусын, хәясен[11] фәласуфи[12] тарикъ илә йөксәлтмәк вә инсаннарның кальбен саф вә бәдәннәрен куәтле калуына вәгазь вә нәсыйхәт иткән вә үзенең гадәләте сәбәбеннән инсаннарны бәхетле кылып, мөмкин кадәр дин ислам арасында иттифаклык куеп вә шулай ук күп инсаннар аңа табигъ булып[13] өммәт булганнар. Хәзрәт Пәйгамбәр инсаннарның кальбендә вә адәм нуры «ярык» халикь иткән вә Хәзрәт Пәйгамбәрнең күп дәлилләрен монда язуга

[2] Дэвид Ллойд Джордж (1863-1945) — инглиз сәясәтчесе, 1915 елда хәрби эшләр министры.
[3] шу — шул
[4] сөбүт итик — ышанычлы булыйк
[5] бәзем — безнең
[6] тәгаллем — өйрәнү, белем алу [тагълим булырга тиеш иде, әмма текстта тәгаллем дип яза]
[7] гашрәт — эчү, типтерү
[8] табигъ — иярүче
[9] тарикъ — юл
[10] манигъ — тоткарлаучы
[11] хәя - тыйнаклык
[12] фәласуфи — фәлсәфи
[13] табигъ булып — ияреп, буйсынып

урыны түгел. Хак Тәгалә тарафыннан боерылган иде Хәзрәт Пәйгамбәр дөньядан күчтектә[14] аның урынында вәкил булуы, вә бу вәкил лязим[15] Хәзрәт Пәйгамбәрнең эзе белән китеп, мәсәлән, инсаннар арасында гадәләтне йөксәлтеп вә анларны һәрбер җәһәттән дөньяда [мөхафәзә[16]] итеп вә мөхарәбә[17] өчен тәдаректә[18] булдырмалы һәрбер мөселман өчен фарыз. Пәйгамбәрнең хәлифәсенә итагать итү вә чакырса хәлифәнең сәнҗагының[19] астына җыелмалы. Хәлифәнең әмеренә итагать кылмаян[20] газапка мөстәхикъ[21] улыр, һәр гяһ[22] аның гозер шәргыйсе булмаса, әгәр дә гозере булмаенча итагать итмәсә[23] үлем җәзасы берлә газапланыр. Без хәлифәне пәйгамбәрнең вәкиле хисап итеп, аның һәрбер иҗтиһады пәйгамбәр куян[24] шәригатьне мөхафәзә итеп вә һәм хәлифә [Җәнап] Хак тарафыннан боерылган әмр[н]е иҗра кылдыгы[25] өчен Җәнап Хак вәкиле дия зурайтырга юлымыз бар.


خدای تعالی نك بو «لندن» بیورغان طریقدن یوروركه
مانع بولور.
نیچک کی حضرت محمد پیغمبر دنیاده ایک ضور پیغمبرلر
دن در دیک کی آنک وکیلاری‌ده ضور کشیلردر حضرت پیغمبر
نك دنیا غه کیلووندن مقصد انسانلرنك نا موسین حیاسین فلا
سوفی طریق ایله یوکسه لتمک وانسانلرنك قلبین صاف وبدنلرین
قوتی قانونه وعظ ونصیحت ایتکان واوزننك عدالتی سایندن انسانلرنی
بختلی قلوب ممکین قدیردین اسلام آراسنده اتفاقلق قویوب
وشولایوق کوپ انسانلرآنغه تابع بولوب أمت بولغانلر حضرت
پیغمبر انسانلرنك قلبنده وآدم نوری «یاریق» حلق ایتکان
وحضرت پیغمبرنك کوپ دلیل لرین مونده یازونمه اورونی
توگل. حق تعالی طرفندن یبورولغان ایدی حضرت پیغمبر دنیادن
کوچدیکده آنك اورونده وکیلی بولوی وبووکیل لازیم حضرت
پیغمبرنك ایزی بلن کیدوب مثلا انسانلر آراسنده عدالت نی یوکسه‌لتوب
وآنلرنی هر بر جهتدن دنیاده محافظت ایتوب ومحاربه اوچون
تدارکده بولدرمالی هر بر مسلمان اوچون فرض پیغمبرنك خلیفه‌سنه
اطاعت ایتو وچاقرسه خلیفه‌نك سنجاغنك آستنه‌جیلملی خلیفه‌نك
امرنیه اطاعت قلمیان غذاب که مستحق اولور هرکاه آنك عذر
شریعی‌سی بولماسه، اگرده عذری بولمانچه اطاعت ایتمسه اولم جزاسی
برله عذابلانور. بز خلیفه‌نی پیغمبرنك وکیلی حساب ایدوب آنك هر
بر اجتهادی پیغمبر قویان شریعتی محافظة ایتوب وهم خلیفه جناب حق
طرفندن بیورولغان امری اجراقیلدیغی ایچون جناب حق وکیلی دیبه
ضورایترغه یولمز بار.
حضرت ابوبکرصدیق زماننده أمت اسلام همه‌سی بریرده
متفق بولغانلر ایدی لاکین آخرده اسلاملرنك اتفاقلق بوزولوب
٢

2 бит

Хәзрәт Әбү Бәкер садыйк[26] заманында өммәте ислам һәммәсе бер йирдә[27] мөттәфикъ[28] булганнар иде, ләкин ахырда исламнарның иттифаклыгы бозылып ислам арасында һәртөрле җенесләр булып вә һәр җенес кәндисенә[29] бер рәис (ягъни баш) сайлап үзләренә бер идарә кыльдылар вә шу кагыйдә Төркия дәүләте булганга кадәре давам итте. Солтан Сәлим беренче[30] габбасыйларның ахырынча хәлифәсеннән хәлифәлекне теләде вә бу кеше [солтанны] хәлифә булырга һәр җәһәттән хаклы [табып], үзе хәлифәлектән төшеп хәлифәлеген солтанга бирде. Вә бу җәһәттән җөмлә[31] дөньяда булган исламнар[32] яңадан мөттәфикъ булып бер хәлифәгә итагать кылдылар, вә бер төрекләрдән булган хәлифәгә шәрыктә вә гаребтә (көнтугышта вә көнбатышта) булган исламнар итагать иттеләр вә Тунис, Алжир, Мисыр, Судан, Гарәбстән, Ирак, Месопотамиядәге [мөселманнар] һәм бергә булдылар. Вә шу бәхетсезлек вә мөселманнарның араларында булган салкынлык дошманнар[г]а форсат биреп, анлар ислам арасында һәртөрле дошманлык таратмак белән, бере берсеннән аермак белә тәфрика[33] кылып, исламнар ахырда үз дошманнарына кол вә әсир булдылар.

[14] күчтектә — күчкәндә
[15] лязим — тиеш
[16] мөхафәзә — саклау, яклау
[17] мөхарәбә — сугыш
[18] тәдарек — хәзерлек
[19] сәнҗак — байрак
[20] кылмаян — кылмаган
[21] мөстәхикъ — лаек
[22] гяһ — вакыт
[23] итагать итмәсә — буйсынмаса
[24] куян — куйган
[25] иҗра кылдыгы — үтәү, җиренә җиткерүгә
[26] садыйк — туры, дөрес
[27] йирдә — җирдә
[28] мөттәфикъ — фикердә берләшкән, союздаш
[29] кәндисенә — үзенә
[30] Солтан Сәлим I. (1470-1520)
[31] җөмлә — барлык
[32] мөселманнар мәгънәсендә
[33] тәфрика — бер фикердә булмау


اسلام آراسنده هر تورلی جنس‌لر بولوب و هر جنس کندی سینه
بر رئیس (یعنی باش صایلاب اوزلرینه بر اداره قلدیلر) وشوقاعده
ترکیه دولتی بولغا نغه قدری دوام ایتدی سلطان سلیم برانچی
عباسیلرنک آخیر نچی خلیفه سندن خلیفه لکنی تله‌دی و بوکنی
سلطان نک خلیفه بولورغه هر جهتدن حقلی طاوب اوزی خلیفه
لکدن توشوب خلیفه لکنی سلطا نغه بیردی و بو جهتدن جمله
دنیاده بو لغان اسلاملر یا نه‌دن متفیق بولوب برخلیفه‌گه اطاعت
قلدیلر و بر ترکاردن بو لغان خلیفه‌گه شرقده وغربده «کون
توغوشده وکون با تشده» بو لغان اسلاملر اطاعت ایتدیلر و تونس
آلژیر مصر سودان عربستان ایراق وبیسا با تا میه‌ده‌گی سلمانلرهم
برگه بولدیلر وشو بخت سیزلیک ومسلمانلرنک آرالرینده بو لغان
سالقین لیق دوشمنلره فرصت بیروب آنلر اسلام آراسنده هر تورلی
دوشمنلق تارا تماق بلن بری برسندان آیرماق بله تفریقه قلوب
اسلاملر آخرده اوز دوشمنلرنیه قول واسیر بولدیلر.
لاکین حاضرده ممکین ایترگه اسلاملرینک خالی بتونله‌ی با شقه
بولغان دوشمنلر اسلامره قارشی نک قیلغان ناچار لقلری باریره
اوزلرینه قایتوب توشدی و مسلمانلرنی ایسکی برلکنه قایتارورغه
سبب بولدی.
مسلمانلربله‌لر آنلرنک دوشمانلری هرتورلی حیله لربلن
مسلمانلرنی ودینی لرنی بتروب خلیفه لیکنی بترو بلن اسلام طائفه
سنک آرالرینده بولغان رابطه‌نی «یعنی اسناشینیا» نی اوزوبرله
باشقه پادشاه لقلر قول آستنده بولغان مسلمانلربله اسوایه‌زانی یعنی علاقنی
بتروب وشمدیکی وقتده اوزلرینک حریت لیکی اوچون چالشقان
مسلمانلرنی بترمک نیه‌تنده ایدیلر. الحاصل اسلامنک دوشمانلری
یریوز ونده بولغان ۳۵۰ ملیون مسلمانی بترومک نیتده درلر لاکین

3 бит

Ләкин хәзер дә мөмкин әйтергә: исламнарның хәле бөтенләй башка булган. Дошманнар[ның] исламнар[г]а каршы [нык] кылган начарлыклары бар йирә[34] үзләренә кайтып төште вә мөселманнарны иске берлегенә кайтарырга сәбәп булды.

Мөселманнар беләләр: анларның дошманнары һәртөрле хәйләләр белән мөселманнарны вә диниләрне бетереп хәлифәлекне бетерү белән ислам таифәсенең араларында булган рабитаны[35] (ягъни отношение)не [бозу] берлә башка патшалыклар кул [астында] булган мөселманнар белә [связьны], ягъни [галяканы][36] бетереп, вә шимдики[37] вакытта үзләренең хөрриятлеге өчен чалышкан[38] мөселманнарны бетермәк ниятендә иделәр. Әлхасыйль[39] исламның дошманнары йир йөзендә булган 350 миллион мөселманны бетермәк ниятендәдерләр, ләкин анларның бу тугрыда олы хаталыклары бар, чөнки көнбатышта булган, көнтугышта булган бөтен мөселман эчендә һичбер кеше табылмас хәлифәне кабул итмәгән мөселман.

Һәр гяһ исламнарның дошманнары тырышсалар да мөселманнар арасында булган иттифакны бетереп вә мөселманлыкны хәкарәт иту[40] белән Мисырда икенче бер солтан тәгаен иттерсәләр дә, ләкин буларның[41] бу гакылсыз политикаларында күп зур хаталыклары булып, гаксенә[42], мөселманнарның бигрәк тә тәрәккыйсенә вә алга баруына сәбәп булдылар, вә һәр кәс[43] беләдер дошманнар ислам арасында фетнә салып вә дошманнарның ниндәй фикердә булдыкларын һәркемгә мәгълүм булды.

Әгәр дә Аллаһы Тәгалә бер милләтне [бетерергә] керешсә, буннан котылмакның һич имкяны[44] юк. Хәзердә [Җәнап] Хак исламның дошманнарын бетерергә кереште, чөнки анлар бөтен исламнарны бетерергә ниятләре булуы өчен.

Ахырда һич кемсә качып котыла белмәс, үзенең иткән гөнаһына вә җинаятенә каршы киләчәк бәладан. Бу сурәттә сездән дә (ягъни дошманнардан да) кыйсас[45] алыначак вакыт йитеште. Сезләргә бәладан качып котылырга һич имкан юк, Җәнап Хак бераз сабыр итсә дә, бу эшләдегез эшләрне һич кичерәчәк түгел, сезнең (ягъни дошманнарның) бетәчәк көннәрегез якынлашты вә без сезнең бу көннәрегезне көтәмез. ■

[34] йирә — жиргә
[35] рабитаны — мөнәсәбәтне
[36] галяканы — бәйләнеш
[37] шимдики — хәзерге
[38] чалышкан — эшләгән
[39] әлхасыйль — нәтиҗәдә
[40] хәкарәт иту - хурлау
[41] буларның — боларның
[42] гакесенә - киресенә
[43] кәс — кеше
[44] имкяны — чарасы
[45] кыйсас — үтерүчене үтерү


آنلرنک بودوغریده اوللی حظالقلری بار چونکی کون باتشده بولغان
کونتوغشده بولغان بتون مسلمان ایچنده هیچ برکشی تابو لماس
خلیفه‌نی قبول ایتمه‌کان مسلمان.
هرگاه اسلاملرنک دوشمانلری ترش سالرده مسلمانلر آراسنده
بولغان اتفقانی بتروب و مسلمانلقنی حقارت ایتوبلن مصرده ایکنچی
بر سلطان تعین ایتدرسه‌لرده لاکین بونلرنک بوعقلسیز پالیتقه‌لرینده
کوپ ضور خطالقلری بولوب عکسنه مسلمانلرنک بیگرکده ترقی
سنیه وآلغه بارونه سبب بولدیلر و هر کس بله در دوشمانلر
اسلام آراسنده فتنه‌سالوب و دوشمانلرنک نینده‌ی فکرده بولدوقلرین
هرکیمگه معلوم بولدی.
اگرده الله تعالی برملتنی بترور وگه کیرشسه بوندان قوتولمقنک
هیچ امکانی یوق حاضرده جناب حق اسلامنک دوشمانلرینی بتورورگه
کرشدی چونکه آنلربتون اسلاملرینی بترورگه نیت لری بولوی اوچون.
آخرده هیچ کیمسه قاچوب قوتولابلمز اوزینک ایتکن گناهنه
وجنایته قارشی کله‌چک بلادن بو صورتده سیزدنده «یعنی دوشمانلردنده»
قصاص آله‌چاق وقت یتشدی سزلرگه بلادن قاچوب قوتلورغه
هیچ ایمکانی یوق، جناب حق برآز صبر ایتسه‌ده بو اشله‌دگیز
اشلرنی هیچ کیچره‌جک توگل، سیزنک «یعنی دوشمنلرنک» بته
جک کونلرگز یاقنلاشدی وبز سیزنک بو کونلرگزنی کوته‌من.

4 бит

СИБГАТ АГА ҖЫРЛЫЙ...

Алмаз Хәмзин

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның, кәттә-хәтәр йөзү марафоннары оештырып, Казансу-Иделләрне иңләп-буйлап йөзеп йөргән дәртле чаклары… 1983 ел. Җәй.

Киң Иделгә сибелгән Маркиз утрауларының берсеннән, кичке нурларга төренеп, моңсу җыр агыла. «Юксыну».

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмыйм —
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Шакир Мәҗитовның Сибгат Хәким шигыренә язган җыры бу. Сибгат ага үзе җырлый (*Айрат Садыйк фотосы. Матбугатта беренче мәртәбә басыла.* — ***Ред.***)! Мин, мәшһүр шагыйребезнең салмак кына җырлаган тавышын басып китмәс өчен, тыныч кына баянымны тартам. Сөйләгәндә дә җанны иркәли торган тавышлы диктор Эльс Гадел Сибгат абыйга караган да, дөньясын онытып, шагыйрьнең иреннәрен кыймылдатып кына җырлавына шаккатып калган. Күрәсең, ул мондый могҗизаны гомерендә беренче мәртәбә күрә һәм тыңлый. Рәсемгә карагач та хәтерләдем: әйе, күренекле рәссамыбыз Рәшит Имаш ул вакытта шагыйрьнең бу халәтен кәгазьгә төшерә иде ләбаса. Җырчысы нинди бит! Җырчысы!!! Ә мин, бәлки, шагыйребезне җырлаткан бердәнбер баянчы булганмындыр да әле?..

Хәтердә: «Юксыну»дан соң без аның сүзләренә Мансур Мозаффаров язган җырны:

— Туып-үскән шушы җирнең ямен
Алыштырмый икән һичнәрсәң.
Башка берни дә кирәкми,
Үзем чапкан печәннәрне
Бер туйганчы иснәсәм, — диеп тә җырладык.

Шул утрауда җырлашканнан соң, Сибгат абый белән шактый еш очрашырга, җырлау вакыйгасын искә төшереп, сөйләшеп торырга туры килде. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта әйтте Үгделмеш: – Илбигем,
Данлысың халыкта, холкың билгеле.

Аңар әйттем инде кайтыр чагымда:
– Җибәрәчәк мине илбик тагын да.

Болай гына куймас, китерер сине,
Бүген үк булмаса, иртәгә, – дидем.

Мине дүнелдерде, «янә килмә», дип,
Барачак түгелмен, көчлек кылма, дип.

– Ярый, – диде илбик, – ишеттем сүзең,
Бу сүз эшкә кермәс, янә берүзең.

Ничек була инде, бу нинди гыйллә,
Шуны китермәсәм, күңелем теләп.

Ирлекме бу – мин баш булып халыкка,
Көчендә булмаса минем ярлыклар.

Егетлек билгеседер ул, мөгаен,
Теләгең үтәргә табалсаң җаен.

Янә дә, чир-ауру булыр теләгем
Үтәп, имләмәсәң, юкса үләмен.

Ни диләр, тыңла һәм укы бу бәйтне –
Төшен мәгънәсенә, и тәхтем бәхте:

Бөтен дәрт – чиргә бар дару вә дәрман,
Төгәл әйтер – сора имләүче камнан[1].

Күңел – җан чирләре илә авырса,
Терелер, билгеле, теләге булса.

Ә Үгделмеш әйтте: – Котлы хөкемдар,
Даруы булмаган нинди чирләр бар?

Илбигем исән-сау теп-тере булсын,
Аның өчен җанын бирерлек колмын.

Сүзем хак, күңелем ихластыр минем,
Ни мәгънә ел буе үкенсәң, бийем?

Ни ди акыллылар, ишеттең, туган:
Сүзеңне сүз ит – бул чын бер пәһлеван.

Никадәр файдалы әйтмәсәң ләм-мим!
Үкендерде мине бу юлы телем.

Сөйләмәгән сүзең сиңа кол була,
Ә инде сөйләсәң, сине кол кыла.

**Ирлекме бу – мин баш булып халыкка,
Көчендә булмаса минем ярлыклар.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Кам – төрки халыкларда мәҗүси рухани һәм дәвачы. «Котайткыч белем»дә бу сүз еш кына очрый.

**Сөйләмәгән сүзең сиңа кол була,
Ә инде сөйләсәң, сине кол кыла.**

Сүзеңне хисаплап сөйлә, ашыкма,
Җәрен үкенерсең, бүген ашыксаң.

Сизенмәдем инде, күр, Уйгырмышны
Чакыргач, килмәс дип, ул ич ир кеше.

Син, илбик, телисең аны, мин – күбрәк.
Галим килсә, көндә файдасы тияр.

Минем белән бергә – бар теләгәнем шул –
Хезмәт итсә иде кул тотынышып.

Ничек кенә каты тотсам да сүземне,
Карышты ул тәмам, ят итте безне.

Янә бару кирәк икән, мин барыйм.
Тагын бүтән сүзләр дә әйтеп карыйм.

Янә бер хат язып җибәрсен илбик,
Укысын, ышансын, нишләр ул – күрик.

Тик илбик әйтте: – Мин бер хат җибәрдем,
Шуңа җавап алдым, шунсы җитәр, дим.

Янә ничек итеп языйм хат-бөтек?
Бөтек урынына син үзең, җитез.

ҮГДЕЛМЕШ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш: – И, котлы илбик,
Шулай булса да син яз янә бөтек.

Илче нинди чичән булса да гәрчә,
Язусыз чын җавап китермәячәк.

Язу таныганча таныш ул язу,
Язу булса йөрми хәйлә-алдашу.

– Теләгең шул булса, хуш, – диде илбик –
Сүз мәгънәсен ачып язу күндерик.

– Язу кирәк, ләкин, и зирәк белкә,
Шунсы бар, ышанма һәрбер бөтеккә.

– Ярый, сүзең булсын тере телеңдә.
Минем янга килсен, син шуңа өндә.

**Сүзеңне хисаплап сөйлә, ашыкма,
Җәрен үкенерсең, бүген ашыксаң.**

ИЛБИКНЕҢ УЙГЫРМЫШКА ИКЕНЧЕ ХАТЫ

Дәвәт-кәгазь сорап алды да илбик,
Каләм тотты кулга һәм язды бөтек.

Ходай аты берлә башлады сүзен:
«Түрәткән, ашаткан, яшәткән — Үзе.

Мең мактаулар әйтәм уган Тәңрегә –
Хөкеме битараф төз вә кәкрегә.

Бер Ул, иптәшсез вә тиңсез пакь, ару,
Бар итә Ул юкны, юк итә барны.
Аны, бердәнберне, тот син күңелдә,
Гыйбадәт кыл, исме булсын телеңдә.

Ни сораса була теләгәнечә,
Нәрсә «булсын» дисә, шуңа ирешә.

Сиңа сүзләр әйттем – шикәрдән татлы,
Агулардан ачы җаваплар алдым.

Җаны тибрәлгәнчә бирә терелге[2]
Тереклеккә каршы куйган үлемне.

Кадер-кадерсезлек аның хөкмендә,
Юл ача олыга һәм дә кечегә.

Теләгенә һичкем чикләр куялмас,
Каза кундерсә дә һичкем тыялмас.

Сөекле сәүчегә төмән мең сәлам,
Аның юлын безгә күрсәтсен Аллам.

Бөтен кылганына аның һәрдаим,
Бары мактау гына әйтсен Ходаем.

Иң элек – күп мәдех һәм йөз мең сәлам
Күндерәмен сиңа, акыллы – галләм[3].

Кәефеңне сорап бөтек җибәрәм:
Нихәлдә яшисең, белкә-мөхтәрәм.

Кардәшеңне сиңа җибәргән идем,
«Теләгем шул – миңа килгәйсең», дидем.

Мәелең булмады безгә килергә,
Миңа төшәргә һәм йөзем күрергә.

Хатыма җавапны язгансың үзең,
Кардәшең аша да беленде сүзең.

Укыдым бөтекне, уең беленде,
Тик сүземне ишет – качынма инде.

Сиңа сүзләр әйттем – шикәрдән татлы,
Агулардан ачы җаваплар алдым.

Янә сүзләремне тыңла вә ишет
Һәм ал күңлемә, и, изге кешем.

Гыйбадәтең булсын, шул атың өчен,
Тик син зая кылма тән вә рух көчен.

Яшисең син, заһит, таулар эчендә,
Заһит даның менә шуның өчен дә.

Шушы атың-чабың ерак җәелде,
Адәмнәргә бөек үрнәк, диелде.

Гыйбадәтең булсын, шул атың өчен,
Тик син зая кылма тән вә рух көчен.

Булыйм ил күзендә бер изге дисәң,
Гыйбадәт мәгънәсе бозыла төптән.

Хакка чын гыйбадәт була өртүле,
Нәрсә сөйләсә дә бу хакта телең.

Ходай гизли[4] иң-иң сөекле колын,
Илдә һәркем белми аларның юлын.

Бире кил, илеңдә генә яшә син,
Ник сиңа «ул изге» дигән ат-исем?

Хәләл хезмәт белән яшәү – изгелек,
Һәр ике дөньяга ашау – кигелек.

Хәләл мал тап, шуңа үзең тиенгәч,
Ачка аш бир, киемсезгә — киемнәр.

Хәләл хезмәт белән яшәү – изгелек,
Һәр ике дөньяга ашау – кигелек.

Бу сүзне ишет, и, миңа килмәгән,
Ару белкәләр дә шулай дигәннәр:

Ходай колларына һәрчак ярдәм кыл,
Кешегә булышлык итү – ирдәмлек.

Яшә, дип, мөселманнар файдасына,
Сине, заһит, куам ил арасына.

Дәваламасаң һич моның моңлының,
Үлемгә тиң синең заһит булуың.

Кешеме ул үзен генә белүче?
Кешедер шул — хәстәр күрсә ил өчен.

[2] Терелге – «яшәргә мөмкинлек», «сәламәт яшәү мөмкинлеге».
[3] Галләм — «бөтенесен белүче».
[4] Гизли — «яшерен тота, яшерен асрый».

Мал өләшү генә юмартлык түгел
Юмарт син ил-көнгә бирелсә күңлең.

Шәфкатьле затмы тик үзен саклаган?
Шәфкатьле син кеше хакын хакласаң.

«Изге кеше», диләр, ул кайсы икән?
Син әйтеп бир әле, и батыр белкә.

Минемчә, изге зат шундый бер кемсә,
Кешегә ярдәмле, бер афәт килсә.

И, изге, пакь кеше, бик тә белемле,
Бу сүзгә бер күз сал, булсаң фәһемле.

Дөресме әйткәнем яки түгелме?
Дөрес булса, күн дә, күтәр күңелне.

Күп сөйләсәң нинди сүз дә җиләтә,
Акыллылар сүзгә саран бигрәк тә.

Тәмам итим сүзне, сөйләмим бүтән,
Акыл-белемеңә, хәтта, бәйләп тә.

Тагын сүзләрем бар әле, аларны
Акыллы кардәшең сөйләр, аңлатыр.

Төгәтте, корытты, бәйләде каты,
Каләмен юды һәм пичәтләп хатны,

Сонды Үгделмешкә кулына биреп.
Тегесе алды зур әманәт белеп.

–Тырыш, – диде илбик, – тырыш ничек тә.
Килсен ул шәһәргә, керсен ишеккә.

Ни теләсә шуны, бу җиргә килеп
Утырса, бирербез, чарасын күреп.

– Ярый, – дип озамый[5] чыкты Үгделмеш,
Чабып килде өйгә – көтми изге эш.

Өенә керде һәм уйлап утырды,
Ашады, эчте һәм намаз укыды.

Шәфкатьле затмы тик үзен саклаган?
Шәфкатьле син кеше хакын хакласаң.

Руми кызы[6] йөзен тәмам яшергәч,
Зәнги йөзе[7] шәүлә төшерде җиргә.

Тиз үк күккә иңде каракош төсе,
Һаваны тутырды төн пәрәвезе.

Түшәк сорап ятты, уйлады тагын
Ни сөйләргә кардәш күзенә багып.

Оеп алды бераз, уяу каранды:
Төн суп-суык күмер кебек караңгы.

Йокы качты, басты ул аягүрә.
Төн күтәрә иде итәген үргә.

Кояш чыкты, җирдән күтәрде башын,
Ягымлы елмайды, күрсәтеп тешен.

Бәк[8] тәһарәт алды, кылды таңнамаз,
Намазы соң дога укыды бераз.

Атын тотып килде бер җитез углан
Һәм бәк чапты – күңле өметкә тулган.

Әкрен генә барып капка шакыды,
Кардәш чыкты. Намаз укыр чак иде.

Уйгырмыш җитәкләп кулыннан тотты,
Кул үбеп, хөрмәтләп, түргә утыртты.

Диде: – И, кардәшем, ни мәшәкать тә
Нигә килдең бүген шушы сәгатьтә.

Кистереп әйттем ич, ишеттең ачык,
Нигә килдең тагы бәгъремә басып.

Ни ди, ишет, әнә белек биргүче,
Сынап, яхшы-яман кеше белгүче:

Минемчә, изге зат шундый бер кемсә,
Кешегә ярдәмле бер афәт килсә.

[5] Озамый — «озак тормый».
[6] Руми кызы – борынгы төрки поэтик телендә кояш, якты көн символы.
[7] Зәнги – негр, поэзиядә төн символы.
[8] Бәк – инде әйтелгәнчә «асылзат; әфәнде».

Бер күрүдә белеп була кешенең
Сөярен-сөймәсен, ишетеп бер сүзен.

Бер күрүдә белеп була кешенең
Сөярен-сөймәсен, ишетеп бер сүзен.

Бакырны алтыннан аералмасаң,
Игәүләп бер ышку җитә ләбаса.

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Кардәшем,
Яралы күңелгә каты бәрмә син.

Сүзеңне илбиккә әйттең хат юллап,
Мин дә әйттем аңа ачык тәфсилләп.

Менә сиңа җавап – җибәрде бөтек,
Дип Үгделмеш хатны чыгарып бирде.

Уйгырмыш ул хатны кулына алды,
Ачып укыды һәм уйларга талды.

Үз-үзенә әйтте: – Бу нинди эштер,
Нишләп мин мондый бер мөшкилгә төштем.

ҮГДЕЛМЕШ БЕЛӘН УЙГЫРМЫШНЫҢ ИКЕНЧЕ МӨНАЗАРАСЫ

Җавап бирде телдән Үгделмеш шунда:
– Сүземне, и, кардәш, ишет вә тыңла.

Илбикнең теләге – сиңа изгелек,
Үзенә дә тели синнән игелек.

Беләсең, бу җирдә дә гыйбадәт күп.
Шулай ук яхшы вә яман гадәт күп.

Әйткәнемчә, шәһәр һәм дә авылда
Изгелек эшләргә урын күп була.

Бу дөньяның коты бик явыз түгел,
Савап казанырга мөмкинлек күп ул.

Дөньяга кул селтәп, заһид икәнсең,
Изге дигән исем алып китәрсең.

Бу дөньяның коты бик явыз түгел,
Савап казанырга мөмкинлек күп ул.

Ләкин начар мени байлык, югыйсә,
Үзең дә кулланса, илгә дә бирсәң.

Нинди шәп сүз әйткән бер казна башы
(Укы син игътибар илә дус кеше):

– Гадәттә, маллы зат – күп белгән кеше,
Ләкин игелектән дә дүңгән кеше,

Тик малсыз да начар – нишләмәк кирәк.
Күккә ашыйм дисәң, мал-баскыч, терәк.

Хаҗга барыйм дисәң, булмыйдыр малсыз,
Газый булыйм дисәң дә булмый ансыз.

Ярдәм итим дисәң илгә, дусларга,
Мал-мөлкәт булмаса, кулың кыскарак.

Һәм изгеләрне дә ничек якларсың?
Изге үгет сүзен генә тапларсың.

Тагать-гыйбадәткә өмет тайгактыр:
Күп тагать кылдым дип, мактанмыйрак тор.

Ходайга җитәме һәр дога кылу?
Бик тә нечкә нәрсә табыну юлы.

Гомер буе меңнәр гыйбадәт кылып
Ахыр җан бирделәр, имансыз булып.

Әлбәттә, догага сөенә Ходай,
Гыйбадәтең безгә дә шатлык, агай.

Ләкин беленмидер дога чынлыгы,
Төгәл дөреслеге һәм кабуллыгы.

Кабул булса гына барча тагатең,
Тик шартына килсә булыр ул татлы…

Колак салып тыңла бу сүзләремне:
Мин дөрес әйттемме, йә әйтмәдемме?

Синең дә сүзләрең булса гел дөрес,
Гамәл кыл тиешчә, и, күңеле төз.

Һәвәс коллыгыңа күңел бирмичә,
Кешеләргә катыл, яшә гадичә.

Дәвамы бар ■

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Вакытсыз азан әйткән мәзиннәр яисә вакытсыз чиркәү каккан звонарьлар була инде. Ул гына түгел, котырган әтәчләр дә булгалап, алар йокысының дәкыйкасе[61] алтын булган мужик халкын алдан уяталар.

***

● Әй гөнаһсыз яшь бала!.. Пакь җаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең[62] пакь синең; син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

● «Сөбханалла», диеп әйтү тиеш, ...бер мән яңа гына туган айны күрсә.

● Яңа ел алдыннан күргән төш хәерле була.

● Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый улдыгы кеби, кызганырга лаек инсаннарны да ифрат дәрәҗәдә кызганырга кушуы да табигыйдер.

***

● Мөэмин булсаң, чын мөэмин бул — намазыңны калдырма.

● Бездә җомга көннәргә дә бер дә игътибар юк: ул көннең бәйрәмлеге бер дә күңелдән хис ителми.

● Бәгъзеләребез бик суфи, көн дә биш намаз укый — бурычка йөз мең алгач, аны кесәгә салгач.

● Хак Тәңренең каршысында килешмидер тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ.

● Динле булып күренү бик яхшы бер кәсеп ул. Ихтимал, сез дә шул файдалы кәсепкә керешергә кызыга торгансыздыр — котлы булсын, туганкай, сәүдәгез, котлы булсын!

***

● Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә.

● Бер дә исеңез китмәсен: Мәккәи мөкәррәмәдәге кәгъбә янында гөнаһ кыйлу мөмкин булган шикелле, Киевтәге монастырь янында савaплы эш кыйлу мөмкиндер.

● Наданлык сәбәпле көфергә төшү җиңел инде.

● Җәза бирми халык һич тә гөнаһ эш, яшерен эшләргә, куша анчак кеше сизмәс рәвештә яшерен эшләргә.

● Җәзалау камчысын биргән гөнаһлы ул халыкка кем? Түгел, юк! Бирмәгән һичкем; Ходай — гадил, Ходай — хаким!

● Бер кешене кяфер дип йөрү бик зур кабахәтлектер.

● Вакытсыз азан әйткән мәзиннәр яисә вакытсыз чиркәү каккан звонарьлар була инде. Ул гына түгел, котырган әтәчләр дә булгалап, алар йокысының дәкыйкасе[61] алтын булган мужик халкын алдан уяталар.

***

● Әй гөнаһсыз яшь бала!.. Пакь жаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең[62] пакь синең; син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

● «Сөбханалла», диеп әйтү тиеш, ...бер мән яңа гына туган айны күрсә.

● Яңа ел алдыннан күргән төш хәерле була.

● Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый улдыгы кеби, кызганырга лаек инсаннарны да ифрат дәрәҗәдә кызганырга кушуы да табигыйдер.

***

● Мөәмин булсаң, чын мөәмин бул — намазыңны калдырма.

● Бездә җомга көннәргә дә бер дә игътибар юк: ул көннең бәйрәмлеге бер дә күңелдән хис ителми.

● Бәгъзеләребез бик суфи, көн дә биш намаз укый — бурычка йөз мең алгач, аны кесәгә салгач.

● Хак Тәңренең каршысында килешмидер тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ.

● Динле булып күренү бик яхшы бер кәсеп ул. Ихтимал, сез дә шул файдалы кәсепкә керешергә кызыга торгансыздыр — котлы булсын, туганкай, сәүдәгез, котлы булсын!

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

[61] Дәкыйка — минут;
[62] Вөҗүд — күцел, рух;
[63] Һиммәт — юмартлык;
[64] Игълам итү — белдерү.

ГОБӘЙДУЛЛИН Рәшит Гомәр улы (1931-2000), композитор. Т.ның әдәби мирасына нигезләнеп язылган әсәрләр арасында «Кисекбаш» балеты (1959) яшь композиторның бу катлаулы музыкаль жанрның серләрен әле үзләштерә генә башлаган чорына карый. Аның либреттосы авторы (Ә. Фәйзи), шагыйрьнең «Печән базары», яки «Яңа кисекбаш» әсәренә нигезләнеп иҗат ителгән. XIII-XIV гасырлар шигъри ядкяре «Кисекбаш»та Мөхәммәт пәйгамбәрнең могҗизалы көче тасвирлана. Әлеге язма җыентык нигезендә 1917 елга кадәр, мәктәпләрдә дини дәресләр укытканнар. «Кисекбаш» балетында Т. поэмасында чагылган сатирик яңгыраш чагылмый. Әсәргә яңа персонажлар кертелә: Шагыйрь, циркта уйнаучы, Хаҗиның яшь хатыны Мәдинә. Халыкның социаль катламын барлау, байлар һәм ярлылар темасын күтәрү — шулай ук либреттоның үзенчәлеге. Персонажлар күп булу аркасында төп идея югала, лирик як өстенлек итә. Оркестровкада да классик формадан тайпылыш сизелә. Композитор сатирик якны күрсәтү өчен күбрәк унисон ысулын куллана. Шулай ук татар халык җыры «Әйе, шул»ны цитата формасында яңгырата. Әсәрнең интонацион үзенчәлеге композиторның «Бәдәвам» китабына кергән мөнәҗәтләрнең көйләрен куллануда чагыла.

Э.М.Галимова

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

Әдәбият: Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Г.Тукая. Изд-во КГУ. 1964. 84 с.; Исхакова-Вамба Р.А. Тукай и татарская музыка. К.: Издательский Центр Госкомстата РТ. 1997. С.72-74; Кантор Г. Рашид Губайдуллин // Композиторы Татарстана. М., 2009. С.74-75; Нигмедзянов М.Н. С.149.

ГОБӘЙДУЛЛИНА Гөлнур Билал кызы (1960-2011), музыка белгече, педагог. Берничә фәнни хезмәте шигырь һәм «моң»ның структур-тематик бәйләнешләре мәсьәләсенә багышланган. Тикшерү объекты буларак исә XX гасыр башы татар шагыйрьләре сайланган, иң әүвәл — Т.ныкы. «Тукай һәм татар камера-вокаль музыкасы», «Татар халык җырының Тукай поэтик фикерләвенә йогынтысы», «Музыкаль ритмо-интонациянең татар шигырь төзелешенә йогынтысы» һ.б. мәкаләләрендә төп фикерләр «XX гасыр башы татар поэзиясе һәм музыкасының үзара йогынтысы» исемле кандидатлык диссертациясендә гомумиләштерелә. Автор Т. шигъриятенең халык музыкаль традицияләре белән тыгыз бәйләнешен ачыклый (эчтәлек, форма, жанр төрләре, ритмик үзенчәлекләре дәрәҗәсендә). Шигъриятнең «музыкальлеге» Т.ның тел концепциясе һәм сәнгати фикерләвенең бер өлеше буларак дәлилләнә. Шигырь төзелешендә ике системаның катнашу үзенчәлеге (силлабика һәм гаруз) музыкаль интонация (традицион мелодик-ритмик формулалар) йогынтысында барлыкка килү турында гипотеза чыгарыла.

Г.Г.ның XIX-XX гасырларда татар мәдәнияте мәсьәләләре буенча «Шәрык» клубы эшчәнлеге белән бәйле мәкаләләрендә Т. укыган «Халык әдәбияты» (1910) лекциясе, Т. тарафыннан төзелгән «Халык моңнары» дип аталган җырлар текстлы җыентыгы турында сүз бара. Әдәби-музыкаль кичәләрдә еш яңгыраган әсәрләрдән З.Яруллинның «Тукай маршы»н атап китә. Аннан кала, Т.ның «Аң» журналы белән хезмәттәшлеге һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең шәкертләр хоры репертуарына «Тәфтиләү», «Туган тел» җырлары да булуы күрсәтелә.

Э.Р.Каюмова

Әдәбият: Губайдуллина Г. Тукай и татарская камерно-вокальная музыка // Поэт свободы и правды. К., 1990. С.325-330; её же. Влияние татарской народной песни на поэтическое мышление Габдуллы Тукая // Страницы истории татарской музыкальной культуры. К., 1991. С.83-108.

Муса Җәлил. 1941 ел

АККА КАРА ТӨШСӘ, ЮГАЛМЫЙ...

(МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ЯҢА ШИГЫРЬЛӘРЕ ТАБЫЛУ ТАРИХЫ)

Рәзин Нуруллин

Татарстан дәүләт радиосы коллективы Җиңүнең 70 еллыгы уңае белән сугыш чоры балаларына багышлап «Михнәтле балачак» исемле тапшырулар сериясен әзерләде. Күп санлы әңгәмәдәшләр арасында берсе – Казанда яшәүче Финә апа Нуретдинова мине аеруча кызыксындырды. Үзе катнашкан тапшыру эфирда яңгыраганнан соң, Финәападан хат килеп төште, анда мондый юллар бар иде: «Ырынбур өлкәсендә туып үскән ***Гобәйдулла Зариф улы Салихов*** *1941 елны сугышка алынып, бәхетсезлегенә каршы, дошман кулына эләгә. Ул хөрмәтле шагыйребез Муса Җәлил белән бергә тоткында була һәм Муса Җәлилнең алты шигырен күчереп ала. Бу шигырьләр Гобәйдулла абыйның балаларында саклана».*

Чынбарлыкмы бу, әллә шаярумы? Әгәр язганнары хак икән, ни өчен аны әлегә кадәр сер итеп саклаганнар? Кабат Финә апага мөрәҗәгать иттем.

Баксаң, Финә апа шул арада гына туган ягында — Ырынбур өлкәсендә булып, ошбу шаккатыргыч, тетрәндергеч яңалыкны алып кайткан икән!

«Гобәйдулла абый сугыштан соң гел кимсенеп яшәде, — дип сөйләп китте ул. — *Аны олысы да, кечесе дә, кулына корал алып сугышканы да, дары иснәп карамаганы да «сатлыкҗан» дип мәсхәрәләде. НКВД вәкилләре бер дә тынгылык бирмәделәр, хәтта төн уртасында өйләренә килеп, тентү үткәрделәр. Аның серле язмышын балаларыннан кала беркем дә төгәл генә белми иде. Чөнки ул мәктәпләрдәге очрашулар вакытында да дәшми калуны өстен күрде. 1970 елда юл һәлакәтендә фаҗигале төстә вафат булып, үзе күргән-белгәннәрен гүргә алып китте, дип уйлаган идек. Ялгышканбыз. 2007 елда Салиховлар яшәгән йортны сүткәндә, чормада күн букча табыла. Ә анда Гобәйдулла абыйның истәлекләре...»*

Финә ападан Гобәйдулла абыйның җиде баласы булуын ачыкладым, шуларның берсе — Башкорт дәүләт университеты деканы, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Гафур Гобәйдулла улы Салихов белән элемтәгә кердем. *«Алман телен барлык диалектларда яхшы белгән, концлагерьда еш кына әсирләр файдасына тәрҗемә итеп, милләттәшләрен коткарып калган әтиебез җәлилчеләр турында безгә бик күп мәгълүмат сөйләп калдырды. Ул чакта безнең илдә аның сүзләренә колак салучы, аңа ышанучы юк иде. Әмма әтиебез якты киләчәккә ышанып: «Сез минем белән горурланырсыз әле!» — дип яшәде. Бала чакта ул сөйләгәннәрнең мәгънәсен аңлап бетермәсәк тә, барысы да күңелгә уелып калды. Җидебезнең бишесенә югары белем биргән, барыбызны да*



Гобәйдулла Салиховның Седльце яисә Радом хәрби әсирләр лагеренда төшкән фотосурәте. 1943-1944 еллар

илгә файдалы кеше, ватанпәрвәр итеп үстергән әтиебезнең рухы шаттыр, дип ышанасы килә. Без, чыннан да, аның белән горурланабыз».

Шундый сүзләрдән соң исеме ил күләмендә мәгълүм булган галим Гафур Салихов миңа чормада табып алынган язмаларны бирде. Анда мондый юллар бар (урысчадан тәрҗемә)[1]: *«1942 елның октябрендә безне эшелонга төяп Польшага озаттылар,* ***Седлец (Седльце)*** *шәһәрендәге хәрби әсирләр лагерена алып килделәр. Монда мин якташым, татар шагыйре Муса Җәлил белән таныштым. Аның алты шигырен күчереп алу мөмкинлеге булды. «Дустым хисе», «Дустыма», «Сөйгән дустым», «Озатып калучы», «Туган ил сулары» һәм «Картлык».*

[1] Гобәйдулла Салиховның күн букчада сакланып калган автобиографиясе белән тулысынча журналның киләсе санында таныша аласыз.



Муса Җәлилгә нисбәт ителгән «Дустым хисе» һәм «Сөйгән дустыма» шигырьләренең кульязмасы



Муса Җәлилгә нисбәт ителгән «Озатып калучы» шигыренең кульязмасы

Мин аларны алып кайттым һәм әле дә үземдә саклыйм. 1943 елның февраль аенда Седлец шәһәрендәге лагерьда башкисәрләр Муса Җәлилне һәм тагын бер кешене кулга алды (фамилиясен хәтерләмим). Беренче көнне лагерь капкасы янында, капка сакчылары күзәтүендә, көн буе гимнастёркада гына тоттылар. Көн салкын иде, төньяк-көнбатыштан бертуктаусыз салкын җил исте. Алар сикергәләп җылынырга тырыштылар, арып, карга егылдылар. Әмма аларны кабат басарга мәҗбүр иттеләр. Икенче көнне шул ук урында, бу юлы шинель кигәннәр иде, кулларына икешәр кирпеч күтәреп тордылар. Өченче көнне инде без аларны күрмәдек…»

Бу юлларны укыгач, тагын сорау туды. Тарихи дөреслек нинди? Бу язмага ышанып буламы? Үзем тарихчы булмаганлыктан, Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче галимнәргә мөрәҗәгать иттем. Татарстан Милли китапханәсе директоры урынбасары **Ирек Һадиев Габдрахман Әпсәләмовның** Муса Җәлил һәм батыр җәлилчеләрнең якты истәлегенә багышлап иҗат ителгән «Агыла болыт» романыннан Гобәйдулла Салиховка бәйле юлларны табып бирде: *«Салихов белән Байдамшинның көчәнмичә, кыланмыйча җырлаулары да әсирләрнең күңелләренә бик хуш килде, йөрәкләре айкалып китте»*[2]. *«Салихов белән Байдамшин халык көйләре белән дан алды»*[3].

[2] Әпсәләмов Г. «Агыла болыт». — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — Б.136.
[3] Әпсәләмов Г. «Агыла болыт». — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — Б.158.

Уфада яшәп иҗат иткән **Рафаэль Азнагуловның** язылып бетмәгән (ул быелның мартында вафат булды) китабыннан да өзек китерик.

«Хәзер килеп шундый сорауга да җавап биреп карыйк. Гобәйдулла әсирләр лагеренда Муса Җәлил белән очрашканмы? Ике якташның очрашуы гаҗәп хәл түгел. Легионерлар концертларында Салихов ике тапкыр җырлый. Халык җырларын башкара. Күренекле татар язучысы Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» романында язылган: Муса Җәлил сәхнә артыннан ике тапкыр Гобәйдулланы күзәтә һәм аның җырларын тыңлый. Бу хәлне әсир Салихов белми, бәлки, белмәмешкә салышадыр. Башкалар, надзирательләр сизеп калмасын дип тә әзне яшерергә мөмкин. Чөнки әсирләр сугышчан бишлекләргә бүленә. Бер бишлектәгеләр башкаларның кемнәр икәнен белмиләр һәм белергә дә тиеш түгел. Әгәр кулга алсалар, үзләренең бишлекләре генә иза чигә. Башкаларны алар белми. Бу инде, үз чиратында, легионерларны күпләп кырылудан саклап кала. Үзенә күрә хәрби тактика була инде бу.

Шулай да, Гобәйдулла Муса Җәлил белән бәйләнештә булганмы-булмаганмы? Бу сорауга да берникадәр ачыклык кертеп карыйк. Ул (Г.Салихов. — Редакция.) ***Шәфи Алмас*** *белән танышып ала. Хәтта өйләрендә була. Бу әфәнде 1917 елда Ырынбурдан Алманиягә кача. Димәк, ул да Салиховның якташы булып чыга, Муса Җәлилне һәм аның иптәшләрен белә. Ул Гобәйдулла шулар хакында яңа мәгълүмат бирмәсме икән, тип тә уйлагандыр. Әмма* ***Губанов (ягъни, Салихов)****, Шәфи Алмасның кем икәнен белә торып, «мин аларны белмим»нән башка ачылып китә алмагандыр, дип гөман кылырга кала. Фашистларга тәрҗемәче вазифасын башкарса да, аның да бит туган илгә биргән анты бар. Әсирләр өчен дә тәрҗемәченең файдасы тиеп куйган очраклар була. Кайсыбер бик тә авыр, четерекле мәсьәләләр килеп туса (мәсәлән, ремонтка дип кайтарылган техниканы, бигрәк тә сугыш коралын, юри вакытны озакка сузып яисә ярым-йорты гына төзәткәнне палачлар сизеп калса), тәрҗемәче Гобәйдулла эшне әсирләр файдасына хәл итә торган булган».*

Җәлилчеләр тарихын өйрәнүчеләр Салихов турында да белгәч, димәк, ул кеше чыннан да бар? Ул кеше, чыннан да, Муса Җәлил белән көрешкән? Ул кеше «кара» исемлектә түгел?

Инде латин хәрефләре белән язылган шигырьләрне (алар әле, өстәвенә, башкорт телендә күчерелгән!) гамәлдәге имлага аударасы һәм аларның Муса Җәлилнеке булуын раслыйсы (яисә кем белә — кире кагасы) калды. Бу үтенеч белән мин Казан федераль университеты доценты, филология фәннәре кандидаты, Муса Җәлил иҗатын өйрәнүче **Нурфия Йосыповага** мөрәҗәгать иттем. Аның раславынча, бу шигырьләр, чыннан да, Муса Җәлил стилендә язылган. Күчереп язучы, ягъни Гобәйдулла Салихов, бәлки кайбер төгәлсезлекләр дә җибәргәндер. Ничек кенә булмасын, һәммә фактлар җентекләп өйрәнүне, тикшерүне таләп итә. *(Алла боерып, киләчәктә, бәлки, Муса Җәлилнең шушы шигырьләре турында Нурфия Йосыпованың да, башка галимнәрнең дә фәнни язмаларын журналыбызда күрергә насыйп булыр әле. — Редакция.)* Галимнәр бу эш белән шөгыльләнә дә.

Шунысын да искә төшерик: Муса Җәлилнең әсирлектән ике дәфтәре

Муса Җәлилнең әсирлектән ике дәфтәре илгә кайта. 1946 елда элеккеге хәрби әсир Нигъмәт Терегулов беренче куен «Моабит дәфтәре»н Татарстан Язучылар берлегенә илтеп бирә.

илгә кайта. 1946 елда элеккеге хәрби әсир **Нигъмәт Терегулов** беренче куен **«Моабит дәфтәре»**н Татарстан Язучылар берлегенә илтеп бирә. **Андре Тиммерманс**, дустының васыятен үтәп, төрмәдән Җәлилнең икенче дәфтәрен алып чыга һәм аны Брюссельдәге (Бельгия) совет илчелегенә тапшыра. Шулай итеп, бер елдан соң тагын бер дәфтәр СССРга кайта.

Өченче куен дәфтәрен **Габбас Шәрипов** исемле әсирнең алып кайтуы билгеле. Ләкин туган илләрендә Терегулов белән Шәриповны кулга алалар һәм яңадан төрмәгә — бу юлы Сталинныкына — озаталар. Терегулов лагерьда үлә. Габбас Шәрипов ун ел утырганнан соң иреккә чыга, аннары Волгоград өлкәсендә яши.

1946 елның гыйнварында Төркия гражданы (милләте буенча татар) **Казим Миршан** Римдагы совет илчелегенә Муса Җәлилнең тагын бер дәфтәрен китереп бирә. Җыентык Мәскәүгә җибәрелә, шунда аның эзе югала.

1979 елдан алып бу дәфтәрләрне эзләү әлегә бернинди уңай нәтиҗә бирмәде. Берәр кайчан табылырмы алар? Билгесез. Әлегә, Гобәйдулла Салиховка шундый игелеге өчен рәхмәт әйтеп, сөекле шагыйребезнең (дөресе, аңа нисбәт ителгән) исәнимин табылган шушы өр-яңа (һәрхәлдә, безнең өчен!) алты шигыре белән танышыйк.

Муса Җәлилнең яңа табылган шигырьләре

ТУГАН ИЛ СУЛАРЫ

Саф көмештәй синең су буеңда
Балык тотып, уйнап үстем мин.
Тауларыңда кышын чана шудым,
Җәй көннәре синдә йөздем мин.

Атка атланып синең кырларыңда
Тырмаладым чәчү кырларын.
Таң атканда сине яңгыратып
Җырладым мин яшьлек җырларын.

Егет булып җиткәч беренче кат
Мәхәббәтне синдә сиздем мин.
Синең суларыңны эчеп үскән
Кара кашлы кызны сөйдем мин.

Синең гүзәл, матур тугаеңда
Иркәләнеп атта чаптым мин.
Читкә китсәм, йөрәк чыдамады —
Сине сагынып кире кайттым мин.

КАРТЛЫК

Мин һаман да шулай йөрерменме,
Әллә картлык билне бөгәрме,
Йөзләремнең яшьлек нурын алып,
Күп җыерчыклар ямьсез тезәрме?

СӨЙГӘН ДУСТЫМА

Гомерем дусты, яшьли сөйгән ярым,
Улларымның гүзәл анасы,
Сөйдерә белгән кебек, үзе дә сөя белгән
Хыянәтсез гомер юлдашым.

ДУСТЫМ ХИСЕ

Иркәләдем сине бүген төшләремдә,
Чәчләреңне сыйпап тарадым.
Башым куеп көчле күкрәгеңә,
Күзләреңә озак карадым.

Сөйлəшəмен, серлəр бүлешəмен,
Синең белəн төн дə төшемдə.
Татлы төшне озатып күзем ачсам,
Син булмыйсың янда, өнемдə.

Сагындым мин сине — гомер
юлдашымны,
Сагынам үз-үземне белмичə.
Бетмəс ул хис, сагынып яну хисе,
Синең йөзлəреңне күрмичə.

ОЗАТЫП КАЛУЧЫ

Авыл очларына кадəр килеп
Саубуллашып озатып калдылар.
Нинди уйлар авыр ташкын булып
Күңеллəрне борчып алдылар.

Сау бул, диде, шулчак кулын бирде
Сөйгəн дустым, озатып калганда.
Нидер əйтте, лəкин аңламадым —
Йөрəклəрем янып барганга.

Артларыма борылып карап бардым,
Яулык болгап озатып калганын.
Оныта алмам аны һичбер вакыт,
Күкрəгемдə мəңге саклармын.

Бик еракка киткəч, карасам да,
Күралмадым сылу гəүдəсен.
Тик хыялда гына йөртəм хəзер
Озатып калучының шəүлəсен.

Аерылганда кеше якын була,
Кыйммəтрəк була тагын да.
Əйткем килде бер сүз җан дустыма,
Аерылышып киткəн чагында.

Əйталмадым лəкин, тик карадым,
Күңелемдə сине сакларга.
Сау бул, дидем, аңа кулым бирдем,
Фронтларга киткəн чакларда.

Əйткем килде таныш күзлəреңнең
Аяз көндəй нурлы булуын.
Əйткем килде ташкын йөрəгемнең
Ярсып-ярсып сине сөюен!

Əйталмадым əйтер сүзлəремне,
Иллəремнəн чыгып киткəндə.
Тик карадым таныш йөзлəреңə
Яшь йөрəгем ярсып типкəндə.

ДУСТЫМА

Почта юлын таптап һəр көн саен
Хатлар көтəм синнəн, акыллым.
Аерылышкач авыр, күңел сыкрый,
Кайларда син, җаным, алтыным?

Хатларың юк, хəлең белə алмыйм,
Таңнар саен сагынып көтəм мин.
Авыр уйлар күңелем борчыйлар да,
Сыгылып елап яшьлəр түгəм мин.

Ник югалдың инде, сөйгəн дустым,
Тормыш таңы сызылып атканда?
Əткəй-əнкəй, диеп иркə күздəн
Улларыбыз күзгə бакканда.

Ник кайтмыйсың бүген, сөекле кош,
Мəхəббəтлəр əллə сүндеме?
Батыр белəн əллə ярсу йөрəк
Тын алуын мəңге бүлдеме?

Син кайтмыйсың, өзелеп сагынсам да,
Рəсемдə генə күрəм төсеңне.
Канлы окопларның итəгендə
Салдыңмы əллə булган көчеңне?

Авылларга кайткан иптəшлəрең
Һичберсе сине күрмəгəн.
Сугышларда булган чакларында
Синең белəн бергə йөрмəгəн[4]*.*

Ник башланды мондый канлы сугыш,
Сызылып кына таңнар атканда.
Бар михнəт, кайгым бетəрме
Сөйгəн дустым исəн кайтканда?

[4] Гобəйдулла Салихов бу юлны «булмаган» сүзе белəн тəмамлый да, «күрмəгəн-булмаган»ның рифмалашмавына игътибар итеп, күрəсең, җəя эченə «йөрмəгəн» дип өсти. Без шул вариантта тукталуны кирəк таптык. — Редакция.

Фатих Кәрими. Ырынбур. 1908 ел

ФАТИХ КӘРИМИ СӘЯХӘТНАМӘЛӘРЕНДӘ ПУБЛИЦИСТИК КАТЛАМ

Рифә Харрасова

Татар матбугаты башында торучыларның берсе саналган Фатих Кәрими **«Кырымга сәяхәт»** әсәрендә милли журналистиканың нинди булырга тиешлеге турында ап-ачык күрсәтә. Безнең хәлдәге бер милләт өчен газета чыгару мал җыюны, шөһрәт казануны яисә башка бер шәхси макатларны күздә тота алмый, бары тик милләткә мәхәббәт, Ватанга, хөкүмәткә, кешелеккә хезмәт, наданлык чокырындагы бичараларга шифа өчен генә башкарыла, дип белдерә. **«Тәрҗеман»**ның егерме еллык юбилее уңаеннан катнашкан дога мәҗлесе уңаеннан, татар матбугаты һәм матбагасы турында уйланып, Гаспралының шул эшне башлап җибәрүдә зур батырлыклар күрсәтүен әйтә, бу чорда мөселманнарда, шул исәптән татарларда, «әлеге юлда хезмәт кую һәм акча тоту гөнаһ түгел микән» ише курку яшәгәнлеге хакында сөйли.

Бер яктан, татар матбугатын тыю, икенче яктан, массалар гына түгел, хәтта кайбер зыялылар да дөньяви әдәбият укырга шөбһәләнгән шартларда, чыннан да, вакытлы матбугат эшен җайга салып җибәрү реформага тиң була һәм зур батырлык сорый. Андый гамәлиятне һәм дөньяви, һәм дини белемгә ия, югары катлам белән аралашкан (ягъни, матбага ачуга акча табу мөмкинлеге булган) һәм андый эшләр белән яхшы таныш кешеләр генә башкара алган. Шунлыктан татар вакытлы матбугатының чишмә башында ахун дәрәҗәсендәге кеше һәм аның махсус белемле балалары тору табигый дә. Татар матбугатын аякка бастыру никадәр авырга килмәсен, ул заманның иганәчелеге һәм байларыбызның киң карашлылыгы, милли рухлылыгы шартларында бу хәл тормышка ашырырлык була.

Юбилей тасвирыннан күрәбез ки, аңа бөтен татар төбәкләреннән танылган кешеләр килә, бихисап телеграммалар җибәрелә. Димәк, «Тәрҗеман» Казанда һәм чит якларда яшәүче татарлар тарафыннан үз газеталары, чын милли матбага сыйфатында кабул ителгән. Без аның озак еллар дәвамында ялгыз диярлек эшчәнлеген татар периодикасының бер этабы сыйфатында өйрәнергә тиешле.

Фатих Кәриминең елъязмасы унтугызынчы-егерменче гасыр чигенә кагылышлы бик күп мәгълүмат китерә, кем һәм кайдан килгән, ни сөйләгән — барысы да тәфсилле күрсәтелә. Без әдип тасвирларыннан, ничәмә еллар тәнкыйтькә дучар ителгән, ахмак саналган, читкә тибәрелгән **Габдрәшит Ибраһимовка** татар зыялыларының шул чорда ни дәрәҗәдә югары бәя бирүен күрәбез.

Бары тик мәгънәле сүзләр, реаль гамәлләр генә эшләнгән бу мәҗлес, аның турында хатирә безне бүген дә уйга калдырырга тиешле. Аңа әзерләнгәндә, Фатих Кәрими болай дип язган була: *«Бу көн безнең өчен иң әһәмиятле көндер, чөнки татар милләтенең тәшкиленнән бирле, вә татар исеменең тарих сәхифәләренә кердекеннән бирле матбугат өчен, мәгариф вә инсаниятькә ителгән фикер вә каләм хезмәте өчен, беренче дәфга (тапкыр) буларак, моның шикелле бер яум мәсарәт (шатлык көне) вә гаед милли иҗра ителәюр (үткәрелә)»*. Автор газетаның эшчәнлегенә югары бәя бирә, аның татар галәме өчен кылган хезмәтләрен ача. Аныңча, теләсә кайсы газета милли тормышны алга җибәрә, кешеләрдә ватаннарына һәм милләтләренә карата мәхәббәт уята. Кәрими бер милләтнең тормышын яктырту, материалларны башка телләргә тәрҗемә итеп, ул милләтнең барышын чит халыкларга да хәбәр итеп торуны татар зялыларының бер бурычы сыйфатында күрсәтә.

Фатих Кәрими язмасында шушы чорда татар мәгарифенә, әлбәттә, шул исәптән, матбагачылыгына да тотылган акча күләме, моңа кадәр басылган фәнни һәм әдәби рисаләләргә бәйле саннар да бар. Язучы һәм журналист, галим үз иҗаты белән дә татар журналистикасының, әдәбиятының үсешенә зур өлеш кертә. Аның публицистикасы бүген дә үрнәккә куярлык әсәрләр булып тора. Алга таба сүзем берьюлы татар прозасына да, журналистикасына да өлеш керткән Фатих Кәрими иҗатында публицистик катлам турында барыр.

***

Узган чорларга борылып карыйсың да, таң каласың, сөенәсең: бер гасыр эчендә татар әдәбияты да, журналистикасы да үсеш-үзгәрешләрнең катлаулы озын юлын үткән. Ул үз укучысын туплаган, сәләтле авторларны мәйданга китергән, форма ноктасыннан баеган, тел-стиль үзгәрешләре кичергән. Шул ук вакытта борчыла да башлыйсың: ул инде бер туплаган укучы санын югалта башлады, теле корамалану юлыннан китте, тирән эчтәлекле публицистик язмалар иҗат итәрлек каләм осталары көннән-көн сирәгәя бара. Шушы

Утырганнар (сулдан уңга): Габдрахман Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Ризаэддин Фәхреддин, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Борһан Шәрәф; басканнар: Рәкыйб Рәкыйби, Госман Нури Акчокраклы, Ярулла Вәли. Ырынбур. 1909 ел

шартларда, заман ихтыяҗларын күздә тотып, әдәбиятта публицистик катламны көчәйтеп җибәргән, бер үк вакытта саф публицистик материаллар да язган Фатих Кәрими һәм кайбер замандашлары иҗатына әйләнеп-әйләнеп кайтасың. Бер гасыр узганнан соң, алар калдырган мирас тагын да актуальләшәрәк төшә сыман. Бу мәкаләнең язылуы да укучы игътибарын егерменче гасыр башындагы кайбер әсәрләргә юнәлтү максатыннан, дип уйларга кирәк. Бүгенге татар язучысы милләтче генә түгел, мәгърифәтче дә булырга, үткен сүзе белән яңадан йокыга киткән халыкны уята башларга тиеш. Әлбәттә, һәр чор мәгърифәтчелек хәрәкәтенең үз спецификасы, бераз аерымрак бурычлары бар, әмма аның гомуммаксаты —милләтне яшәтү.

Беләбез ки, узган мәгърифәтчелек чорында әдәбиятларда поэзия үз позицияләрен бирә, проза жанры ныгый. Татар язучылары да шәхес һәм милләт хокукларын көчлерәк яклый алган, киң планда фәлсәфи фикер йөртү мәйданы белән тәэмин иткән, әле ныклы традицияләргә ия булмаган заман прозасын тудыру эшенә керешә. Унтугызынчы гасырның яңа шартларында татар әдәбиятында нарратив жанрлар кискен үсеп китә. Бу вакыйгакүренешләрне укучыга хикәяләүче образы булган сәяхәтнамәләргә дә кагыла.

Һәр мәгърифәтче әдипнең мирасханәсендә сәяхәтнамә, истәлек, хат кебек формаларга караган язмалар табыла. Шушы чорның күренеклеләреннән саналган Кәрими иҗатында сәяхәтнамә генә дә — өчәү. Шулардан 1901 елда язылган **«Аурупа сәяхәтнамәсе»** белән 1903 елда мәйданга килгән **«Кырымга сәяхәт»** — публицистик формага хас традицияләрне алга таба үстерү булса, 1898 елда иҗат ителгән **«Шәкерт илә студент»** — татар милли беллетристикасының башлангычына нигез биргән хикәядән дип исәпләнергә лаек. Без,

әдипнең юл очеркларын бер читкәрәк куеп торып, соңгысына ныграк тукталырбыз.

Әдәби сәяхәтнамә, бер яктан, публицистика шикелле үк, киңкатлам укучыга юнәлдерелә. Икенче яктан, документаль жанрларга каршы да тора. Өченчедән, тар мәгънәдә беллетристика төшенчәсенә дә җавап бирә: ял иткәндә уку, чор сурәте, модалары, кешеләрнең уй-фикерләре, гадәтләре, һөнәрләре һәм социаль катламнары белән танышу өчен кызыклы чыганак рәвешен ала. Җәмгыятьнең ике гасыр чигендәге хәл-торышын чагылдырган «Шәкерт илә студент»ны документаль-фактик материал әдәби алымнар ярдәмендә җиткерелгән (ягъни, беллетризацияләнгән) әсәр дип бәяләргә булыр иде.

Әдәби әсәрнең публицистиклыгы — һәм эчтәлеккә, һәм формага караган сыйфатлама. Ул каләм иясенең дөньяга карашларын, иҗтимагый тормыш күренешләренә мөнәсәбәтен, социаль-сәяси проблемалар күтәрү сәләтен күрсәтеп тора һәм, беренче чиратта, текст стилистикасында чагылыш таба.

Фатих Кәрими иҗаты турында сөйләгәндә, галимнәр әдип прозасында зур урын алган публицистизмга һәрвакыт игътибар итә. Әйе, гомумән алганда, мәгърифәтчелек әдәбиятында көчле чагылыш тапкан бу сыйфат аның әсәрләрен дә читләп узмый. «Шәкерт илә студент»та Кәрими социаль, иҗтимагый-сәяси проблемаларны әхлакый яссылыкка сала. Русия халкының, милләтләренең, бигрәк тә татарларның язмышы, гореф-гадәтләре, аларның милләт язмышындагы һәм ил тарихындагы роле турында уйланулар Фатих Кәрими әсәрләренең публицистик башлангычлы икәнен күрсәтеп тора да.

«Мин үземезнең мөселман кардәшләремезнең наданлыктан, файдасыз вә урынсыз тәгассебтән, ахмаклык вә каршылыктан вә искедән калган бәгъзебер мәҗүсилек гадәтләреннән котылып, аз булса да гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнәгать кәсеп итеп, ачык фикерле вә мәдәниятле булуларын, вә сөекле ватанымыз булган Русиянең фидакяр хадиме, хөкүмәт матбугатымызның халис вә садыйк углы, ягъни мәдәниятле русия мөселманы» булып яшәүләрен телимен», — ди Фатих Кәрими әсәргә кереш сүздә.

«Шәкерт илә студент» Кәрими тарафыннан баштан ук публицистик уйланмага нигезләнә: анда халыкның беркатлы ышанычлары, ярым дини-ярым тормышчан фәлсәфәсе, бу инануларның көндәлек тормышта, киемдә, ашау-эчү культурасында чагылуы шуны ачык дәлилли.

Әсәрнең публицистиклыгы ни дәрәҗәдә, дигән сорау туа. Беләбез ки: публицистиклык хирыслы полемик стиль белән язуда чагылыш таба. Бу сыйфат Фатих Кәрими хикәясендә шактый калку. Анда публицистик катлам әсәрнең бөтен сәнгати тукымасына сеңдерелгән; ул сюжетка караганда доминанта позициядә тора; образ-детальләр очеркларга хас булганча тудырылган һәм сайланган. Мәсәлән, хәзрәт кияве белән пишкадәм турында сүз алып барганда, автор алар мәдрәсәдә укыган барлык дәреслекләрне бер-бер артлы атый, мөгаллимнәрнең шәкертләренә ничек белем бирүләрен һәм үзләренең дә мәгърифәтлелек дәрәҗәсен бәяли. Әдәби әсәр иҗат итүне максат итеп куйганда әдип боларга, бик кирәк санаганда да, ишарә ясау белән канәгатьләнер иде.

Геройларның көрешү, аралашу әдәбе турындагы тәфсилле абзацларның да укучыны ялыктырачагын Кәрими белә, әмма стильне үзгәртми, бу ялыктыру аның файдасына гына: укучының иске тип руханилардан күңеле кайтачак. *«Яннарына утыргач та, хәзрәт кияве рустан: «Син кем? Кая барасың? Ник барасың? Хәзер кайдан киләсең?» — дип, бердән-бергә биш-алты сөаль сорады...»* дип башлый үзенең бер абзацын автор һәм бу төр төпченүнең ямьсез күренеш икәнлеген күрсәтергә тырыша.

Фатих Кәрими гаиләсе белән. Уфа, 1911 ел

Публицистик катлам нәфис әдәбиятта, мемуарларда һәм башка төр хезмәтләрдә дә текстка заманның темага туры килгән хәлләре, проблемалары, күренеш-вакыйгалары, персонажлары турында хөкем йөртүләрнең үтеп керүендә чагылыш таба. *«Ашадыкымыз вакыт безем янымызда утырган бер адәм, капудан кергән икенче бер адәмне күрдектә: «Сибгатулла Сергеевич! Монда кил, әзрәк закусить итеп алыйк!» — дия чакырып алды. Гәрчә исеменең яртысы — мөселманча вә яртысы русча булса да, бу адәмнәрнең мөселман идеке мәгълүм иде. Сембер, Пенза, Саратов, Нижний тарафларындагы мөселманнар, әксәриян, кәнделәренә шуйлә исем бирәләр»*. Күрәбез ки, язучы чорында исемнәрнең руслашуында татарларның үзләре гаепле икәнлекне ачык аңлый.

«Шәкерт илә студент» хикәясенең һәр битендә әдип һәм заман тавышы ишетелә. Димәк ки, без хикәя баштан алып ахыргача публицистик рухта язылган, дип әйтә алабыз. Әлбәттә, анда нәфис текстларга хас сыйфатларга да билгеле бер күләмдә урын калдырыла, әмма бу аны хикәя дип атауны аклар дәрәҗәдә генә. «Шәкерт илә студент», публицистик әсәр буларак, үз чоры өчен әһәмиятле иҗтимагый проблемаларны күтәрүдән тыш, гражданлык, хакыйкать, гаделлек, дөреслек, милләт каршында җаваплылык кебек һәр заманда актуаль булган проблемаларны да чагылдыра.

Хәтта чын мәгънәсендә нәфис форма иҗат итәм, дип яза башлаганда, иҗтимагый проблемаларны калкуландырсаң, үтәли мотив ясасаң, лексик составта нык чагылдырсаң, каләмеңнән төшкән текстның жанр сыйфатламалары шунда ук үзгәрә башлый. «Шәкерт илә студент»та исә публицистизм автор уйланмасы булып тора. Ул теләсә кайсы гади укучы күзенә ташлана, чөнки автор позициясен чагылдырган әлеге сыйфат әсәрнең өс ягында ята, киңкатлам аудиториягә юнәлтелә.

Нәфис текстның публицистик катламнарын аерып кую анда сәнгати һәм публицистик башлангычның нисбәтен билгеләргә ярдәм итә. Әдәби әсәрнең публицистик ягы ул иҗат ителгән методка һәм авторның дөньяны күзаллауларына, хәтта еш кына язучылык талантына да барып тоташырга мөмкин. «Шәкерт илә студент»та публицистик катламның зур урын алып торуы бигрәк тә беренче шартлар белән бәйле, һәм моның шулай икәнлеген Кәрими мирасында бөтенләй башка төр стильгә корылган әсәрләр барлыгы белән дә исбатлап була.

Әдәби әсәрдә күренешләрне җентекле анализлаган, бәяләгән автор образы сиземләнә икән, ул шулай ук публицистикага тарта башлый. Бу хәтта гаҗәеп нәфис тел белән иҗат иткән Мөхәммәт Мәһдиевнең аерым әсәрләрендә дә урыны белән үзен сиздерә. Текстның нәфисме яисә публицистикмы икәнен ачыкларга кирәк булганда, аның берничә сыйфатына игътибар итәләр. Публицистика ике төр функция башкара: берсе — аңларга

тырышу, икенчесе — бәяләү, шунлыктан аңа фикер эзлеклелеген чагылдырган төшенчәләр килеп керергә мөмкин, образлы-эмоциональ сөйләм элементлары да җитәрлек булыр. Мисал китерик: «Алар бәхәснең нидән ачылганын, сүзнең кайдан киткәнен күптән оныттылар. Мин дә көчкә генә исәпләп таптым да үз-үземнән сорадым: *«Йә, менә безнең егерме ел укыган пишкадәмнәребезнең гыйлемнәре, бәхәсләре. Бу бәхәстән йә дөнья, йә ахирәт өчен үзләре никадәр файда иттеләр? Яисә мин, бер сәгать исраф итеп тыңлап утырдым. Ни файда иттем?»*

Фатих Кәрими «Шәкерт илә студент»та, публицистлар кебек, тирәлекне детальле тасвирлый һәм аларга үз шәрехләрен дә биреп бара. Шул сәбәпле хикәя тормышчан, реалистик кабул ителә, анда автор образы нык тоемлана, еш кына төп уңай герой авторның үзе кебек кабул ителә. Хикәяне авторның башка төр сәяхәтнамәләре янәшәсенә куйсаң, бик күп фикерләрнең кабатлануын күрербез. Әлеге форманың активлыгы чорның фәлсәфи-сәяси эсселары, тарихлары, сатирик хикәяләре, әхлакый кыйссалары һәм романнары уздырган барлык карашларын бергә тупларга мөмкинлек бирүенә барып тоташа.

Публицистик әсәрләрдә, беренче чиратта, социаль чынбарлык үзенең җентекле тасвирларында чагылыш таба. Пароходка утыручыларның тасвирына тукталыйк: *«Өсләренә-башларына бик яхшы нәрсәләр киенгән берничә рус вә рус хатыннары, пароходка утырмак өчен, конторның күпереннән керәләр иде. Нәрсәләрендер хезмәтчеләрдән күтәрткәннәр, үзләре арттан киләләр»*. Алга таба Фатих Кәрими *«зур паласларга төреп, җеп белән баглаган вә өсләренә берәр комган таккан нәрсәләре, вә икенче кулларында калай чәйнекләре бар иде»* дип, татарлар турында сөйли башлый. Тасвирлар тормыштан алынган булса да, образ-детальләрнең сайланышы ук авторның күренеш-вакыйгаларга хирыслы якын килүен, теге яки бу социаль төркемнәргә мөнәсәбәтен чагылдыра.

Фатих Кәрими руханилар катламына һәрдаим социаль бәяләмә бирергә тырыша, шулай ук башка төр иҗтимагыйсоциаль күренеш-хәлләрне дә бәяләп баруны әсәрнең соңгы битенәчә туктатмый. Болар барысы да «Шәкерт илә студент»ның публицистик сыйфатларын көчәйтә. Хикәядә социаль тормыш бер яки ике күренеш аша гына ачылмый, автор аны сюжет мөмкинлек биргән кысаларда гаять тә төрле итәргә тырыша, бу да публицистик катламның зураюына китерә.

Публицистикада шәхси башлангыч көчле була. «Шәкерт илә студент»та да автор позициясен белдерүче шәкерт образы шактый калкулана. Икенче яктан, Кәрими үз күзаллауларын студент сөйләмендә дә җиткерә, шул сәбәпле ике арада барган әңгәмә полемикага әйләнеп китә алмый, рус кешесе татар егетен үз фикерләренә инандыра, алар искелек тарафдарларына бергәләп каршы тора башлый.

Күргәнебезчә, Фатих Кәриминең «Шәкерт илә студент»ында публицистизмның һәм эчтәлеккә, һәм формага караган күптөрле сыйфатлары чагылыш таба. Аның хикәяләү структурасы эмоциональ-тасвири һәм аналитик-публицистик катламнардан оеша, һәм әсәр авторның дөньяны аңлау эшчәнлегенең чагылышы рәвешен ала. Публицистик катлам зур урын биләүгә карамастан, «Шәкерт илә студент»ны нәфис әдәбиятка кертеп карарга мөмкин. Анда хикәягә караган сыйфатлар да бар. Ул мәгърифәтчелек идеологиясе таралуга бәйле җанланган, яңа үсеш алган жанр булып тора. Анда алга таба татар тормышын ничек кору проблемасы алай һәм болай яшәү антитезасы ярдәмендә хәл ителә. ■

Зариф Мөэминов

СОЛДАТ ЙӨРӘГЕ

(Автобиографик бәян)

III

1915 елның октябрендә Русиядән пленныйларны күрергә дип делегация килде. Арада бер хатын кеше килде. Бу хатын Николай патшаның сеңлесе икән. Кызыгы шул — әлеге хатынның улы да шушы лагерьда пленда икән. Егетне әнкәсе белән күрештерделәр. Бу күрешүне Австрия генераллары карап торган булдылар. Менә шушы делегация килеп киткәннән соң, урыс пленныйларына шактый күп кенә җиңеллекләр булды. Ашау ягына артык рәтле булмаса да, духовой оркестр барлыкка килде, кино күрсәтә башладылар, кесә ягына хәллерәк егетләргә, Русиядән акча һәм посылка алып торучы яшьләргә футбол уйнарга рөхсәт ителде. Ә теге княгиняның улы һәр ай саен Русиядән посылка һәм акча алып тора башлагач, беттән тәмам арынды булса кирәк — футбол командасының башлыгына әйләнеп куйды. Аның иптәшләре дә күп иде. Барысы да Петербург егетләре. Дөресрәге, Петербург дворяннары малайлары. Әлеге княгиня тырышлык күрсәткәндер инде, хәллерәк кешеләрнең балаларына һәм якын кардәшләренә посылка һәм акчалар туктаусыз килеп тора башлады. Ул гына да түгел, Русия пленныйларына Русия хөкүмәтеннән Мәскәүдә пешерелгән, берсе-берсе әчмуха гүрәнкәле — дүртесе бер гүрәнкә килешле зур тартмаларга тутырылган печенье килә башлады. Бу печенье белән австриялеләр хәтта атларын да туйдыралар иде. Ләкин пленныйларга барысын да бирмиләр. Кайбер бәйрәмнәрдә һәрбер пленный башына берничә кисәк өләшеп бирәләр иде. Ишетүләргә караганда, Мәскәүдә бу печеньены, һәр көнне бирергә дип, һәрбер пленный башына берәр печеньедан хисаплап пешерәләр икән. Австриялеләр аны үзләре теләгәнчә хәл итәләр иде. Тулысынча бирергә дошман бит ул, туган-тумачаң түгел. Шулай да княгиня килеп киткәннән соң, авыр яралыларны алмашу да башланды, ике арада пленныйлар хат һәм акча, посылка алып тордылар. Ә кайдадыр аяусыз сугыш бара иде…

Фронттагы хәлләр аңлаешсыз иде. Русия солдатлары да сугыштан кача икән хәзер. Фронтка җибәрелгәч, бер пуля да атмыйча, ярты көн дә сугышмыйча, полкы-полкы белән немесләр ягына пленга чыга башлаулары да сер түгел инде. Шул сәбәпле уналтынчы елның язында Варшава немесләргә бирелде. Австриялеләр дә сугышырга ашкынып тормыйлар иде булса кирәк: үзләре били торган империя чикләреннән урыс солдатларын куып чыгарып бетергәч, урыс җиренә керергә теләмәделәр. Әллә Русия ягы каты каршылык күрсәтеп ташладымы, ике як та сугыш хәрәкәтләрен туктатып, озаклап оборонада яту башланды. Бары тик уналтынчы елның көзендә генә генеральный һөҗүм ясап, Русия гаскәрләре австриялеләрне тагын да Карпат тауларына кадәр кудылар. Бу һөҗүм вакытында Русия ягыннан Румыния дә катнашты.

*Дәвамы. Башы журналның 7 санында.

Лечениедә тәмам дүрт ай вакыт үтте. Лечение алган урын Вайн шәһәренең көньягына урнашкан Висильвург дигән станса кырындагы зур бер лагерь иде. Монда биек итеп корылган мәһабәт баракларның исәбе-хисабы юк. Баракларның кайберләре буш, дворы-дворы белән кешесез-җансыз иде. Нәрсә өчен шулай күп итеп корганнардыр? Лагерьның төньягында кирпеч заводы бар. Лагерь кешеләре файдага эшләсенгә төзелгәндер инде. Тик ятып кына булмый бит. Лагерь бик чиста. Барак араларына һәм юлларга вак ташлы ком сибелгән. Двор саен зур тигезләгеч тәгәрмәч-катук бар. Дәваланырга китерелгән яралы-гарип пленныйлар иртәнге аштан көндезге ашка (көндезге сәгать бергә) кадәр, әбиттән соң сәгать икедән башлап кичке сәгать сигезгә хәтле шушы авыр тимер катукны тартып, ком җәелгән сукмак-юлларны тигезләп йөргән булалар. Читкә калып булмый, бу — мәҗбүри эш. Эш өчен өстәмә порция дигән булып, берәр чирпәк мал чөгендере шулпасы бирәләр. Менә шушы әсир кешене дәвалау була инде. Лазаретка дәвалануга җибәрелү гомуми пленныйлар лагеренда слабосильный (хәлсез әсирләр) командада ятудан күп тапкырлар авыр иде.

Лечениегә килүчеләр төрле лагерьлардан җыйнап китерелгәннәр. Килгәч тә, беренче тапкыр комиссия үткәндә үк, табиблар таякка таянып йөрүче аксакларның таякларын алып бетерделәр. Алар яралыга:

— Курыкма, курыкма, сиңа таяксыз да йөрергә мөмкин, — дип, үзләре җитәкләп йөртеп тә күрсәтәләр. Дөресен әйтергә кирәк, арабызда сәламәт кешеләр рәтендә эшкә бармыйча, аяклары авыртудан куркып кына таякка таянып йөрүче яралылар да күп иде. Менә шундыйлар зур катукны көннәр буена тартып йөри башладылар. Төрле гимнастикалар ясату, кулы яралыларга берничә килограммлы герләр күтәртү, алага-ем олы баракларны себереп чыгару һәм юу, саламнан галош үрү ише эшләр эшләтеп «дәвалау» үзәккә үтте. Пленныйлар командага бүленде, ничәнче команда икәнлеген белдерү өчен, кызгылт бишмәтнең нәкъ түш турысына диагональ буенча тегелгән түгәрәк калай тагылган була. Бу калайларга «16», «17», «18» кебек номерлар төшерелгән. Бо-

лар команданың номеры. Безнең Дрезденнан килүчеләрнең түшенә уналтынчы нумер тагылган иде.

Шулай да лечение бөтенләй үк файдасыз булды дисәң, гөнаһ булыр. Күбесе шактый ныгып китте. Үлсәм үләм, дошманга файда китермим, дип эшләмичә йөрүчеләрнең дә авызлары ябылды. Берәүнең дә тиз генә үлеп китәсе килми икән ул. Кайбер һөнәрләргә өйрәнү дә алдагы тормышта ярап куйды.

Үзара мөнәсәбәткә килгәндә, алар начар иде. Безне кораллы солдатлар сагы астында йөртәләр һәм бу солдатлар безгә явыз дошманга караган кебек карыйлар. Юкса, бу ил солдатлары белән дөнья яралганнан бирле беренче тапкыр очрашуыбыз. Безнең бу кешеләргә бернинди дәгъвабыз һәм бернинди алыш-бирешебез дә юк. Ни сәбәптән без бу ил халкы белән дошман булдык соң? Моның сере кайда?

Николай патша белән Франц Иосиф һәм кайзер Вильһельм арасында ачу-кычу яки нинди булса да бер-берсен рәнҗетә торган дошманлык булган икән, ник алар үзләре генә сугышмыйлар? Ник алар бөтен ил халыкларын бер-берсенә каршы сугыштыралар икән? Бу нинди гаделсезлек икән? Мондый уйлар башка еш килә иде.

Лечениегә килгән яралы пленныйларны үз лагерьларына озата башладылар. Бу вакытта инде җирсеп үләрлек ямьле җәй көне иде. Чынлап әйткәндә, май ае иде бу. Без килгән вакыт нәкъ кыш үзәге иде бит. Карлы, яңгырлы, күңелсез юеш көннәр иде.

Безне Дрезден стансасында Италия фронтына җибәрелә торган Австрия артиллеристлары төялгән эшелонга утырттылар. Шул фронтка озатыла торган эшелон булу мөнәсәбәтендә безне духовой оркестр һәм үзләренчә «ура» кычкырышып озаттылар. Шунда бер хәл булды. Эшелон Прага шәһәрен үтеп, бер стансага җитәрәк крушениегә очрады. Артиллеристларның күпләре һәлак булды, күпләре яраланды. Пушкалар төялгән платформаларның асты өскә килеп бетте. Без (Русия пленныйлары) төялгән беренче вагонның алгы көпчәкләре генә рельстан чыккан иде. Әсирләрнең берсе дә һәлак булмады. Сугышка баручы Австрия солдатларының юлда ук һәлак булулары бик гаҗәп иде. Яралы пленныйларның йөри алмаслыкларын арбаларга төяп, йөрерлекләрен җәяүләтеп алдагы стансага илттеләр. Таң вакытында икенче эшелонга утырдык.

Австрия җирен матур һәм төзеклеге өчен мактарга була. Торым-торымга баяр усадьбалары күренә. Алар шактый. Авыллар җидешәр, күп булса, уникешәр йорттан гына торалар. Безнең Русиядәге крәстиян авыллары кебек берәр, хәтта икешәр чакрымга сузылган авыллар юк. Өйләр икешәр-өчәр катлы чүлмәк белән ябылган. Безнең яктагы шикелле салам түбәле бернинди каралты юк. Басулар таш юллар белән челтәрләнеп беткән. Юл буйларында һәр ике яклап алма һәм груша агачлары үсеп утыра. Шундый матур, шундый ямьле. Дрезден шәһәре тирәсе дә шулай.

Без төялгән эшелон Австрия мәмләкәтенең баш шәһәре Венага килеп җитте. Без лечениегә барышлый да бу шәһәрне күреп киткән идек. Шәһәр зур бер кара урманны хәтерләтә. Иге-чиге юктыр кебек. Мәһабәт биек йортлар завод төтене белән ысланып, каралып беткәннәр. Станса тирәсендәге кирпеч йортлар морҗа юллыгы кебек каптай-кара. Барышлый безгә бүрәк (шалканга охшаган үсемлек) шулпасын биргәннәр иде. Шулчакта мин:

— Австрия патшасы Франц Иосиф үзе дә бүрәк ашап кына җан асрый икән. Без пленныйларга икмәкне каян алып бирсен тагын! — дип иптәшләрне көлдергән идем. Бу юлы, чыннан да, кунак сыедай аш бирделәр. Беренчегә — ак макарон, зур гына кисәк яхшы симез ит, икенчегә — фасоль боткасы иде. Шулай ук бишәр йөз грамм бодай икмәге дә биргәннәр иде.

Без, сынык күңелле яралы тоткын-пленныйлар, Вена шәһәре әбитеннән бик канәгать калдык. Тоткынга эләккәннән бирле беренче мәртәбә шундый ашау тәтеде. Бер-беребез белән күтәренке күңел хәлендә сөйләшә башладык.

Беребез гөман кылып:

— Әллә солых булды микән? Австриянең пленныйларны гомердә болай сыйлаганы юк иде, — дип акыл сата башлады.

Безнең нәрсә турында сөйләшүебезне постта торган бер солдат аңлап алган икән. Җавап бирде:

— Солых булганы юк әле. Сугышның очы-кырые күренми. Урысларда халык күп, яңадан егерме биш ел сугышырлар әле, — диде.

— Австрия белән Алмания солых сорасалар да, урыслар күнмәсләр микәнни? — дибез.

— Нимесләр урысларның солых соравын көтәләр. Тик урыслар ягы бирешми.

— Сугышны сез башладыгыз бит. Сез сорарга тиеш солыхны! — дидем мин кыза төшеп.

Посттагы солдат миңа җавап бирмәде. Шулчакта Франц Иосиф сурәтендә киенгән, чәһрәсе (йөзе, чырае) караңгыланган бер генерал килеп керде. Посттагы солдатлар үрә каттылар, без дә урыныбыздан тордык. Генерал сакау урысчалап безгә утырырга кушты. Кырку гына итеп урыс телендә:

— Ничек соң, аш әйбәтме? — дип сорады.

Без барыбыз беравыздан:

— Аш бик әйбәт, азрак кына булды шул, — дип шаулашып алдык.

Ул чәһрәсен тагын да боза төште. Ачу белән:

— Русиягә кайткач, күп итеп ашарсыз. Без шуннан артыгын бирә алмыйбыз сезгә. Имгәкләр, әрәмтамаклар, ыштыр битләр! — дип, ачу белән идәнгә тибеп алды да, кырт-кырт атлап чыгып китте.

Вагоннар кузгалыша башлады. Бездән алда беренче класслы вагоннардан торган поезд кузгалды. Аның артыннан ук безнең эшелон хәрәкәткә килде. Алдагы стансага барып җиткәндә әлеге беренче класслы эшелон да шунда туктап тора иде. Бу эшелон безгә бик гаҗәп тоелды. Чөнки бу эшелонның вагоннары пыяладан эшләнгән. Вагоннар ятып бару өчен җайлашмаган. Кара-каршы һәм аркага-арка куеп утыру өчен матур диваннар тезгәннәр. Башка поездларның вагоннарына өчәр катлы ятак эшләнгән. Монда андый нәрсә бөтенләй юк икән. Бу вагоннарга утырган пассажирларның суткалап юлда йөриселәре юк. Бәлки, сәгатьләп кенә йөриләр. Берничә сәгать эчендә барачак җирләренә барып җитәләр. Ә инде ерак юлга сәфәр өчен махсус вагонлы эшелон була.

Стеналары ачык пыяладан булганга күрә, сөйләшкәннәре аермачык ишетелә. Мин инде нимесчә әйбәт аңлыйм, сүзләренең һәммәсен күңелгә салып куям. Вагоннарның эче ачык күренеп тора. Бик матур эшләнгән вагоннар затлы киенгән сәламәт йөзле халык белән тулы. Анда — хәрби әфисәрләр, гражданский ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар төялгән. Һәммәсе дә шат чырайлы. Хатын-кызлар дөньяларын онытып, үзара сөйләшеп баралар. Ир-атларның күбесе гәзитә, китап укыйлар. Шундый гаҗәп тоелды: бу эшелонның пассажирлары — хатын-кызлар, балалар — безне күреп алгач, кызыксынып урыс тоткыннарын күзәтә башладылар. «Бу нинди халык монда килеп чыкты?» — дигәннәрдер инде. Йөзләре белән янәшәдә барган әфисәргә табан борылдылар.

— Урыс, урыс, урыслар болар! — дип, нидер сөйли әфисәр.

Бала-чага һаман кызыксына.

— Нинди халык алар? Кием-формалары бигрәк начар. Гел шулай киенәме алар?

Әфисәр иренми, белдекле кыяфәт белән урыслар хакында аңлата.

— Әнә күрәсезме, араларында ярыйсы гына русский хәрби киемлеләре дә бар. Күбрәгенең өстендә без биргән иске киемнәр. Аларның илләрендә салкын кыш бик озак була. Бездә көннәр ел әйләнәсе җылы. Ул якларда җәй вакытлары нибары өч-дүрт ай, ә ерак Себердә бөтенләй җәй булмаган урыннар да бик күп, — дип сөйли. Һәммәсе гаҗәпкә калалар. Әфисәр кызык итеп кулларын угалап ала. —Ух, тух, Иркут-бухта, Забайкал!

Ул шул рәвешле хатын-кыз һәм бала-чагага Русиянең салкын, коточкыч ил икәнен аңлатып маташа. Себердәге кырык-илле, хәтта алтмыш градус салкын булган җирләр турында сөйләргә керешә. Урыс халкының ничек киенеп йөрүе хакында аңлатуга күчә: иләмсез зур калын толып һәм киез итек, бүрек, бияләй дип сөйли. Тыңлаучылар гаҗәпсенеп көлешәләр. Русия ягында пленда калган солдатларны кызганып сүз алышалар. Арада әсир төшкән туган-тумачалары да булган пассажирлар да бар икән. Русиядән язган хатлары турында сүзләр куерып китә.

— Ничек җан асрыйлар бу урыслар? Ничек өшеп үлеп бетмиләр микән? — дигән сораулар яңгырый.

— Урысларның яралышы шундый. Кар булмаса, авырый башлыйлар. Бозда ятып йоклыйлар, чәй-кофены белмиләр, чи ит ашап, салкын су эчеп, эчләрен уып, шатыр-шотыр кикереп йөриләр, — ди белдекле әфисәр. — Пленда йөрүче урыслар безнең илнең җылылыгына түзә алмыйча пешеп тә үләләр…

Әфисәрнең бу сүзеннән кычкырып көлделәр. Икеләтә кызыксыну белән янә безнең эшелонны күзәтеп тора башладылар. Аннан соң әфисәр Русия җиренең киңлеге һәм андагы халыкларның төрлелеге, бигрәк тә казак кавеменең бик чая һәм шәфкатьсез сугышчы булуы хакында тезеп китте:

— Казаклар ат өстендә туалар, шунда үсәләр. Атлары шундый оста өйрәтелгән, сугышта тезген тотасы да юк. Казакларның итекләренә сөңге беркетелгән, сугышта аяклары белән кадыйлар, бер кулында — мылтык, икенче кулында — кылыч. Яуга керсәләр, мәхшәр: кадыйлар, аталар, чабалар, турыйлар…

Хатын-кызларның йөзләре агарынып, сискәнеп китә; бала-чага куркудан, әниләре артына яшеренә. Нимес марҗалары, тыела алмыйча, Русиягә пленга алынган нимес солдатларын, үз туганнарын кызганып елый башлыйлар. Русиядә күп айларга сузылган кышлар хакында зарланып хат язуларын әйтәләр. Бик күпләре салкын тиеп, авырып үләләр дә икән. Салкыннан өшеп үлүнең никадәр газаплы икәнлеге турында сүз кыза. Аларны һаман бер сорау борчый: шундый да куркыныч һәм салкын Русиядә халыклар ничек тормыш итәләр? Әфисәргә тагын сораулар ява:

— Анда бай тормышлы кешеләр бармы соң?

— Аларда бик начар тормыш итәләр, кап-кара икмәк ашыйлар. Шуңа күрә дә ерткыч, тәрбиясез, кыргыйлар һәм юньсез алар, — дип, әфисәр Русия халыкларын хурларга керешә. Кинәт кенә бу әфисәргә каршы чыгучы табылды. Юан бер таза карчык:

— Кыргый, тәрбиясез, дигәнгә ышанмыйм. Миндә бер урыс пленный солдаты эшли. Үзе шундый чибәр, шундый чисталыкны ярата. Кухаркаларым ул килеп эшли башлагач, юу-чистартудан бушамыйлар. Теге солдат үзе дә бик пөхтә, башкалардан да чисталык таләп итә, — диде.

— Аларда культуралы халыклар да бар. Төрле кавем яши, дип әйттем бит инде, — ди әфисәр, сүзен бирәсе килмичә.

Калын сигара капкан карт полковник сүзгә катнаша.

— Аурупаның бик күп өлешен Русия биләп тора. Аурупа культурасы аларга үтеп керә тора. Аларның телгә алырлык тәрбиясе юк. Булган культураларына төкереп карыйлар. Русиядә зур байлар, промышленниклар, алпавытлар барлыкка килде. Миллион, миллиардлар белән эш итәләр. Русия миллиардеры Астафьевларны белмәгән кеше юктыр? Әмма халкы начар яши, сәләмә, наданлык көчле. Русия үз халкын савып, интектереп гомер кичерә. Бай яшәргә мөмкинлеге җитәрлек, югыйсә. Бөтен Аурупа илләренә икмәк чыгарып тора ул.

Шушы урында сүз өзелде. Кисәк бик каты свисток бирделәр. Ниндидер бер эшелон шашкын көч белән яннан чабып үтә башлады. Артыннан дөнья җимерелеп калгандай булды. Ул күздән югалырга өлгермәде, әңгәмәгә баткан пассажирларын минут эчендә алып, беренче класслы эшелон да китеп барды. Алар артыннан иренеп кенә безнең эшелон кузгалды.

Прага шәһәренә кайтып туктауга, безне вагоннан төшереп, шәп бер столоваяга китерделәр һәм әбит (төшке аш) бирделәр. Прага шәһәрендә биргән әбит күп яклардан Вена шәһәре әбитеннән дә өстен иде. Ак икмәк, ак макаронлы шулпа, борай боткасы, симез, шактый олы ит кисәге. Чиста киенгән поварлар безгә аш өләшеп йөри башлагач, тоткын башыбыз җиңеләеп, өзелеп әрнегән ач йөрәгебезгә хәл кереп киткәндәй булды. Без, гаҗәпсенеп, бер-беребезгә сорау бирәбез: «Бәй, соң безне дә кешеләр дип тану бар микәнни әле бу каһәр суккан дөньяда?»

Ач кешегә яхшы ашлар бик аз сыман тоела. Ашлар олы телдән узмады, кече телгә барып җитмәде кебек булды. Безне шунда ук вагоннарыбызга китереп яптылар һәм озакламады — безнең эшелон Дрезден шәһәренә таба йөгерде. Кояш тәбәнәгәя иде инде. Без Дрезден шәһәре стансасына килеп җиттек. Вагоннан төшереп, дүртәргә тезеп, грунт юлдан алып киттеләр. Юлыбыз Чехословакия ягыннан Дрезден шәһәре крепостена килеп керә. Крепость өчәр, урыны белән бишәр кат кирпеч-таш белән эшләнгән. Борынгы заманда Зөлкарнәйн (Александр Македонский) патша эшләттергән Кыйстантин[1]

[1]Автор ялгышы. Константинопольне император Константин төзеттерә.

(Константинополь, хәзерге Истанбул шәһәре) крепостенарак охшаган бугай. Дрезден крепостеның өч яктан зур күпер аша керә торган өч капкасы бар. Крепостьның кирпеч стеналары унбиш-егерме метр биеклектә. Кирпеч стенадан соң баскычлап туфрак һәм балчык өелгән. Ул балчык-тауны бу кадәр биек итеп кемнәр, нинди көчләр түгеп өйгәндер?! Өелгән тау-крепость өстендә зур-зур агачлар үсеп утыра. Шуңа күрә Дрезден шәһәре, читтән караганда, урман эчендә утырган шикелле тоела. Урман уртасыннан биек бер манара күренә. Бу манараның дүрт ягында дүрт сәгать. Барысы да бер үк вакытны күрсәтеп торалар. Сәгать битлеге кап-кара, цифрлары ялтырап торган алтын белән капланган. Уклары да шулай ук ялтырап тора. Укларының сәгать ничәне күрсәткәнен өч чакрымнан шәйләргә була. Тонык суккан тавышы җиде чакрымга ишетелә икән. Ярты сәгать икәнен белдереп, кыска гына итеп бер мәртәбә сугып куя. Ә инде тулы бер сәгатьтә — берне, икедә — икене, өчтә — өчне, уникедә уникене суга.

Безне икенче номерлы лагерьга урнаштырдылар. Бу лагерь шулай ук сортировочный булып хезмәт итә иде. Бу лагерьга төрле җирләрдән инвалидларны җыйныйлар, авыр яралы һәм төзәлә алмаслык авыруларны Русиягә кайтаралар. Хезмәткә ярарлы чагыштырмача сәламәт пленныйларны хезмәт лагерена җибәрәләр. Аларны производствога — шикәр заводларына, шахта һәм рудникларга, хәтта урман эшләренә, лесопилка заводларына җибәрәләр. Ай ярым чамасы торганнан соң безне дә беренче номерлы лагерьга озаттылар. Монда бик усал нимес фельдфебеле идарә итә иде. Ул безне ял итмәстән эшкә куа башлады.

Дрезден шәһәреннән көнбатыш якта, ике чакрым читтә, тагын бер крепость бар. Бу крепость эчендә солдатлар казармасы һәм дүрт катлы төрмә бар. Тагын да читтәрәк өч катлы фәхешханә урнашкан. Казарма — солдатлар белән, төрмә — тоткыннар белән, фәхешханә хатын-кызлар белән шыплап тулган.

Бу крепостьны узган вакытта тимер челтәрле тәрәзә аша урыс пленныйларына аерым игътибар күрсәтеп, арестантлар нидер кычкыралар. Ике канаты ике якка ачылып, пәрдәләре җилфердәп торган фәхешханә тәрәзәләреннән хатын-кызлар шаян һәм оятсыз сүзләр белән эндәшәләр, үзләренә ымлап чакыралар. Яшь хатыннар шундый чибәр күренәләр, үлгән йөрәкләрне дә уятырлык. Арестантлар исә тормыш тәртипләренә үзгәреш кертергә кирәклек хакында ымлап кычкыралар. Алар Франц Иосиф һәм кайзер Вильһельмны сүгәләр. «Урысларда көч һәм сәләт җитәрлек. Бирешмәгез! Сез аны булдырырсыз, сез безне сасы камералардан коткарырга тиешсез! Без монда сугышка каршы чыккан өчен килеп эләктек», — дип кычкыралар. Аларга җавап биреп булмый инде. Биек манарада сакта торучы солдатлар һавага ата башлыйлар. Имеш, сөйләшмәгез! Посттагылар урыс әсирләрен сүгәргә керешәләр. Арабызда посттагылар белән әйткәләшерлек кешеләр була. Алар посттагы солдатларны үрти башлый.

— Арестантларыгыз сездән аңлырак икән. Ник сез шундый акыллы кешеләрегезне төрмәдә яткырасыз? Күпме кеше сасы төрмәдә эшсез килеш җан асрый. Эшкә кушыгыз аларны, Австрияне өр-яңадан матурайтып төзерләр иде. Карагыз инде, күпме чибәр хатын-кызлар ир күрмичә тилмереп ята, үзегез булдыра алмасагыз, яннарына барып йөрергә безгә рөхсәт итегез!

Постлар отыры ачуланалар.

— Сөйләшмичә барыгыз! Башыгызны чәрдәкләргә дә күп сорамабыз! — дип кычкыралар, сафның тигезлеген бозмаска кушалар.

Австрия ягында булган чех әфисәрләренең һәм солдатларының Русия пленныйларына ягымлылык күрсәтүләре сокланырлык иде. Бер кызыклы вакыйга истә калган.

Безне крепость эчендәге зур икмәк складына эшкә китерделәр. Таза, юан гәүдәле ир уртасындагы чех каршы алды. Ул строй каршына басып, иң элек исәнлек-саулык сорады. «Урыслар безгә туган тиешле халыклар алар», — дип тә куйды. Төрле җанга ятышлы сүзләр дә әйтеп, күңелне күтәрде. Минем каршыма килеп, аерым исәнләште. «Үз йортыгыздан чыгып, сугышка китүегезгә күп вакыт үттеме? Атаң-анаң, туганнарың бар идеме? Хәлле, чибәр егет күренәсең, анда сөйгән кызың калгандыр, әлбәттә. Кызың да төшеп калганнардан түгелдер, чибәрдер инде. Сине озатканда бик елагандыр, әле дә сагынып көтә торгандыр. Хат аласыңмы Русиядән?» — дип, сораулар белән мине күмеп ташлады. Һәрбер соравына уңай җавап бирдем.

Эшкә керештек. Дугадан дуга өзелми, дисәм хата булыр. Алар атларны бездәге кебек дуга белән җикмиләр. Арбаның алдына беркетелгән юан сыңар тәртә, шуның ике ягына ике атны каеш-арканнар белән генә җигәләр. Йөк артыннан йөк тезелеп кенә килеп тора. Он тутырылган капчыкларны җилкәбезгә салып, складка ташыйбыз. Авыр яралы булу сәбәпле, берничә ел слабосильныйлар командасында ятуым, шуның аркасында икмәк, ашны бик аз бирүләре үз эшен башкарган — бу хезмәткә хәлем җитәрлек түгел иде. Тиз арада хәлем бетте. Капчык күтәреп барганда, тезләрем сыгыла-бөгелә. Теге чех әфисәре арыган һәм йомшак булуымны шунда ук сизеп алды. Кулымнан тотып диярлек кайдадыр җитәкләп алып китте.

— Мин сине тагын да авыррак эш эшләргә кушам, — диде ул көлеп. Пешкән икмәкләр тутырылган складка алып керде. — Күпме ашый аласың — аша, ләкин яшереп алма. Сине тикшереп чыгарырмын. Әгәр дә ипине урласаң, төрмәгә яптырып куярмын. Лагерьга кайта алмассың. Озакламыйча ипи төяргә килерләр. Син ипи төяшерсең. Алар килгәнче, тизрәк ашый башла. Бераз хәл керсен, — диде дә, мине складта калдырып чыгып китте.

Баштарак, курка төшеп, ипине ашарга кыймыйча тордым. Берничә ел инде туйганчы ипи ашаганым булмаганга күрә, бер килограмм килешле бодай икмәген, бер башыннан сындырып алып, ашарга керештем. Яртысын ашаган идем, икмәк төяргә олаулар да килеп җитте. Эш бик кызу булды. Ярты икмәкне ашарга вакыт булмады. Эш тә бетте. Чех әфисәре дә килеп җитте.

— Әйдә чык! — диде миңа.

Калган ярты ипиемне алырга да, алмаска да белми торганда, чех әфисәре:

— Ничә ипи ашадың? Туйдыңмы? Нигә яртысын калдырдың? — диде.

— Бары яртысын гына ашарга өлгердем. Эш бик кызу булды, — дидем мин. Ул калган ярты ипине пәкесе белән икегә бүлде дә ике чалбар кесәсенә тыгарга кушты һәм мине күмер складына китереп кертте.

— Ашап бетер дә, утын тураучылар янына чык. Ипи ашаганыңны беркемгә дә күрсәтмә дә, әйтмә дә, — дип, янымнан китеп барды.

Башыма уй йөгерде. Нинди кешеләр микән бу чехлар? Миңа ул Русия татары дип әйтә. Үзе — Австрия чехы, үзе бик ягымлы, тәрбияле күренә. Шундый усал нимесләр арасында каян килеп чыкканнар болар?

Минем татар икәнемне белгәч, бөтенләй йомшарды. Чехлар без татарларны беләләр дә, яраталар да икән. Каян килә бу? Чехлар миңа «татар» дип сирәк эндәшә, күбесенчә, миңа төбәп, «Мөхәммәди» дип атыйлар. Ягъни, Мөхәммәт динен тотуыма ишарә итәләр. Яһүдләргә дә начар карамыйлар. Чехларны кешелекләре өчен ихтирам иттем. Монда ике төрле халык: берсе — чехлар, икенчеләре — словаклар. Словак кавеменнән булганнар чехларга караганда катырак бәгырьле, алар безгә пленный итеп, кимсетеп карыйлар. Үзләре дә кистереп әйтәләр: «Без чехлар кебек йомшак халык түгел, без, словаклар, катырак холыклы, кешене бик үк кызгана белмибез, усал халык без!» — диләр.

IV

1916 елның көзендә Корбан гаете булды. Бу гаеткә Бүснәдән (Босниядән) бер мулла килде. Мулла дигәнем төрекчә хәрби киемдә иде. Фәсендә укадан эшләнгән ай һәм йолдыз кокардасы ялтырап тора. Татар-мөселман пленныйлары арасындагы кайбер тиктормаслар муллага үтенеч җиткерделәр: «Австрия хөкүмәте Русия мөселманнарын Бүснәгә эшкә җибәрсен иде, мөселманнар арасында яшисебез килә. Монда төрле кавем-халык арасында бозылып-каралып бетәбез», — диделәр. Бу үтенеч татарларга күп хафалар китерде, зур ялгышлык булды. Аңа кадәр Австрия хөкүмәте мең ике йөз кеше сыешлы мәчетне бер атна эчендә корып биргән иде. Теләгән кешегә мәчеттән чыкмыйча намаз укып кына ятарга мөмкин иде. Имеш, мөселманнар арасында татарларга иркенрәк була… Австрия хөкүмәте теге телләре озын мөселманнарның зарын тиз ишетте бит! Тоттылар да, җыйнап, атна-ун көндә безне Бүснәгә, Альп таулары итәгенә озаттылар!

Безнең эшелоныбыз 1916 елның октябрендә Прага шәһәре аша Австриянең баш шәһәре Венаны үтеп, ерак көньяктагы Загреб шәһәренә барып чыкты. Аннан соң Әдрән диңгез буйлап Албаниянең зур шәһәре Тиранага килеп җитте. Аннан соң юл көнчыгыш якка борылды һәм Бүснә иленең баш шәһәре Сараевога таба китте. Аннан юл безне Травник губернасы территориясенә китерде. Загреб шәһәренең матурлыгына исебез китте. Күркәм, төзек шәһәр иде ул.

Бүснә җиренә кергәч, безне кечкенә вагоннарга утырттылар. Бу инде безнең шәмаилләрдә генә рәсемен күргән Һиҗар тимер юлына бик нык охшый иде. Нәзек кенә рельслар салынып, кечкенә паровозлар сөйри торган гаҗәп кечкенә вагоннар. Җыйнак, матур итеп эшләнгән вагоннар ике төрдә: класслы һәм йөк вагоннары.

Бүснәгә барып, Альп таулары сыртында дөнья яралганнан бирле үскән өй юанлыгы ак чыршы һәм бөке (бук) агачларын кисәргә тотынып, эштән йончып, пленныйларга карата иң каты кысынкылыкларны татый башлагач, Бүснә мөселманнарының диндәш халык икәнлеге дә онытылды. Алар хәтта Русия мөселманнарын мөселман дип танудан да баш тартты.

Бүснәдә телләре бер булса да, диннәре буенча төрле халыклар яши. Телләре — хорват теле. Монда хорватлар төп халык булып санала. Хорватлар православие динен тоталар. Элек Төркия бу җирләрне басып алган булган һәм ислам динен хорватларга көчләп таккан. Монда шулай итеп төрле диндәге хорватлар барлыкка килгән. Алар арасында поляклар дине — католик динен тотучылар да бар. Шулай ук яһүдләр һәм нимесләр дә бар. Төрек динен тотучы хорватлар бигрәк усал. Дин буенча алар бигрәк каты шовинистлар. Мөтәгассипләр икән. Аларга бу йогынтыны төрекләр урнаштырган. Төркиядән килеп оялаучы төрекләр Бүснә мөселманнарын гел кыздырып, башкаларга өстереп кенә торалар. Төрекләр безне, Русия мөселманнарын да яратмый булып чыкты. Төрекләрнең күпчелеге шәһәрләрдә яши. Аерым зур җирләр биләп торучы алпавытларның да төрекләр икәнлеген әйтеп китик. Алар әле үз телләрен онытып бетермәгән, картлары төрекчә дә сөйләшә белә. Яшьләрнең хәл башка, телләрен белмиләр диярлек, тәмам хорватлашканнар. Рәсми тел хорват теле хисаплана. Мөселман динен тотучылар үзләрен өстенрәк тоя, баерак тормыш итә. Күбесенчә помещиклар һәм завод-фабрика хуҗалары да алар. Җирләрнең күп өлеше мөселманнарда. Төп хорватлар уңдырышлы җирләрдән куылганнар. Тау башында ярым җимерек такта баракларда торалар. Диннәрен тоту да тыелган булса кирәк. Авылларда мөселман өчен мәчетләр бар, әмма бер чиркәү дә күрә алмассың. Травник шәһәрендә җиде мәчет, бер яһүдләр чиркәве булса да, православныйларның чиркәүләре берәү дә юк. Баш шәһәр Сараевода җитмеш биш мәчет бар. Башка дин ияләре өчен бер чиркәү дә юк. Шәһәрдәге хорватларның киеменә карап кына кайсы дин тотуын белеп булмый. Барысы да бер төстәге кием-салымда. Дин буенча мөрәҗәгать итәргә туры килсә: «Мөселманмы, православныймы?» — дип сорамый булмый. «Православный» яки «католик» дип җавап бирүчеләрнең саны «мөселман» дип җавап бирүчеләрдән бер дә ким түгел.

Дрездендагы лагерь белән саубуллашу безгә ямансу булды. Нигәдер анда хәл өметлерәк тоела иде. Сәламәтлек тә яхшыра төшкән иде, ашау ягы да ничава иде. «Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәннең качасы килә» булып чыкты безнең «Бүснә, мөселман кардәшләр» дип саташуыбыз. Теге ялтыр фәсле мулланың әйтүе буенча, Бүснәгә баргач, безгә һәрь яклап яхшы булырга тиеш иде. Булды, ди!

***

Татарлар арасында төрле кешеләр очрады. Кайбер татарлар, пленга төшкәч тә, Русияне инкяр итеп, фронтта кигән солдат формасыннан баш тарттылар. Алар Австриянең пленныйлар өчен теккән махсус киемнәреннән йөри башладылар. Бик мәзәк форма иде бу — кызгылт вельвет чалбар һәм гимнастёрка, озынчарак бишмәт, соры материядән козырёксыз фуражка. Бу форманы, берәр нәрсәгә алыштыра алмасыннар, диптер инде, бетми торган аксыл лак белән буяп куялар. Күңелсез инде. Мин Русия солдат формасын югалтмаска бик нык тырыштым һәм теләгемә дә ирешә килдем. Яраланганда умырылган чалбар һәм гимнастёркамны чиста итеп юдым, ертыкларын, ишен табып, бер яһүдтән шәп кенә яматып алдым. Берчакны сугышка керергә дә өлгермичә авыр яраланып әсир төшкән авылдашымны очраттым. Аның киемнәре өр-яңа иде. Берничә көн үтүгә авыр яралыларны Русиягә озатырга хәзерли башладылар. Аларга әйбәт киемнәр кигезделәр, ул миңа үзенең яңа киемнәрен бүләк итеп калдырды. Уң кулының уч тирәсенә разрывной пуля тиеп, бармакларсыз калган иде ул. Бу яңа киемгә каты погоннар куеп, погоныма үз полкымның номерын — «191»не матур сәйләннәр белән чигеп төшердем. Илдә хезмәт иткән вакытта рядовой солдатка каты погоннар куеп йөрергә рөхсәт ителми, ләкин пленда йөргәндә аны тикшерүче юк бит! Мин үземнең укымышлы, төшеп калган егет түгеллегемне

ассызыклап, кыланыбрак, урыс әфисәрләренә охшатып йөрергә тырыша идем. Минем шундый формада йөрүемә дежур торучы Австрия солдатларының эчләре поша, миңа ныграк бәйләнәләр дә иде. Имеш, мин — чын урыс солдаты, монда да немесләргә дошман булып калам, эшкә барганда һәм кайтканда һәрвакыт алдагы сафның флангасына бастыралар. Бу урынга баскан пленный солдат, юлда нимес әфисәре каршы очраса, сафтагылар ишетерлек итеп каты кычкырып: «Смирно!» — дип команда бирергә тиеш. Австрия әфисәрләренең эченә нык тидем — берсенә команда бирсәм, өчесенә бирергә «оныта» идем. Команда бирелмәгәч, әсирләр төркеме түш киерергә җыенып, кәпрәеп торган әфисәр яныннан башларын түбән салындырып, тып-тын узып китәләр.

Әфисәрләрнең чырайларын сытып:

— Һай, дуңгыз урыслар! Әфисәргә хөрмәт күрсәтергә дә теләмисез! — дип сүгенеп калуларын күрү миңа бик күңелле тоела иде.

Бервакыт стансадан әбиткә кайтабыз. Эш авыр булса да, бүген табыш белән кайту. Вагоннарга тозлы ит һәм тозлы балык төядек. Карап торучы бер чех иде. Кайтырга тезелгәч, ул безгә эш өчен рәхмәт әйтте, башкалар сыман, кесәләребезне тентеп маташмады. Корсак астына каеш белән кыстырылган кисәкле итләр, симез селёдка балыклары үзебезгә насыйп булды. Мондый чакта күңелләр күтәренке инде. Башта бер Австрия әфисәре очрады. Матур итеп, чыңлатып: «Смирно!» — командасы бирдем. Әфисәр мактап: «Вольно!» — дип команда бирде. Саклап килүче солдатларны да мактап алды, һәрчак шулай эшләргә кушты.

Бераз кайткач, күрәм: ике постовой алдан-арттан торып бер урыс әфисәрен каядыр алып барып яталар. Әфисәр — полковник чинында. Күрәсең, аягы яралы — интегеп, аксап атлый, кулында кечкенә таягы да бар. Әфисәрнең йөзендә безне күрүгә кызганыч сызыклар хасил булды. Аңа да, безгә дә бу хәлебез бик ямансу тәэсир итте. Үз әфисәребез яныннан тыныч кына үтеп китәсе килми бит, аның белән тигезләшүгә, үз илебездә хезмәт иткән чагыбыздагы кебек күтәренке рух, гайрәт белән:

— Взвод, смирно! Равнение на право! — дип кычкырдым һәм кулны хәрәкәтеннән туктаттым. Әфисәребез һушсыз булып елап калды. Ул безгә: «Вольно!» — дип команда да бирә алмады.

Кайчандыр шундый эфисәрләр кул астында хезмәт итүебез искә килеп, йөрәкләр тетрәде. Иртән торулар, шау-шу килеп солдат күнегүләре ясау, занятиеләр үткәрү, ашау-эчү, ял итү вакытлары хәтергә төште. Чын солдат йөрәге һичкайчан да чын эфисәр йөрәген чит күрми ул. Хезмәт һәммә кеше өчен тигез. Эфисәр хезмәте икеләтә җаваплы: үзе дә хезмәтен яхшы үтәргә тиеш, солдатларны да кирәгенчә өйрәтергә бурычлы. Яхшы, тәрбияле эфисәр солдатка таяныч ул. Моны аңламаган солдат чын солдат була алмый. Элек тә ул шулай булды, хәзер ул бигрәк тә шулай.

— Бичара полковник, — диде арабыздан бер солдат. — Солдатларның әсир төшүе була инде ул. Без алгы сафта сугышабыз. Зур чиндагы эфисәрләр дә тоткынлыкта җәфа чигәләр икән...

Аңа каршы җавап бирүче булмады.

Байтак җирләр кайтканнан соң, бер рота чамасы булыр, Австрия солдатлары очрады. Арадан бер нимес солдаты:

— Бер мең тугыз йөз беренче полк, капут! — дип кычкырды.

Нимеснең погонымдагы 191 нче полкны белдерә торган номерны ялгыш укыганын аңлап, аңа каршы:

— Надан гөмбә, дөрес итеп цифр да укый белмисең бит син! Сукыр тәре! —дип кычкырдым. Һәр ике колоннадагылар шаркылдашып көлделәр.

V

Язмаларымда эзлеклелек булып җитмәс дип, кисәтеп куйган идем инде. Искә кайсы вакыйга килеп төшә, шуны теркәп куярга тырышам. Бүснәгә китү чорына әйләнеп кайтыйк әле.

Безнең эшелон Прага шәһәренә таба бара иде. Миңа бу юл бик таныш. Икенче көнне нәкъ әбит вакытында Прага шәһәренә килеп җиттек. Әйбәт кенә ашатырлар дип өмет иттек. Ашатырга уйлап та караучы юк.

— Дрезденда ике көнлек икмәк бирделәр, әбитегез шул була. Сезгә һәр көн саен таратырга, Австриянең артык запас икмәге юк, — дип җикеренделәр постовойлар. Каешлар бушады, эш хөртиләнде. Ике көнлек икмәк кичә әбит вакытында ук ашалып беткән иде. Һәрчак ашыйсы килеп торганлыктан бер-ике кабымлык ипине дә запаска ничек саклыйсың? Моңа хәтле Прага шәһәреннән ничә тапкырлар үттек. Һәрчак тамакны яхшылап туйдыралар иде. Бу юлы ашатмыйча, мәхрүм булып китү бик авыр булды. Австриянең баш шәһәре Венаны сагына башладык. Икенче көнне әбит вакытында Вена шәһәренә килеп җиттек. Ике тәүлек бернәрсә ашамаган идек. Безне вагоннардан төшерделәр. Бик озаклап кабат-кабат санадылар. Монда бер ят фельдфебель дә бар иде. Столоваяга алып килделәр, бер бөртек ярма, бер чеметем он да салынмаган әче кәбестә шулпасы бирделәр. Ул да күп түгел, кеше башына берәр чирпәк тиде. Юл өчен икмәк бирмәделәр.

Шаулаучылар табылды.

— Кайда безгә өченче көнге ужин? Кайда кичәге әбит? Ә бүгенге ужинны кайчан һәм кайсы стансада бирәсез? — дип кычкырдылар.

Тавышлануыбызга ачулары килеп, куалап вагоннарыбызга кертеп тутырдылар. Эшелон тиз генә китмәде. Кич булды. Безгә ужин да бирмәделәр. Икенче көнне кояш чыккач кына эшелон кузгалды. Эшелон Италия границасына таба бара иде. Италия чигенә якынлашкан саен безнең эшелон стансаларда, хәтта ярымстансаларда да бик озаклап китмичә тора. Беренче нәүбәттә фронтка солдатларны үткәрәләр, йә фронт кирәк-яраклары төялгән эшелоннар уза. Без Вена шәһәреннән Италия чигенә унике

көн бардык. Күпме генә ара инде ул. Русия кебек очсыз-кырыйсыз илмени ул Австрия! Унике көн эчендә ике тапкыр да ашарга бирмәделәр. Алҗындык, күпләп үлүләр китте. Сакчылар стансаларда яшереп кенә чи шикәр чөгендере бирә башлады. Ихтимал, безнең вагон постлары гына шулай мәрхәмәтле булгандыр, чөнки башка вагоннарда үлүчеләр тагын да күп булган. Юлга кузгалганда бер мең ике йөз татар әсире идек. Бүснәгә барып җиткәнче дүрт йөз кеше үлгән булып чыкты. Немесләр төгәл халык: үлүчеләрнең барысын да теркәп, «авырудан үлде» дип язып куйдылар.

Менә ерактан ук болытларга терәлеп торган зәп-зәңгәр биек таулар күренде. Бу таулыклар тоташ урманлыклар белән капланган һәм алар Венгрия (Һунгария) чигеннән үк башлана. Шушы таулыклардан Дунай дигән елга юл ала. Көнчыгышка таба сузылып киткән Дунай елгасы Бусанский Бруда (? — ред.) дигән шәһәрнең уртасыннан агып уза. Бу шәһәрнең яртысы Һунгария ягында, яртысы Бүснә ягында. Шушы шәһәргә җиткәч, Австрия-Венгрия эшелонынннан төшереп, яңа эшелонга утырттылар. Тимер юл нәзек рельслардан, кечкенә паровоз һәм вагоннардан тора икән. Вагоннар, алда әйткәнемчә, төрлечә: йөк вагоннары һәм классный, бик матур вагоннар бар. Безне йөк вагоннарына утырттылар. Безнең эшелоныбыз Дунай буйлап Загреб шәһәренә таба юл тотты. Бүснәгә барып кергәч, көнгә бер тапкыр гына булса да, исән калганнарыбызга кукуруз икмәге бирә башладылар. Загреб шәһәрен узганнан соң безнең иптәшләрне һәрбер стансада бүлеп-бүлеп калдыра килделәр. Без төялгән ике-өч вагон нәкъ паровозның башында ук иде. Ниһаять, безне урманлы тау түбәсендә урнашкан бер үзәк Чардак дигән стансага китерделәр һәм дүрт йөз грамм кукуруз икмәге белән фасоль боткасы бирделәр. Чардакта унике кешене генә алып калдылар. Безне тагын арырак — Жулит дигән урынга җибәрделәр. Жулитны без «жулик» дип атадык һәм бу урын безнең өчен чынлап та жулик булып чыкты. Чардактан егерме сигез чакрым ары иде бу урын. Бу урынга хәтта суны да вагоны белән генә китереп торалар. Чардак һәм Жулит төбәкләре Альп тауларының иң биек җиренә урнашкан. Урмансыз ачык тау сыртлары төньяк-көнчыгыштан башлап төньяк-көнбатышка сузыла. Еракта тигезлекләр күренә иде. Шулай ук Албания яклары да түбәнлектә урнашкан. Төнге тынлыкта Италиядәге вулканның үкергән тавышы һәм сирәк-мирәк күккә ялкынлатып ут ыргытуы да күренгәли. Без моны Италия фронтындагы сугыш галәмәтедер дип уйладык. Шул тирәдә яшәүче бүснәкләр моның вулкан галәмәте икәнен аңлатып бирделәр. Вулкан һәр ел Раштуа чорында котыра башлый һәм нәкъ шушы чорларда торым-торымга җир тетрәү була икән.

Чардак дигән стансаның вокзалы алдында бер немес кызы белән безнең русский пленный бер егетнең шаярышканын күрдек. Егет тә шундый чибәр, чигүле погонлы. Ягъни, хәрби мәктәп юнкеры иде. Кыз, немес кызларына хас булганча, кыланчык, горур, тәкәбберле чибәр нәрсә иде. Бездә патриотизм юкка чыкмаган иде, урыс егетенең бу немес кызы белән шаяруын килешмәгән эш дип кабул иттек. Без үзебезне мөселманга санап, бер җиргә тупланмакчы идек, монда нинди генә милләт кешеләре юк! Мөселманлык дип авыз ачучылар бөтенләй калмады. Без монда Русия әсирләре, бетте-китте.

Уналтынчы елның маенда бу егетне безнең янга Жулиткa сөрделәр. Моның сәбәбе — Чардактагы комендант немес әфисәренең әлеге кыз артыннан йөреп маташуы булган. Немес әфисәре урыс егетеннән көнле башлаган. Алар кыз өчен бик каты гына бәрелешеп алганнар. Әфисәр эшне зурга җибәреп, урыс егетен хөкем иттертеп аттырмакчы булган. Ләкин кыз ирек бирмәгән. Урыс егете дә немесчә сөйләшергә бик оста иде. Кыз баш управляющий Аис Миланов кызы иде.

Тихонов Алексей безнең янга Жулитка китерелгәч, безне агитларга, агартырга тотынды, ике тапкыр восставать итәргә җитәкләде. Беренчесендә шактый уңыш казандык. Беренчесе, моңарчы якшәмбе көнне ял бирелми иде. Ял көннәре генә түгел, урыс халкының башка бәйрәмнәрендә дә эштән бушата башладылар. Икенчедән, юньләп эшли алмаган авыру-яралыларга эш көннәренә икешәр крона түли башладылар, әйбәт эшләүчеләргә хезмәт хакын арттырдылар. Өченчедән, өс киемнәре бирелә башлады. Дүртенчедән, тәмәке һәм шырпы бирү тәртибе керде. Шул ук вакытта, ашарга бирүне бик каты кыса башладылар. Әсирләргә бернәрсә сатмыйлар иде. Тик аракы гына саталар. Тихонов безне икенче тапкыр баш күтәртте. Ашатуны яхшыртуны сорадык. Нимес әфисәре:

— Сезгә җитәрлек акча бирелә. Икмәк арттырырга мөмкинлек юк, — дип аңлатты.

Забастовка комитеты сайладык. Комитетта дүрт кеше — өч урыс, бер татар иде. Забастовка дүрт көнгә сузылды. Урыслар һәм татарлар, шулай ук, берничә яһүдләр белән дүрт йөз кешегә җыелдык.

Бишенче көнне эшелонга төялгән жандарм отрядлары килеп безнең баракларны пулемётлар белән чолгадылар. Безгә Тихонов курыкмаска, бер сүздә, нык торырга кушты. Ул үзе барактан да чыкмады. Безне чыгарып тезделәр. Жандармнар коралларын корып:

— Эшкә чыгасызмы? — дип өч тапкыр сорады. Яһүдләр эшләргә риза булып, стройдан чыгып, постовойлар янына барып бастылар. Без, урыслар һәм татарлар, сүзебездә бердәм, нык тордык.

— Туйганчы ашатыгыз, хезмәт хакыбызны тулы итеп бирегез. Без эшкә чыгарга каршы түгел. Хәзер үк кухняларны ачыгыз. Биш көнлек икмәкне хәзер үк кулыбызга бирегез! — дип, таләп куйдык.

Жандармнар бик ачулы, пулемётларны да хутка да җибәргән булыр иде, ләкин жандарм отрядындагы гади солдатлар безгә атудан баш тартты.

— Безнең туганнар Русиядә пленда йөриләр. Без боларны ачка да кырсак, атып та үтерсәк, урыслар безнең братларны шулай үтермәсләрме? — дип кычкырыша башладылар.

Жандарм әфисәрләре фикер алышты. Солдатлар килгән вагоннарына төялеп кире киттеләр. Күп вакыт үтмәде, буш вагоннар тагып, икенче поезд килеп туктады. Баракларыбыздан чыгып тезелергә куштылар һәм «моннан китәбез», диделәр. Строй белән вагоннар алдына китерделәр. Кырыгар кеше санап, вагонга кертеп, өстән бикләп куйдылар. Тихонов белән бер вагонга туры килдек. Тихоновыбызны җаныбыз кебек күрә идек. Вагонга керү белән безнең өстән дә ишекне бикләп куйдылар. Тимер челтәрле тәрәзә аша күзәтеп торабыз: жандармнар баш күтәрүчеләр комитетында булган өч кешене тотып алдылар һәм таза сүс бау белән кулларын артка каерып, өчесен өч чыршыга бәйләп куйдылар. Поезд китте, алар бәйләнгән килеш шунда калды. Эшелон Чардакка килеп туктады. Су сорап, вагон ишекләрен ачтырдылар. Шунда эшләүче пленный ватандашларга бәйдә калучылар хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр. Кичекмәстән аларны азат итәргә куштылар. Әсирләр бер-берсен бәладә калдырмый ул. Шунда ук бер татар һәм бер Златоуст башкорты Жулитка таба йөгерде. Ул иптәшләрнең чынлап коткара алулары хакында ишетә алмадым мин. Ачык булмаган хәбәрләр генә килеп иреште: коткарырга баручыларнымы, әллә бәйләнеп калучыларнымы атканнар икән нимесләр.

***

Бу хәлдән алда булган бер вакыйганы язып китмичә булмый. Жулитта без урман кисүдә эшләдек. Диаметры бер ярым метр юанлыгындагы ак чыршыларны кисеп

аударабыз. Ул чыршыларның буе туксан һәм йөз егерме метрларга хәтле бара. Беренче вакытта без бик яхшы эшләдек. Чөнки, җитәрлек булмаса да, беренче айларда ашарга да ару гына бирделәр. Аннан соң китте инде. Аш дигәне — кәбестә суы, көнгә кеше башына ике йөз грамм кукуруз икмәге, ул да авызга алмалы түгел, күгәреп беткән. Пычкы чүбеме, нәрсәдер кушалар. Без алҗыштык. Эшкә чыгу түгел, болай барактан чыксаң да җилдә йөреп булмый. Кайбер халыклар мәшкә (гөмбә) ашыйлар. Ниһаять, урманны кар каплады. Поезд да йөрүдән туктады. Су түгел, продукт-азык та килә алмый. Бишәр көн аш-сусыз, икмәксез торыла башлады. Үлүчеләр дә күбәйде. Нимесләрдә закон шундый: ачтан үлгән кешенең үлем сәбәбен бервакытта да дөрес итеп күрсәтмиләр, «авырудан үлде». дип язып куялар. Бервакыт алҗулары чамадан ашкан әсирләрне Чардак стансасына, табиб каравына алып киттеләр. Ара — егерме сигез чакрым. Җәяүләп, кар ярып шушы араны үтәргә кирәк. Чардакка үз аягы белән барып җитүчеләр аз булды, күбесе юлда үлеп калдылар. Үлүчеләрнең күбесе олырак яшьтәге тоткыннар иде. Миңа ул вакытта егерме өч яшь иде. Иң артка калып булса да, барып җитә алдым.

Чардакка барып җиткәч, безне бер буш баракка урнаштырдылар. Анда биш көн тордык. Врач каядыр киткән, аның кайтуын көтәргә куштылар. Көтәбез врачны. Гадәттәгечә, ике йөз грамм кукуруз икмәге, вакытында чәй, аш биреп торалар. Жулиттагыдан яхшырак бит. Чәе дә шикәрле. Повар белән үземнең җаным кебек күргән өр-яңа шинелемне алмаштым. Ул миңа кара бубрик шинелен бирде. Повар урыс пленные иде. Сигез йөз грамм килешле бер бодай икмәге һәм бер крона акча өстәде. Мин бер кронага столовойдан бер порция аш сатып алдым. Аш пешмәгән хайван үпкәсеннән иде. Ашны ашау белән эч китү башланды. Эчем авырта, температурам күтәрелде. Ниһаять. врач та килеп җиткән. Безне врачка алып киттеләр. Врач ачлыктан алҗынган халыклардан авыру таба алмый. Авыруы табалмагач, әсирне җәзага тарталар. Богаулап салкын кладовойга ябалар. Врач каршысына мин килеп бастым. Авыруым бар, моны врач та таныды:

— Ошпитал Тороуник! (Травник шәһәренә, госпитальгә!) — дип кычкырды врач.

Шунда булган иптәшләр:

— Сары май кайнаган көнне тугансың икән, иптәш. Безне богаулап амбарга ябалар, ә сине госпитальгә җибәрәләр, — диделәр.

Австрия хәрби вәкилләре минем исем һәм фамилиямне, лагерь номерымны язып алдылар. Икенче көнне Травник дигән шәһәргә озаттылар. Безнең белән бергә әлеге врач үзе дә барды.

Яйце дигән шәһәргә җиткәч, безне эшелоннан төшереп бер чиста һәм җылы баракка урнаштырдылар. Имеш, пересадка була. Баракта әлеге врачыбыз үзе җыйнап алып килә торган больнойларын кабат тикшерә башлады. Бу вакытта инде минем бернинди авыруым да калмаган иде. Врач гаҗәпкә калды. Яралы җирем дә юк. Чөнки күпләрнең аяк-кулларында йә балта ярасы, йә өшеп кабарган яралары бар иде. Ә миндә бернәрсә дә юк. Мин шат һәм җитез йөрим. Врач тикшерде, тикшерде дә, аптырауга калып:

— Чардакта сез нинди авыру белән авырый идегез? — дип сорады.

— Эч китү белән, пан врач. Үзегез дә беләсез, без Жулитта эшли идек. Дүрт көн ашарга бирмәделәр. Чардакта кантингә (ашханә) кереп бер порция аш сатып алдым. Ул чи, пешмәгән хайван үпкәсенән булып чыкты. Моны белсәм дә, ачлыгыма түзә алмыйча ашадым. Шуннан башланды инде хәлләр… Хәзер савыктым инде. Теләсәгез ни эшләтегез…

Врач ябык йөземә карап торды да:

— Ярар, — диде. — Госпитальгә баргач, тагын да тазарырсың, — диде.

«Госпиталь» дигән сүзне зур өмет белән кабул иттем. Иптәшләремнең «сары май кайнаган көнне тугансың икән» дигән сүзләре, мөгаен, рас киләдер, дип сөенеп куйдым.

Травник дигән шәһәргә килеп җиттек. Таулар арасына кысылып утырган шактый зур гына бер шәһәр икән. Шәһәрнең читендә «Резервная казарма» дигән вибуска (вывеска, алтакта) куелган зур, дүрт катлы йортка урнаштырдылар. Госпиталь шушы була инде. Госпитальдә ашау мактанырлык түгел: көнгә ике йөз грамм ипи, бер чирпәк кәбестә яки аз гына каштан оны сибелгән шыбыр су-шулпа һәм ике кашык сып-сыек итеп изелгән бәрәңге яки фасоль бирәләр. Тазар, хәллән шул ашау белән! Ныклап авырып ятучыларга мондый ашның кирәге юк, барыбер җан тәслим кылалар. Минем кебек ачка алҗыган яшь кешеләргә чиссыз (җанга ятмый торган) ашның нәрсә файдасы булсын? Ул гына да түгел, температурасы булмаган авыруларны эшкә куалар. Ком бушату, әрдәнә өю яки стансада вагоннардан күмер бушату, башка төрле йөк төяү һәм бушату, һич тә булмаса, кар яуган арада (гәрчә, ул кар эреп бетеп торса да) шул карны җыеп, арбага төятеп, аны кулдан тарттырып, читкә илттертеп түктерүләр — ачка алҗынып беткән, кеше төсе бер дә калмаган пленныйларны иң соң дәрәҗәдә җәзалау һәм мәсхәрәләү иде.

Аның да өстәвенә, Австрия капралларының шул чиртсәң дә егылырга торган ач пленныйны сугып егулары, кычкырып, кабахәт сүзләр белән сүгүләре, мәсхәрәләүләре үзәккә үтте. Нимес халкының чын йөзе шушы. Дөрес, сакта торучы солдатларның барысы да немесләр түгел. Хорватлар, бүснәкләр, хәтта мөселман бүснәкләр дә, албаннар, молдаваннар, һунгар-венгрлар, чехлар, словаклар да бар. Ләкин болар немесләр приказыннан чыкмыйлар. Немесләр аларга да өстен карыйлар, һәр төрле начарлыкка мәҗбүр итәләр. Ачулары кайный, нишләгәннәрен белештерми башлыйлар. Русия пленныйлары өченче этажда яталар иде. Ишегалдына чыгу өчен йозаклы җиде ишек һәм ишек саен берәр пост аркылы үтәргә кирәк. Бу йорт, госпиталь булудан бигрәк, төрмәне хәтерләтә иде. Мин монда декабрь аенда эләктем. Элекке урынга — Жулитка кире кайтармадылар. Күрәсең, шәүлә-скелет кыяфәтем производствога җибәрүне тоткарлагандыр. Март ае беткәнче гомерем шундый газапта үтте. Эштә йөрүчеләргә фирт

бирәләр. Фирт — әбит саен Әстерхан чикләвеге хәтле йомарланган камыр ул. Аны «галушки» диләр. Бервакыт врачтан фирт бирүләрен сорадым. Миңа врач:

— Син эшләрлек түгел. Без эшләрдәйләргә генә фирт язабыз, — диде. — Сине эшкә яраклы итү өчен, берне түгел, ай дәвамында көнгә уналты фирт биреп торырга кирәк. Һай-һай-һай... — диде, табиб башын чайкап.

Шулай итеп, гайрәтле егет хәленә кайтканчы Австриягә бик кыйммәт төшәчәкмен икән бит. Тизрәк үлүем күпкә яхшырак икән. Врач күземә карап шулай диде. Сәламәтләнеп эшкә йөри башласам, югыйсә, күпкә файдалырак булыр идем, дип уйлаган булам. Немесләргә анысы да кирәк түгел. Максатлары — халыкны мөмкин кадәр интектереп, теге дөньяга озату. Юк, бирешмим, теш-тырнагым белән тормышка ябыштым, язмышны җиңдем — түздем, тәмуг газабына чыдадым. Мине ачлыктан киптерделәр, кыйнадылар, сугышта алган ярамны рәтләп дәваламадылар, тәрбия күрсәтмәделәр. Русия халкы шундый чыдам була. Без мөселман халкына кайда да түзәргә кирәк. Сабырлык лазем. Исән-имин кайтсам, бу каһәр суккан немесләр күрсәткән газаплар хакында киләчәк буыннарга җиткереп калырмын! Бу халыкка, арт сабагын ныклап укытмый торып, акыл кермәячәк.

Минем язмышыма кагылышлы төш күрә торган гаҗәп бер гадәтем бар. Забунлыкта (тоткынлыкта) чагымда күргән бер төшем хакында язып үтәргә булдым. Сугышка керер алдыннан да бер төш күргән идем. Анысын сугышта исән калачагыма, ләкин дошманнар ягында пленда калачагыма юрадым. Запасный батальонда хәрби өйрәнү вакытында булды бу. Гомеремдә суда йөри торган корабка утырганым түгел, күргәнем дә юк иде. Төш болай. Имеш, иптәшләр белән без кып-кызыл ләмнәре актарылып яткан зур бер елга ярына килдек. Яр читендә бер кораб тора иде. Иптәшләр белән корабка төялдек. Кораб кузгалды. Елганың аргы ягына чыгабыз, имеш. Үземнән кечерәк энем өйдә калган иде. Шушы энем дә безнең белән икән, тик корабка утырмады, яр читендә, шул кызыл ләме актарылып аккан елга суында кулларын-битләрен юа калды. Кораб елга уртасына килеп җитүгә давыл купты, кораб күз ачып йомганчы җимерелеп, таралып бетте. Күп иптәшләр су төбенә батты. Мин исә корабның бер идән сайгагына атланып, шәп ат сыртына менеп юырткан кебек, шул такта белән юыртып елганың теге ягына чыга башладым. Шулчакта сул як җилкәмне һәм сул як ботымны бик каты авырттырып нәрсәдер тешләп алды. «Төшлек китабы»нда «корабка утырып елганы кичүчеләр — чит илгә әсир төшәр», дип юралган. Дөрес бит, сугышка кергәч, сул як җилкәм — осколка тиеп, сул ботым пуля тиеп яраландым. Әсир төштем. Ә энемнең шул елгада бит-кул юып калуы — аның минем арттан сугышка китеп, сугышта һәлак булачагы булган икән. Бу вакытларда энемнең сугышка киткән хәбәрен ишеткәнем дә юк иде.

Менә бу Травник госпиталендә ике кич рәттән төшемдә әниемнең баштан-башка кисеп борай күмәче биргәнен күрдем. Юрыйм: мөгаен, дидем, миңа Русиядән посылка килгәндер. Мөгаен, Жулитка кайтсам, ул посылканы алырмын. Шушы төштән соң үземне Жулитка кире җибәрүләрен сорый башладым. Бу вакытларда моңа хәтле аждаһа булып йөргән маҗар-венгр врач урынына икенче хорват врач килгән иде. Аның хакында: «Госпитальне бераз төскә кертәчәк икән. Аш-су да яхшырачак икән», — дигән сүзләр ишетелә башлады. Ләкин бу сүзләргә минем һич тә ышанасым килмәде. Һәнүз (туктаусыз) Жулитка җибәрүләрен сорыйм. Ә яңа врач җибәрәсе килми.

Ул миңа:

— Син һич тә эш эшләрлек түгел бит әле. Анда үләргә кайтмакчы буласыңмы? — ди.

Мин үземнекен тукыйм:

— Кайда үлсәм дә бер инде. Монда бөтенләй тынгылык юк, һәрвакыт эшкә куалар. Ничә ай ятып бер мәртәбә дә фирт бирмәделәр, — дим.

— Ярый соң, — диде яңа врач, — мин сиңа фирт язармын!

— Минем өчен әлегә Австриядә фиртләр үсмәгән, өлешемне Русиядә алырмын.

Врач көлемсерәп торганда өстәлдә таралып яткан карточкаларны умырып алдым да врачка тоттырдым.

— Зинһар, җибәрегез моннан!

Табиб карышмады. Канцеляриягә баргач, ике көнлек кукуруз икмәге бирделәр. Мин аны стройда чакта ук ашап бетердем. Бүгеннең ярты көне, тагын башланмаган ике көн бар. Вагонга утыргач, гражданскийлар белән сөйләшеп, корыч пәкеләремне яртысы кычыткан яфрагыннан эшләнгән арпа камырына алмашып, тиз генә капкалап куйдым. Күренгәнчә, гражданский халыкның да хәле әйбәт түгел икән монда. Халык ярлы яши. Ризык-фәлән сораштырсаң:

— Ништи, ни имам, — диләр. Безнеңчә әйтсәк: «Бернәрсәм юк», — дигән сүз була.

Чардакка кайтып төштем. Әле икмәк алачак көнем тумаган иде. Шулай да икмәк сорагач, отказ итмәделәр. «Озакламыйча Жулитка поварлар белән бергәләп китәрсең. Икмәкне Жулитка кайткач та алырсың, — диделәр. Госпитальгә киткәнче, 1916 елның декабрь аенда эшләгән барлы-юклы хезмәт хакымны канцеляриягә кереп сорадым. Бухгалтер исем-фамилиямне буташтырырга кереште. Минем белән бер фамилиядәге тоткын бар иде. Аның исеме «Ш» хәрефе белән, минем «Җ» хәрефе белән башлана, нимес шуларны бутый.

— Алгансың бит инде акчаңны. Нәрсә баш катырасың? — дип шаулаган була.

Хәлне аңлатам. Бутап бирү ихтималын төшендерәм.

— Әйе, әйе, шул фамилиядәге кеше алган, — дигән була бухгалтер нимес, эшнең асылына төшенгән кыяфәттә.

Читтән исемлеккә күз салам, имза урыны буш, нимес үзе ниндидер тамга гына куйган. Димәк, алдаша, яңадан кайтып йөрмәс дип, акчамны үзләштергән.

Сүземдә нык торам. Лагерь номерымны әйттем. Бухгалтер каушагандай булды. Чыраен сытып кына өч крона акча бирде. Бусы да ярады. Кантингә кереп, аш сатып алып ашадым.

Жулитка кайттым. Лагерьда, моңа кадәр Гастинак дигән җирдә, берничә йөз пленныйны кырып үтереп бетергән нимес суксиры эш итә икән. Суксир — хәрби чин. Русиядә старший унтер дип йөртелә. Бу нимес шундый кансыз нәрсә икән. Мин шушы аждаһа кулына каптым хәзер.

Жулиттагы баракта өч көн Газраилне көтеп яттым. Беркөнне яныма яһүд писаре килде:

— Русиядән сиңа атап күмәч килгән, иртәгә Чардакка барасыңмы посылкаңны алырга?

Эчкә җан керде. Төшем рас чыкты бит. Бардым. Чыннан да, унике кадак борай күмәче, сохари салганнар иде. Сохари арасыннан кечкенә хат килеп чыкты. Энем хакындагы аяныч хәбәрне дә шунда белдем. Ул миннән соң озак тормый сугышка китеп һәлак булган...

VI

Безне яңа урынга күчерәләр. Әсирләр белән бергә иректән тулысынча мәхрүм ителмәгән тотаклар да заводка озатыла икән. Арада таныш Тихонов та бар. Андый-

ларны «ирекле тәрбиядә асралучы тотак», «вольныйлар» диләр иде. Вагоннарга утырту башлангач, вольный пленный Тихоновны озатырга гыйшык тотып йөрүче немес кызы йөгереп килде. Сакчылар куып маташсалар да, кыз тыңламады. Кыз белән егет кавышып, немесчә сөйләштеләр. Без, әсирләр, немесчә аңлый идек инде, барысын күреп, аңлап тордык. Кыз дулкынлана, көлә.

Эшелонны озак тотмадылар. Кыз белән егет саубуллаштылар. Барып җитү белән хат салырга кушты кыз. Кая озатылуыбыз кызга алдан ук билгеле булган, күрәсең. Эшелон кузгалды. Киттек без.

Травник шәһәренә җитәргә өч чакрым калгач, Турбита дигән лесопилка заводына төшерделәр. Яңа урын. Көн бик ямьле, җирсеп үләрлек. Документларны канцеляриягә җыеп алдылар. Австриянең гадәте шул: яңа җиргә килсәң, бер айга хәтле ашау-эчү яхшы гына була. Аннан соң эшләр хөртиләнә инде, чыдап кына тор. Бер көнне пычкы оныннан пешерелгән икмәк китергәннәр. Аны, белмичә, һәркем алды. Ашаган кешеләр бик нык авырдылар. Әсирләр үзара сүз куештылар: яңадан китерсәләр, бу икмәкне алмаска, алучылар була калса, андыйларны үзара хөкем итәргә! Икенче көнне дә шул ук икмәк, өченче көнне дә… Сбор (әсирләрне җыя торган мәйдан) уртасында икмәкләр чүмәлә булып өелде. Әсирләрнең саны — мең биш йөз кеше. Берсе дә тик утырмый, һәммәсе дә эшкә йөриләр. Ләкин икмәкне алмыйлар. Өченче көнне һәммә халыклар тышта аш ашап утыралар. Әбит. Шулвакыт сбор капкасыннан комендант әфисәр килеп керде.

— Өстенә ыргытыгыз! — дип кычкырып, бер урыс тоткыны икмәк чүмәләсенә табан йөгерә башлады. Аның артыннан һәммәбез өемгә ябырылдык. Күз ачып йомганчы, пычкы онынннан пешкән икмәк белән әфисәрне күмеп куйдык. Каяндыр санитарлар йөгерешеп килделәр. Пычкы оны икмәге арасыннан бите-күзе канга баткан һушсыз комедант әфисәрне актарып алдылар һәм носилкага салып алып киттеләр. Әбит вакыты үтте, эшкә чакырып гудок гүләде. Без заводка эшкә киттек.

Кич эштән кайтуга сборны жандарм командасы чолгап алган иде. Безне тезделәр. Жандар әфисәре сорау ала башлады.

— Әнә икмәгегезне кире төяп алып китегез. Үзегез ашагыз андый икмәкне. Без ашамабыз, үлгәнче эшләрбез! — дип шаулаштык. Монда күпчелек урыс һәм татар тоткыннары иде. — Шушы агач икмәкне ашарга мәҗбүр итсәләр, нәрсә эшләр идегез? — дип, бердәм кычкырдык.

Әфисәр артык бәйләнеп тормады. Өелеп торган икмәкләрдән берничә буханка икмәкне алды да солдатларын алып кире китте.

Икенче көнне иртән үк беренче сорт оннан пешкән ак икмәк китерделәр. Мондый сыйфатлы икмәк китерү берничә ай дәвамында барды.

Заводтан унсигез чакрымдагы тауга менеп, ак чыршы кисеп йөрдек. Ачлыктан алҗымадык. Ашатсалар, Русия халкы эштән качмый ул. Русия пленныйларыннан алда монда итальяннар, серблар эшләп мәтәшкәннәр. Эшләренең рәте булмаган. Аларның барын да куып, безне китереп тутырдылар. Теге комендантны пычкы онынннан пешкән икмәк белән күмеп куйгач, яңа комендант бик сак йөрде. Көн саен кухняны һәм биреләчәк икмәкне дә күзәтә иде.

Шулай урман кисеп йөрибез. Унсигез чакрым китеп, тауга менгәч, беренче пункт — гәстилгә туктыйбыз. Заводтан шушы урынга хәтле электр хәрәкәткә китерә торган «сәлбан» исемле һава тимер юлы салынган. Бер тау башыннан икенче тауга башня-

манаралар корып рельс үткәргәннәр, бәләкәй вагонеткаларны юан тимер аркан белән электр сөйрәп йөртә. Шушы ук юл белән тау өстендә киселгән бүрәнәләрне заводка кайтаралар, шушы ук юлдан атларга фураж, кешеләр өчен продуктлар килеп тора. Бүрәнәләрне гәстилгә кечкенә тимер юл белән паровозлар ташый. Бу тимер юл гәстилдән урман арасына тарала. Гәстилдән ары биш чакрым эчендә «яссик» дигән урын бар. Берара яссикта тордык, гәстилдә дә яшәп алырга туры килде миңа. Моңа сәбәп шул булды. Яссикта эшләгәндә бер хорват сакчысы белән тыныша алмадык. Ул мине яратмый, бәйләнә дә тора. Мин аны яратмыйм. Хорватчалап сүгенеп җибәрәм, мин сиңа әйтим. Ят халык арасына барып эләксәң, ни хикмәт, башта шул телдә шәпләп сүгенергә өйрәнеп аласың. Теге хорват белән очрашкан саен сүз көрәштерәбез. Мин Русияне мактыйм, аты-юлы белән сүгеп, Австрияне хурлыйм. Аның үз Хорватиясен мактыйсы килә һәм Австрияне битараф калдыра. Янәсе, аның Австрия белән бер уртаклыгы да юк. Беркөнне сүгешү шулхәтле кызды, хорват түзмәде, мылтык приклады белән шартлатып аркама китереп сукты. Мин дә кыздым, тегенең сары йонлы яңагына сөялле учым белән чатнатып чаптым. Сугышырга тотындык, даулашу бик каты буласы иде. Башка пленныйлар арага керде. Әсирләр ун кеше, постовой берүзе. Сакчы шикләнде, куркуы йөзенә чыкты. Ачы тавыш белән: «Атам!» — дип кычкыра. Беләбез, мылтыгында бер патрон бар иде, шул сыңар патронны стволына озатып, һавага атып җибәрде. Бу инде әбиткә кайтканда, юл өстендә булды. Постовой безне капрал янына китереп бастырды да жалоба бирде. Капрал каты итеп әрләргә кереште. Арадагы башкорт солдаты эшнең ничек булганлыгын яхшылап сөйләп бирде. Капрал минем гимнастёркамны ачып аркамны карады.

— Барасыңмы госпитальгә?! — дип кычкырды.

— Барам, — дидем.

Капрал:

— Поезд килгәнче мин сине арестка ябып торам әле, — диде.

Кечкенә караңгы бүлмәгә ябып, өстемнән йозаклап куйды. Әбит алдылар. Ашадылар. Караңгы бүлмәдә гарәпчә хөтбәләр укыйм, кычкырып җырлыйм, такмак әйтәм, арест бүлмәсен җимерердәй итеп, барабан кагам, биим. Миңа тынычланырга кушалар.

— Комачауламагыз! Мин бит молитва укыйм, — дигән булам.

Поезд килде. Теге усал сакчы белән, бүрәнәләр өстенә утыртып, госпитальгә җибәрделәр. Гәстилдә кундык. Икенче көнне тагын ике татар өстәлде. Алар да авырып киткәннәр. Без өч татар булдык. Безне башта таудан түбәнге заводка төшерделәр, аннан инде янә поездга утыртып, Травникка җибәрделәр. Зур бер баракта кундык. Ару үзәккә үткән, бик каты йоклаганмын. Иртән постовой килеп уятты һәм миннән сорау ала башлады:

— Теге ике иптәшең кая китте? — ди.

Аптырап тик торам. Иптәшләрем төнлә качкан булып чыкты. Алар андый теләкләре барлыкны бер дә сөйләнмәгәннәр иде. Җай чыкканга карап эш иткәннәр булса кирәк. Мунча кереп, киемнәрне парда тотканнан соң, врач карый башлады.

— Кай җирең авырта?

— Кичә постовой приклад белән кыйнады. Арка авырта...

Врач даруларга кереште. Үзе мине шелтәли:

— Сакчыга каршы дәшмә, карышмаска кирәк. Артыгын тырышып эшләмәгез. Азрак селкенеп торсагыз, җитеп торыр. Беләм, сезгә ашау җитми. Ни эшләмәк кирәк? Сугыш әсирен бер илдә дә кунак итеп сыйламыйлар. Аңлыйсызмы?..

— Эшләмәгән өчен кыйнамады ул мине. Мин Русияне мактадым. Шуңа ачуланып кыйнады, — дидем. — Эш ягына сынатмыйбыз алай…

Албан врачы яхшы күңелле иде:

— Үз илен мактарга һәркемнең хакы бар. Чыннан да, Русия яхшы илдер, ләкин сез бит Русияне кесәгезгә салып йөри алмыйсыз. Русия бик зур ул. Ай-һай зур ул Русия!.. Русиягә тиңләшү өчен йөз Австрия җире кирәк, — диде. Дәвалау сеансы беткәнлеген белдереп: — Сине госпитальгә алып калып булмый. Өч көн баракта ял ит. Белешмә язып бирәм. Болай чиста күренәсең, мунча кереп килүең дә бик ярый, — диде. — Син бер дә урыс кавеменә охшамагансың. Алар чисталыкны арткарак калдыралар.

— Татар кавеменнән мин. Мөселман булам. — Үземнең эчне пошырып торган сорауны бирдем. — Мине, сакчыга һөҗүм иткәнсең дип, арестка япканнар иде. Кичә әбит тә бирмәделәр. Кайткач та мине арестка япмасланмы? — дидем.

Врач тавышын басып:

— Әйттем бит инде. Карышып эш чыгара алмассың. Юк нәрсә өчен дә үз-үзегезне кыйнатмагыз. Сез — хәрби пленныйлар, буйсынмый чарагыз юк. Сез генә түгел, Австрия властена без, албаннар да буйсынабыз. — диде. — Үзем дә мөселман өммәтеннән булам. Без сабыр халык, уйламый-нитми тәртипне бозарга һич ярамый. Син әле яшь кеше, өеңдә эти-әниең көтә торгандыр. Бу мәхшәрдә исән калу ягын кара, — дип киңәш бирде.

Больницада яткан берничә тоткынны кушып, безне кире заводка кайтардылар. Теге ике әсирне качырган өчен минем белән әрләшкән сакчыны кулына богау салып, күмер складына япканнар икән. Безне гәстилдә алып калдылар, нигәдер яссиккаҗибәрмәделәр. Шулай итеп, теге хорват постовоеннан котылдым. Ишеттем, ул сакчыны күмер складыннан алып, Италия фронтына җибәргәннәр икән. Мин аны фронтка киткән чакта күреп калдым. Мыскыллап:

— Бар инде, кораллы маскаллар (Мәскәү кешесе, урыс солдаты) белән сугышып кара. Мондагы коралсыз маскалларны кыйнарга йөз яшьтәге картларның да көче җитә, — дидем.

Дөресен әйткәндә, албан табибы мине Травник больницасына белеп җибәрмәде. Анда әсирләргә начар караш иде. Больницада ятып кайтучылардан хәтта хәл-әхвәл сорашмый идек. Исән кайтып керүләре бер могҗиза була иде. Тик теге хорват белән һаман саен ызгышудан гарык булып, барырга җөрьәт иткән идем госпитальгә. Больницага барган чакта, канцелярия тирәсендәге бакчада, әлеге вольный Тихоновның теге нимес кызы белән култыклашып йөргәннәрен күрдем. Тихоновны урман эшенә җибәрмәделәр, бухгалтериядә калдырганнар иде.

— Бәхетле парлар кавышканнар! — дип кычкырдым аларны күрүгә. Алар да мине танып, сөенгән шикелле көлештеләр. Егет мине үз янына чакырды. Постовой җибәрмәскә иткән иде. Егет нимесчә:

— Җибәр аны, монда килсен! — дип кычкырды. Челтәрле койма янына килдем. Исәнлек-саулык сорашкач, егет миңа әйбәт сыйфатлы ун данә папирос бирде. Тартмый идем, папиросларны уптым ике кронага постовойга саттым, Травник шәһәренә килгәч, ара табып, ике липушка (көлчә, кабартма) сатып алып ашадым.

Гәстилдә эшләү уңай иде. Җәйлектә монда урман җимешләре дә бик уңа икән. Җир җиләге белән башланып китә. Кура җиләге һәм кара бөрлегән, хәтта чикләвек һәм груша агачлары да бар. Урман грушасын кышкы айлар узганчы җыеп була. Урман грушасы җиргә коелгач әчеп бетә. Гәстилдә кофеханә, кантин, ларёк бар. Акча булса, барын да сатып алырга мөмкин.

Ахыры киләсе санда. ■

«МИЛЛИ ТЕАТР ҮЛСӘ, ТЕЛ ДӘ БЕТӘ»

Җәй башында башкалабыз Казанда Төрки халыкларның XII «Нәүрүз» халыкара театр фестивале булып узды. Әлеге чарага Төркия, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Азәрбәйҗан, Татарстан, Кырым, Алтай, Саха-Якутия, Чувашстан, Башкортстан республикаларыннан килгән милли театрлар катнашты. Шул уңайдан, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының директоры **Илфир Илшат улы Якуповка** драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Рәдиф Сәгъди** берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

— Илфир әфәнде, әлеге чара элеккеләреннән нәрсә белән аерылды, гомумән, фестиваль төрки дөньяның милли театрлары үсешенә нәрсә бирә?

— Фестивальне уздырыр алдыннан бер ел кала үзебезгә шундый максат куйдык: биредә катнашкан театрларның саны түгел, ә алар куйган спектакльләрнең сыйфаты иң беренче урында булыр-

«Кара йөзләр».
Башкортстан

«Зилзилә».
Казакъстан

«Илаһи уен».
Азәрбәйҗан

«Коркыт тәүбәсе».
Казакъстан

«Тискәрене
буйсындыру».
Казакъстан

га тиеш. Әлбәттә, сан мәсьәләсе бөтен регионнарга да кагылмый. Мәсәлән, Якутиядә дүрт милли театр эшли. Ә Алтайда нибары бер милли театр. Бу очракта безнең сайлау мөмкинлегебез юк. Кайбер театрларның нинди милли спектакле бар, шуны чакыртып алдык. Икенче үзенчәлек — бу елгы фестиваль Казакъстанга багышланды, алардан өч театр һәм бер фольклор төркем кабул иттек. Гадәттә Казакъстаннан ел саен унлап гариза килә. 1989 елны Россия театр әһелләре беренче «Нәүрүз» фестивален дә Алматыда үткәргән.

Без бит әле «Нәүрүз»гә Мәскәү, Петербург калаларыннан, чит илләрдән продюсерларны, театр белгечләрен һәм тәнкыйтьчеләрен дә чакырабыз. Фестиваль кысаларында аларның төрки театрлар белән элемтәсе ныгый, төрки менталитетны ныграк аңлый, төшенә башлыйлар. Бу милли театрлар өчен искиткеч файдалы. Мәсәлән, Колумбиядән килгән кунагыбызны Алтай театры артистларының тамак төбе тавышы белән җырлау ысулы бик кызыксындырды. Ул алтайлылардан бер артистны Колумбиягә, үз театры артистларын өйрәтергә чакырды. Бу төркиләрнең гореф-гадәтен, осталыгын бөтен дөньяга таныту, дигән сүз. Төрки, татар театрлары үз эчләрендә генәябылып яшәргә тиеш түгел.

Алтай теле — үлеп баручы борынгы тел. Сер түгел, бүген күп кенә театрлар керем, тамашачы артыннан куып пьесаларны урыс телендә сәхнәләштерә башлады. Берзаман алтайлылар фестивальгә урыс телендәге спектакльнең видеоязмасын җибәргән иде. Урыс телендә алтай акценты белән искиткеч гүзәл итеп уйный башладылар. Әмма мин шунда ук видеоны туктаттым, аларның сәнгать җитәкчесенә: «Ничек сез милли театрлар фестиваленә русча спектакль җибәрергә ниятлисез?! — дип шылтыраттым. — Мин афишага ни дип языйм? Монда килгән тамашачыларга ничек аңлатыйм?» Нәтиҗәдә алар спектакльне үз туган телләрендә тәкъдим итте. Шулай итеп, фестивальнең төрки телләрне саклауда, аны дөнья халыкларына танытудагы өлеше дә бәһасез.

«Нәүрүз» — милли театрларны бер мәйданга җыючы зур чара. Россия Федерациясенең матурлыгы аның төрлелегендә. Без төрле телдә сөйләшәбез, төрле телдә уйныйбыз. Иң мөһиме: туган телеңне һич тә онытырга ярамый! Ә милли театр үлсә, нинди регион булуга карамастан, тел дә бетә, дигән сүз. Үзебез турында дөнья халкына әйтеп, үзебезнең миллилекне күрсәтеп торырга кирәк. Төрлелектән Россия Федерациясе таркалмый, ә ныгый гына. Фестиваль тәэсирендә шуны да әкренләп аңлый башладылар.

— Аңларга тиешләр! Аңламасалар, кораб бер якка аваргa мөмкин.

— Илнең бербөтенлеген саклар өчен милли фестивальләр кирәк тә инде! Бу чараны бары тик Камал театры залларында гына да үткәрү мөмкинлеге бар. Әмма без аны берничә урында — Камал, Рус яшь тамашачылар, Качалов, Тинчурин һәм «Әкият» театрларында оештырабыз. «Нәүрүз» бер үк вакытта безне дә берләштерсен, бер

казанга салып бутасын! Бер елны Качалов исемендәге Рус драма театрының җитәкчесе Александр Славутский үзендә төрекләрне кабул итте. Шуның нәтиҗәсе буларак, алар Төркиягә гастрольгә барып кайтты. Бу бит «Нәүрүз» фестивале аша килгән бәйләнеш! Артистлар үзләре эшләгән театрга килеп фестивльнең спектакльләрен карый, кызыксына, тәҗрибә туплый. ГИТИС профессоры, мәшһүр театр тәнкыйтьчесе, чит илләр театры кафедрасы мөдире Алексей Бартошевич та бирегә килде, безнең театр әһелләре белән күрешеп аралашты.

— Без төрки театрлар фестиваленә нигәдер урыс, Мәскәү, Петербург театр белгечләрен чакырабыз. Алар безнең хәлне, гореф-гадәтне, традицияләрне аңлап бетерәме соң?

— Әлбәттә, күбесе — Мәскәү, Петербург белгечләре. Шул ук вакытта Уфа, Казакъстан тәнкыйтьчеләрен дә чакырабыз. Мәскәү белгечләре алга таба да фестивальдә мәртәбәле кунакларыбыз булачак. Аларны чакырмасак, бу белгечләр Мәскәү һәм Петербург казанында гына батачак. Без аларга менә мондый дөнья да бар әле, менә болай да була әле, дип үзебезнең төрки дөньяны күрсәтергә тиеш.

— Мәскәү, Петербург белгечләре үзәктәге урыс театрлары белән чагыштырып карагач, безнекеләргә нинди бәя бирә?

— Сәнгатьтә монысы начар, монысы әйбәт дип әйтергә ярамый. Безнең үз юлыбыз. Алар безгә сокланып, ә кайвакыт көнләшеп тә карый. Кайберләренең — ак көнләшү, ә кайберләренең кара көнләшүләре сизелә! Милли театрның рухын аңламаучыларны без бүтән чакырмыйбыз. Ә Казанга килергә теләк белдерүче театр белгечләре искиткеч күп. Без бит әле аларны биредә театрлар белән генә таныштырып калмыйбыз, төрле экскурсияләргә дә йөртәбез. Театр белгечләре Казан, татар халкы тарихы, мәдәнияте белән киңрәк таныша, еш кына безне үрнәк итеп тә куялар. Чит милләтне белмичә, аны тәнкыйтьләсәң яки аның беләнниндидер уртак эш алып барсаң бу зур наданлык булыр иде һәм алар моны бик яхшы белә.

— Киләчәктә дә төрки халыкларның «Нәүрүз» халыкара театр фестивале шушы күркәм рухта дәвам итәрме, аны кайсы төбәккә багышларга уйлыйсыз?

— Төрки дөньяның театрлары «Нәүрүз» фестивале белән елданел ныграк кызыксына. Азәрбәйҗан театр җитәкчелеге килеп, кайчан безгә багышларсыз икән, диде. Шундый ук сорау белән бүтән төбәк вәкилләре дә мөрәҗәгать итте. Кунаклар бу чараның матурлыгын, асыл мәгънәсен күрде. Икенче елга безнең мәдәни-агарту форумы булачак, ә 2017 елда янәдән милли театрлар Казанга килеп спектакль куячак. Без ул елны исә Саха-Якутия Республикасына багышларга ниятлибез. Аларның театры һәм фольклор сәнгате гаять кызык һәм үзенчәлекле. ■

ШӨГЕР ЯГЫ – КАРА АЛТЫН ИЛЕ

(тарихи-документаль очерк)

Гәрәй Рәхим,
Татарстанның халык язучысы

МӘДӘНИЯТ

1754 елда хәзерге Чирмешән районының Утыз Имән авылында туган һәм 1834 елны хәзерге Лениногорск районының Тимәш авылында (Шөгергә якын гына) вафат булган һәм шундагы зиратка күмелгән бөек татар шагыйре һәм галиме **Габдерәхим Утыз Имәни** «Кыйссаи Йосыф» әсәрен өйрәнеп фәнни хезмәт алып барган чорында нәкъ менә элеккеге Шөгер районының Сарабиккол (Әби авылы), Куакбаш, Түбән Чыршылы (Бу авылда икенче бер бөек галимебез Риза Фәхреддин мәдрәсәдә укыткан. Риваятьләргә караганда, кайчандыр бу Тимәш авылына Габдерәхим Утыз Имәнинең туган авылыннан күчеп килгән кешеләр нигез салган. Ул шушы авылларда яшәгәндә төрки һәм татар дөньясында, беренчеләрдән буларак, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен фәнни эшкәртеп, халык арасында таралган төрле кулъязма ядкярләрне берләштереп, аерым китап рәвешенә китерә. Утыз Имәнинең бу кулъязмасы 1839 елны Казанда аерым китап булып басылып чыга. Китапның катыргы белән тышланган 90 битле төп кулъязмасын 1947 елны Шөгер районының кайчандыр Утыз Имәни яшәгән һәм эшләгән Куакбаш авылы кешесе, шагыйрьнең дүртенче буын вәкиле **Гамәлетдин улы Ходайфә** Утыз Имәни тормышы һәм иҗатын өйрәнүче Казан галиме доцент **Үлмәскамал Беляевага** бүләк итә. Кулъязма китапта бу әсәрне эшкәртүне Габдерәхим Болгари (Утыз Имәни) 1824 елда тәмамлады, беренче мәртәбә аның улы Әхмәтҗан күчереп язды, дигән язу бар. Кулъязма китапның бу нөсхәсен Куакбаш кешесе Нигъмәтулла Хөсәен улы 1884 елны күчереп язуы турында әйтелә.

Әйткәнемчә, 1983 елны Казанда «Кыйссаи Йосыф» бик нык тулыланган, затлы бизәлгән рәвештә (540 бит күләмендә), академик басма булып дөнья күрде. Бу тирән фәнни һәм әдәби китапны төзүче, төп текстны әзерләүче, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы — якташым, әлеге Утыз Имәни гомер иткән Тимәш авылында туып-үскән күренекле татар галиме **Фазыл Фәсиев**.

Шулай итеп, Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» әсәрен 1830 еллардан алып 1983 елга кадәр булган чорда (150 еллар чамасы) фәнни өйрәнү, нәшер итү, бөтен дөньяда пропагандалау эшендә Шөгер төбәгендәге авылларда туып-үскән һәм яшәгән шәхесләр Татарстанның

* Ахыры. Башы быелның 7 нче санында

Элеккеге Шөгер районы Федотовка авылының күренекле Родионовлар гаиләсе (сулдан уңга): гаиләнең иң олы кызы Роза, Бәкер курортын төзи башлаган атаклы табиб Максим Игьнатьевның якын дусты, Бөек Ватан сугышы ветераны, авылда озак еллар «2 нче бишьеллык» промартеле һәм Ленин исемендәге колхоз рәисе булып эшләгән, Шөгер районының күренекле шәхесе Василий Семёнович, гаиләнең икенче баласы, гомер буе нефть кудыру эшендә эшләгән Ривал, берсеннән-берсе кечкенә өч баланы сугыш елларыннан исән-сау алып чыккан, тирә-як авылларның атаклы тегүчесе, авылның моңлы җырчысы Фёкла апа, Татарстанның халык язучысы, Шөгер төбәге турында күп әсәрләр язган әдип Гәрәй Рәхим (Григорий), сугыштан соң дөньяга килгән төпчек, Лениногорск һәм Әлмәт нефть оешмаларында эшләп пенсиягә чыккан Вера. Фотомонтаж – монда сурәтләнгән гаилә әгъзаларының төрлесе төрле елларда фотога алынган.

мәдәни тарихында шактый тирән эз калдырырлык гамәлләр кылганнар икән.

Шөгер ягы татар мәдәниятенең төрле өлкәләрендә эшләп халкыбызның рухи кыйммәтләрен арттыруга лаеклы өлеш керткән тарихи шәхесләргә бай.

Шул ук Габдерәхим Утыз Имәнинең улы **Әхмәтҗан Утыз Имәни** Тимәш һәм Сарабиккол авылларында яши, мулла, мөгаллим, шактый танылган шагыйрь була. Аның шигырьләре татарлар яши торган төрле төбәккә кулъязмалар рәвешендә тарала, берничә китабы басылып чыга. Әхмәтҗан әсәрләре Казан Дәүләт университеты фәнни китапханәсенең кулъязмалар фондында саклана. Бер бәйләм шигырьләре 1992 елда дөнья күргән «Татар поэзиясе антологиясе»нә дә кертелде. Ул антологияне дә миңа, Шөгер малаена төзү насыйп әйләде.

Алда әйтелеп киткәнчә, татар халкының күренекле галиме, дин әһеле, әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Риза Фәхреддин Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсендә эшли. Ул монда үзенең шактый исемдәге фәнни һәм әдәби әсәрләрен иҗат итә. Шушы Чыршылы авылы халкыбызның тагын бер атаклы шәхесе — галим һәм җәмәгать эшлеклесе **Һади Атласи** тормышы белән дә бәйле. Ул XX гасыр башында шушы авылның **Габделфәттах мулла кызы**, бик укымышлы туташ **Хөсникамалга** өйләнә. Атласи еш кына Әлмәттән Чыршылы авылына килеп йөри, бу якларның тарихын өйрәнә, документлар туплый. Ул Бөгелмә өязенә кергән авыллар тарихы турында китап яза башлый, әмма аны тәгәлләргә өлгерми, 1929 елда НКВД тарафыннан хаксызга хөкем ителгәндә өендәге тентү

вакытында кульъязманы юкка чыгаралар. Һичшиксез, бу кульъязмада Бөгелмә өязенә кергән Шөгер яклары, бигрәк тә, сөекле хатыны туган Түбән Чыршылы авылы турында язмалар булмый калмагандыр.

Шөгер төбәгенең Зәй-Каратай авылы да халкыбызның мәдәни тарихында зур урын тота. Зәй-Каратай бертуган ике бөек шәхеснең — шагыйрь, тарихчы, фольклорчы, мәгърифәтче, мөгаллим **Фазыл** һәм атаклы мәгариф галиме, педагог **Кәбир Туйкиннарның** туган авылы. Бүгенге көндәге билгеле әдәбият галиме **Әнвәр Шәрипов** та шушы авылда туган.

Югарыда санап кителгән шәхесләрнең кайберләре Шөгер төбәгенең игелекле туфрагында туып үскән, кайберләре бу якларда яшәп, татар халкының рухи байлыкларын арттыру өчен иҗат иткән, олы хезмәт күрсәткән.

Бүгенге көндә әлеге олы галимнәр, шагыйрьләр, җәмәгать эшлеклеләренең лаеклы дәвамчылары бар. **Әгъдәс Борһанов**, **Марсель Әхмәтҗанов**, **Римма Ратникова** — әнә шундыйлар. Олы аксакал галимебез Фазыл Фәсиев, республикабызның атаклы галимнәре, бертуган **Индус** һәм **Энгель Таһировлар,** галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләре бертуган **Рамил** һәм **Рафаэль Вәлиевләр, язучылар Мәхмүт Газизов, Әнвәр Шәрипов, Таһир Шәмсуаров, Әнәс Исхаков, Җәүдәт Дәрзаман, Кәшшаф Әмиров, Разим Вәлиуллин, Роза Хафизова, Людмила Аланлы, Касыйм Тәхау** һәм Шөгер төбәгендә яшәп иҗат итүче дистәләрчә сәләтле яшь әдип-шагыйрьләр — әнә шундыйлар. Вакытсыз вафат булган, әдәби әсәрләрендә халкыбыз тарихын, каһарманнарыбызны зур осталык белән сурәтләгән күренекле язучы Җәмит Рәхимов та Шөгер төбәгеннән.

Әлеге әдипләрнең барысы да Лениногорскида татар әдәбиятының күренекле язучысы **Шамил Бикчурин** оештырган һәм озак еллар җитәкчелек иткән яшь язучылар түгәрәгендә беренче әдәби чыныгу алды. Хәзер ул Шамил Бикчурин исемендәге «Чишмә» әдәби берләшмәсе дип атала. Бу әдәби җәмәгать оешмасы Әлмәттә Татарстан Язучылар берлеге бүлеге оештырылганчы ук, 1958 елның октябрь аенда рәсми рәвештә эшли башлый. Лениногорск әдәби түгәрәге республикабызның иҗади тормышында шулкадәр актив эшли ки, анда Татарстанның төрле районнарында туып-үсән яшь язучылар тартыла. Шундыйлардан **Альберт Хәсәнов**, **Флёра Гыйззәтуллина**, **Рәмзия Габделхакова, Шамил Маннапов**, **Рәшит Бәшәр**, **Әсрар Галиев** беренче әсәрләре белән Лениногорск әдәби түгәрәгенә килә, озак еллар аның утырышларында катнаша һәм соңыннан күренекле язучылар булып китә.

Татарстан гимнының сүзләр авторы, Бөек ватан сугышы ветераны, бик күп популяр җырлар авторы шагыйрь **Рамазан Байтимеров** та шушы күренекле әдәби берләшмәнең актив әгъзасы. Аның «Туган ягым» дигән шигыренә көй язган күренекле композитор Рөстәм Яхинның шушы җырга язган музыкасы Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан Татарстан гимны итеп кабул ителә. Әмма «Туган ягым» җырының сүзләрен рәсми гимн өчен яраклаштырырга кирәк була. Рамазан Байтимеровның «Туган ягым» дигән җыры сүзләрен гимнга яраштырып эшләүдә миңа якыннан катнашырга туры килде. Татарстан Дәләт Советы рәисе урынбасары, гимн сүзләре өстендә эшләү комиссиясе рәисе Римма Ратникова бу турыда матбугатта: «Гимнның сүзләрен камилләштерүгә шагыйрь Гәрәй Рәхим аеруча зур өлеш кертте» — дип язды. Гимн сүзләрен эшкәртүдә Р.Байтимеровның кызы Гөлшат бик актив катнашты.

Шөгер ягы — мәгариф өлкәсендә дә кызыклы төбәк. **Таһировлар**, **Вәлиевләр**, **Җәмит Рәхимов**, шагыйрь **Таһир Шәмсуаров**, тагын СССРның,



Әгъдәс Борһанов

Марсель Әхмәтҗанов

Римма Ратникова

Россиянең, Татарстанның төрле икътисади, иҗтимагый, фәнни, хәрби һәм башка өлкәләрендә зур дәрәҗәләр алган дистәләрчә күренекле шәхесләр атаклы Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлады. Бу мәктәп менә инде 100 ел буе саф татар телен, әдәбиятын саклап, аларны нәтиҗәле һәм сыйфатлы укытып туган халкыбызга лаеклы белгечләр әзерләүгә юл ача.

Узган гасырның утызынчы елларыннан алып алтмышынчы елларына кадәр Шөгер районыныда ике татар урта мәктәбе эшләп килде.

Районның икенче татар урта мәктәбе минем туган авылым Федотовкада иде. Бу мәктәптә районның көнбатыш төбәгендәге әлеге атаклы Сарабиккол, Түбән Чыршылы, Куакбаш, Кирлегәч, Ормышлы, Яңа Елховой авылларында җидееллык мәктәпне тәмамлаган яшьләр килеп урта белем ала иде. Кызык, чын мөселман авыллары яшьләре керәшен авылына килеп, саф татар телендә белем алды.

Федотовка урта мәктәбендә дә Иске Шөгердәге шикелле районыбызда туып-үскән атаклы укытучылар эшләде. Районның күренекле шәхесе **Миргасыйм Вәлиев** озак еллар мәктәп директоры булды. Аның уллары — бүгенге көндә Татарстанның күренекле галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре игезәкләр **Рамил** һәм **Рафаэль Вәлиевләр** безнең авылда туып, балачакларын Федотовка урта мәктәбе ишегалдындагы яшел чирәмдә үткәрде — директор яши торган өй мәктәп ишегалдында иде.

Безнең мәктәп татар теле һәм әдәбиятына аеруча игътибар бирде. Чөнки татар теле һәм әдәбият укытучыбыз шул ук Иске Шөгердә туып үскән гаять талантлы укытучы, күренекле галим Һади Атласиның укучысы, үзе дә шигырьләр иҗат иткән **Саҗидә Сөләйман** кызы **Мулюкова** иде. Ул чакта әле XX гасырның 40-50 нче елларында Татарстанда яшьләр журналы юк һәм Совет хакимияте андый журнал чыгаруны тыеп килде. Әмма яшь иҗатчыларда үз журналларын булдыру теләге бик көчле иде. Шуны искә алып, Саҗидә апа җитәкчелегендә без, яшь каләм тибрәтүчеләр, айга бер тапкыр «Яшь иҗатчы» дигән кульязма журнал чыгара башладык. Журналга үз шигырьләребез, хикәяләребез, мәкаләләребез тупланып, журналның һәр саны класстан-класска йөреп укылды. Журналның тиражы бер генә данә булуына карамастан без аны мәктәпкә кергән һәр ата-ана, кунаклар, югары оешмалардан килгән вәкилләр дә укуын тели идек. Шул максаттан без журналның бер почмагын тишеп бау бәйлибез һәм мәктәп коридоры диварына элеп куябыз. Янында өстәл һәм урындык була — журналны алып укы да, кире урынына элеп куй.

Бүгенге көндә минем архивта аның бер саны сакланып калган. Безнең мәктәпне тәмамлап, соңыннан озак еллар Казан телевидениесендә иң актив тележурналист булган **Мөкаддәс Юсупов** бу журналларда күп шигырьләрен дөньяга чыгарды. Иске Шөгер мәктәбе шикелле үк безнең мәктәптән дә шактый гына фән, әдәбият һәм башка өлкәләрдә уңыш казанган шәхесләр чыкты.

Мин Федотовка урта мәктәбен 1959 елда тәмамлап, Казан Дәүләт университетына укырга кердем һәм бөтен гомеремне әдәбиятка, язучылык эшенә багышладым. Безнең мәктәпне тәмамлаган **Антипов Вадим** Иванович, Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлап, башта Казан шәһәрендә, аннары Чабаксар шәһәренең баш прокуроры булды. Хәзер ул Россия генераль прокуратурасының Түбән Новгородтагы Идел буе федераль идарәсе начальнигы булып эшли. Вадим Иванович Россия Федерациясенең юристлык өлкәсендәге иң яшь генералы.

Безнең авылда туган, Федотовка һәм Иске Куак авылларында урта белем алып, гомере буе СССР күләмендәге иң күренекле Казан Оптика-механика заводында инженер-конструктор булып эшләгән **Ефимов Пётр Васильевич** та — бүгенге Лениногорскиның күренекле шәхесе. Ул — бу заводтагы ябык конструкторлык фәнни лабораториясенең СССР хәрби көчләрендә, бигрәк тә космонавтика өлкәсендә кулланыла торган оптик приборларны уйлап табу төркеме җитәкчесе. Пётр Васильевич уйлап тапкан һәм гамәлгә ашырылган күп кенә оптик приборлар СССРның космик ракеталарында, җир тирәли әйләнгән кешесез һәм космонавтлар идарә иткән космик корабльләрдә дөньяда беренче мәртәбә файдаланыла. Сүз дә юк, гаплади урман, тау, чокырлар арасындагы Федотовка авылы космосны яуларлык егет үстерүе белән чиксез горурлана.

Бөтен гомерен нефтьчеләр сәламәтлеген саклауга багышлаган тәҗрибәле табиб **Кузьмин Василий** Егорович та безнең авыл егете. Ул Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаганнан соң гомере буе, пенсиягә чыкканчы, Әлмәттә нефтьчеләрнең сәламәтлеген саклау буенча санитарлык пунктын җитәкләде, фидакяр хезмәте өчен Татарстан хөкүмәте тарафыннан «Республиканың атказанган табибы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Соңгы елларда безнең авылдан тагын бер талант күтәрелеп чыкты. Ул композитор, җырчы, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы Людмила Аланлы. Ул татар шагыйрьләре һәм үз шигырьләренә көй яза, аларны һәм халык җырларын республикабызның зур фестивальләрендә, конкурсларында үзе башкара, радио-телевидение аша музыкаль чыгышлар ясый.

***

Без һәрвакыт күпмилләтле туган Татарстаныбызда төрле милләт вәкилләренең үзара дус, тыныч яшәүләре белән горурланабыз. Бу җәһәттән Шөгер ягының көнбатыш төбәге, Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россиядә дә уникаль бер төбәк! Нибары 500 кв.километр чамасы мәйданны биләгән бу төбәктә, уртача һәм зуррак 13 авыл урнашкан. Шушы 13 авылда — 9 милләт һәм этник группа вәкилләре яши. Әйтик, Сарабиккол, Түбән Чыршылы, Кирлегәч, Куакбаш, Ормышлы авылларында саф Казан татарлары, Иске Варваринкада руслар (аларның бабалары монда 1830 елда Пенза губернасының Арбищево авылыннан күчеп килә), Яңа Варваринкада украиннар (алар монда 1905 елда Украинаның Чернигов өлкәсеннән күчереп утыртыла), Мордва Карамалкасында мордвалар, Яңа Елховойда чыкылдаган мишәрләр (алар монда 1895 елда хәзерге Әлмәт районының Иске Елховой дигән атаклы авылыннан күчеп утыра), Совет власте елларында гына төзелгән Мичурин авылында та-

тарлар белән чувашлар, XIX гасырның утызынчы елларында нигезләнгән Кузьминовка авылында чувашлар һәм мордвалар (мукшы), XVI гасырда ук нигез салынган минем туган авылым Федотовкада (тарихи исеме — Аналык (ягъни «Ана авылы») — керәшеннәр, Иске Куак авылында руслашкан поляклар һәм французлар яши. Бу Куак авылының тарихы бик кызыклы. 1654 елда, рус-поляк сугышы вакытында, Смоленск янындагы сугышларда бик күп шляхтичлар, ягъни поляк солдатлары русларга әсир төшә. Бу чорда рус дәүләте көнчыгыш җирләрен яулап алу максаты белән Кама аръягы хәрби ныгытмасын төзи. Хәзер аның Яңа Чишмә калдыклары сакланып калган. Россия хөкүмәте, Смоленскида әсир төшкән 478 шляхтич гаиләсен шушы хәрби ныгытманы саклау өчен Яңа Чишмә кальгаларына күчереп утырта. Бу поляклар урыслаша башлагач, Рәсәй хөкемдарлары тирә-яктагы татарларны буйсындырып тоту өчен, шляхтичларның бер өлешен элеккеге Шөгер районының Федотовка (Ана авылы) һәм Сарабиккол авылларына якын гына урынга, Шушма елгасы белән Куак суы дип аталган инеш кушылган җиргә күчереп утырта һәм тирә-як авыллардан талап, зур чәчүлек мәйданнары булган җир бирә. Әле хәзер дә Иске Куак авылының җир биләмәләре безнең авылның сыер фермаларына кадәр килеп терәлгән.

Ә 1812 елда Наполеон гаскәрләрен җиңгәч, Рәсәй хөкүмәте әлеге сугышта әсир төшкән 256 француз хәрбиен дә Иске Куакка китереп урнаштыра. Алар арасында бер штабс-офицер, 5 обер-офицер була.

Әмма озакламый, Иске Куакның урыслашкан шляхтичлары һәм французлары тирә-як татар авылларының усалланмавына, үзара тыныч яшәргә омтылуларына күнегеп китә һәм алар белән бик дус яши башлый. Авылларында зур базар ачып, әлеге 13 авыл кешеләрен җәлеп итә.

Менә шул заманнардан башлап,

Ә 1812 елда Наполеон гаскәрләрен җиңгәч, Рәсәй хөкүмәте әлеге сугышта әсир төшкән 256 француз хәрбиен дә Иске Куакка китереп урнаштыра. Алар арасында бер штабс-офицер, 5 обер-офицер була.

бүгенге көнгә кадәр, Шөгер ягының әлеге күпмилләтле төбәгендәге 13 авылда яшәүче 9 милләт һәм этник төркем вәкилләре (рус, татар, поляк, француз, украин, чуваш, мордва, мишәр, керәшен) беркайчан да бер-берсенә корал күтәрмичә үзара дус булып, кирәк чакта бер-берсенә ярдәмләшеп яши. Толерантлыкның, милләтара һәм динара дуслыкның, җир йөзендә үзара аңлашып яшәүнең иң олы мисалы түгелме соң бу?! Нәни генә төбәктә 9 төрле яшәү рәвеше, гореф-гадәте, холкы 9 төрле булган адәмнәр төркеме ничә гасырлар, ничәмә йөз еллар кулга-кул тотынып, дус, иптәш һәм туган булып яши.

Бу мәсьәләләрдә дә Шөгер төбәге, Шөгер ягы бөтен дөнья халыкларына үрнәк булырлык матур яши. Ул — Татарстанның горурлыгын арттыручы уникаль бер төбәк!

***

Шөгер төбәгендә башланган «Лениногорскнефть» НГДУсы — бөтен Татарстан нефте тарихын үзенә туплаган, данлы Татарстан нефте тарихының көзгесе ул! Әйтергә кирәк, татар нефте тарихы рәсми, дәүләт күләмендә алып барылуга соңгы 70 елда гына түгел, ә аның борынгы заманнардан ук халык хуҗалыгында кулланыла башлау тарихы да хәзерге «Лениногорскнефть» идарәсе эш алып барган территориягә, бигрәк тә элеккеге Шөгер районы һәм аның күршеләре булган нефть чыганакларына карый. Бүген без һич икеләнмичә: «Кара алтын — Татарстан горурлыгы, ә аның әнкәсе — Шөгер төбәге!» — дип әйтә алабыз. ■

ИДЕЛНЕҢ БОРЫНГЫ ҮЗӘНЛЕГЕ

Николай Петров*

«Аерым шәхесләрне баету өчен халыкны үлемгә дучар итүгә караганда милләтнең киләчәген кайгырту өстенрәк».

Фукидид, борынгы грек тарихчысы, я.э.к. 460-400 нче еллар

Халыкка, милләткә дөньяда яшәү, үзенең киләчәген булдыру өчен иң кирәкле шартларның берсе – тору урыны, яшәү ареалы һәм аның уңышлы көн күрү өчен яраклыгы. Борынгы нугай-кыпчак бабаларыбыз заманыннан аермалы буларак, Евразия киңлекләрендә генә түгел, хәтта Җир шарында да яңа территория, яңа илләр үзләштерү мөмкинлеге күптән беткән. Бу эшләрне бүгенге техник-икътисади чаралар, хәтта хәрби көчләр белән дә гамәлгә ашыру мөмкин түгел.

Татарстан халкы, ата-бабаларыбыздан табигый мирас булып калган уңай климатлы һәм бай табигатьле Идел-Йорт өчен Тәңрегә чиксез рәхмәттә булып, әйләнә-тирә мохитнең кадерен белеп яшәргә тиеш. Идел бассейнында, елганың урта агымында урнашкан мәйданның әле дә тиешле әһәмият бирелмәгән байлыгы бик күп. Шуларның берсе — эчә торган су. Җир асты катламында уннарча миллион еллар дәверендә җыелып, бүгенгәчә сакланып килгән су резервларының бәяләп бетергесез кадерле чыганаклары бар.

* Петров Николай Иванович — ярты гасыр дәвамында су белән тәэмин итү тармагында эшләгән белгеч-инженер.

Ни кызганыч, бабаларыбыздан калган бөек мирас — җир өстендәге елга, күл сулары инде үзләренең табигый көчләре белән яңадан чистара алмаслык итеп бозылды, пычранып бетте. Чират җир асты суларына да килеп җитте.

Соңгы 50-60 ел эчендә техник прогресс, шәһәрләрнең зураюы, химия сәнәгатенең котырып үсеше, авыл хуҗалыгында минерал ашламалар, пестицидлар, гербицидлар һәм башка агулы матдәләр куллану нәтиҗәсендә елга суларының, шул исәптән Иделнең дә агулы, шакшы суга әйләнүе эчәргә яраклы җир асты суларының киләчәк тормыш өчен әһәмиятен күтәрә.

Футуролог галимнәр күзаллавынча, киләсе гасырларда булачак халыкара сугышларның төп сәбәбе — эчәргә яраклы табигый су өчен рәхимсез көрәш булуы ихтимал.

Казан халкы һәм республикабызның башка шәһәр-авылларында яшәүче кешеләргә эчә торган су чыганакларының иң ышанычлысы — Идел елгасының җир катламы астында күмелеп калган борынгы үзәнлегендә, аның 50-100 метр тирәнлектә сакланган «Яшел Үзән», «Столбище», «Су кыры» («Сокуры») һәм «Лаеш» атамалы сусаклагычлары, фән телендә әйткәндә — «подземные водоносные горизонты». Ул үзәнлек бүгенге Иделнең, Куйбышев сусаклагычының сул як ярлары белән янәшә, 10-20 чакрым арада, якынча Яшел Үзән — Дәрвишләр бистәсе — Столбище — Су кыры — Лаеш тирәләреннән уза.

Геолог галимнәр аңлатуынча, борынгы үзәнлек (палеодолина) моннан 10 миллион еллар элек — соңгы бөек бозлавык заманында барлыкка килә һәм Скандинавиядән, Кола ярымутравыннан боз составында килгән ком-гравий катламнары белән тулып, елганың иске юлын кабатлаган хәлдә, җир асты горизонтларындагы сусаклагыч булып кала.

Салкын сугыш кызган 1970-1980 нче елларда, Идел буе шәһәрләренең эчә торган су чыганакларын атом коралы фаҗигасеннән саклап калу чараларын эзләгәндә, Урта Идел гидрологик экспедициясе Казан тирәсендәге югарыда әйтелгән җир асты суы чыганакларының тәүлегенә 300 мең куб.м күләмендә искиткеч югары сыйфатлы, эчәргә яраклы су бирә алачагын ачыклый.

Шуннан чыгып, 1990 нчы елларда җирле хөкүмәтнең җаваплы министрлыгы җир асты су чыганакларын пычранудан саклау, аларны киләчәктә Казан халкы өчен эчә торган суның төп

чыганагы итү турында берсеннән-берсе гүзәл карарлар, нәзакәтле боерыклар кабул итте. Кызганыч ки, алар берсе дә үтәлмәде, инде онытылып та беттеләр. Алай гына да түгел, бу зонада искеләре өстенә, җир асты сулары өчен тагын да зыянлырак, гаять тә куркынычрак сәнәгать оешмалары төзелде һәм алар хәзер дә «хуҗаларына» зур табыш китереп бик «уңышлы» эшләп килә.

Мари Иле, Яшел Үзән, Биектау, Лаеш районнары һәм Казан тирәсендәге чишмәләр, күлләр, һичшиксез, шул борынгы җир асты сулары белән бәйле булып, аларның катлаулы бер гидрологик система тәшкил итүләре күптән ачыкланган. Шунысы кызгыныч, бу күл һәм чишмәләргә дә безнең бүгенге мөнәсәбәт искиткеч начар, бик түбән дәрәҗәдә.

Хәзерге көндә Казан шәһәрен үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы өчен төп чыганак булып Куйбышев сусаклагычы тора. Ул суга сәнәгать пычраклары (диоксин, фенол, авыр металлар, хлор, хлорорганик матдәләр, фосфатлар, һ.б.), авыл хуҗалыгында кулланылган агулар (органик һәм минерал ашламалар, гербицидлар, пестицидлар), Идел бассейнындагы барлык авыл-шәһәрләрнең коммуналь хуҗалыкларыннан калган шакшы суларны чистарту корылмаларының «тырыш хезмәте» — барысы да җыела. Өстәвенә, ачык су бассейнына бүген-иртәгә нинди яңа агулар үтеп керәсен анык кына әйтү дә мөмкин түгел.

Соңгы 6-7 елда бу матдәләр турында ачык язу тыелды, аларның ашамлыкларда һәм суда барлыгы темасы «дәүләт сере»нә әйләнде. Азыктагы һәм эчә торган судагы әлеге матдәләрнең кеше организмына рөхсәт ителгән микъдары Россиядә 0,000035 мг/л, ә АКШта һәм Халыкара норма буенча 0,00000003 мг/л. Бу 1000 мәртәбә азрак дигән сүз. Өстәвенә, санитария нормалары буенча, Европа илләрендә эчә торган су сыйфатын 100дән артык, ә Россиядә исә нибары 50ләп күрсәткечтә генә тикшерү каралган. Дәүләт үз кулы белән раслаган шул «льготный» нормативны тикшереп билгеләү өчен генә дә Казанда тиешле лаборатория җиһазлары юк. Бу мәсьәлә белән кызыксынган гражданнарга Роспотребнадзор түрәләре шулкадәр буталчык, югары химик-биологик белемле кеше дә аңламаслык кинаяле, тайгак җаваплар биреп утыралар.

Куйбышев сусаклагычындагы берсеннән-берсе зарарлы агулы химик матдәләрнең шәһәр су чистарткыч корылмаларында тиешле югарылыкта чистартылуы хәтта теоретик яктан да каралмаган, аның технология буенча да, икътисади яктан да мөмкин түгеллеге белгечләр тарафыннан инде күптән ачыкланган...

Соңгы 40-50 елда тереклек дөньясы өчен коточкыч агу булып танылып, америкалылар тарафыннан Вьетнам сугышында кулланылган диоксин группасы матдәләре, җентекләбрәк өйрәнелгәннән соң, «химик СПИД» кушаматы алдылар. Диоксин агуының зәгыйфь, җитешмәгән балалар тууына, онкология, яман шеш авыруларына зур сәбәпче булуыннан тыш, кешенең иң нәзберек урыны булган баш мие сыйфаты — интеллект, абстракт уйлау, анализлау, фикерләү һәм нәтиҗә чыгару сәләтен юк итүе билгеле.

Узган ярты гасыр эчендә 150 миллионга якын кеше яшәгән Россиядә дөньяда танылырлык, Бертран Рассел, Карл Ясперс, Мартин Хайдеггер кебек Европа, Америка фикер ияләре белән янәшә куярлык дәрәҗәле бер генә философ-фикер иясе дә күренмәве, Нобель премиясе лауреатларының чагыштырма саны әйтергә дә оят дәрәҗәдә аз булуы шуңа бәйле. Соңгы 100 елда Махатма



Ганди, Уолт Уитмен, Лев Толстой кебек гигантларның да тиңдәшләре үсеп җитешмәве бер дә шатлыклы хәл түгел. Бу — кешелекнең ялгыш юлга кереп баруы турында Галәм-табигатьнең борчулы кисәтү хәбәре булуы бик мөмкин.

Кискен мәсьәләне хәл итү өчен Иделнең борынгы үзәнлегендә булган сусаклагычлар нигезендә эчә торган су заводы төзергә кирәк. Дөньяның алдынгы, мәдәни дәүләтләре үрнәге күрсәткәнчә, милләтнең генофондын саклап калу өчен бүген башка чара юк. Андый завод Ашхабадта 1990 нчы еллардан бирле эшли. Тәүлеккә һәр кешегә җитәрлек 4 литр эчә торган суны завод халыкка бушлай бирә. Заводның өч тәүлектә эшләп чыгарган суы бөтен шәһәр халкын тәэмин итәргә җитә, атнаның калган өч көнендә завод шул ук чиста су нигезендә сәүдә өчен башка эчемлекләр ясап сата. Шулай итеп бөтен чыгымнарын каплап, табышлы гына эш алып бара. Андый заводлар Россиянең дә байтак шәһәрләрендә, шул исәптән Петербург һәм Мәскәүдә дә бар. Әмма аларда су, Ашхабадтан аермалы буларак, халыкка акчага сатыла.

Бүген кибетләрдә сатыла торган полиэтилен (полиэтилентерефталат) шешәләрдәге вак «фирмалар» җитештергән су сыйфаты белән дә, күләме белән дә шәһәрдәге чиста су проблемасын хәл итми. Зур табыш китерү сәбәпле 50-60тан артып киткән бу «фирмалар» элементар санитария нормаларын бозмыйча эшли дә алмый, тикшерүче җитди дәүләт органнары өчен «шәхси салым»га тоткарсыз, күндәм «савым сыерлар» булып хезмәт итә.

Казанда узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле халык контроле астында эшләячәк эчә торган су заводы төзү өчен ачык акционерлык җәмгыятен оештыручы теләктәшләр төркеме эшләп килә. Иделнең борынгы үзәнлегендә булган бай мирас — җир асты суларын шәһәр халкына җиткерү өчен дәүләтнең катнашуы, хөкүмәтнең бюджет һәм административ ресурслар белән булышуы кирәк. ■

«ТАШНЫ БАШ БЕЛӘН ЯРЫП ҮЗ ЮЛЫН АЛДЫЛАР...»

Нәкый Исәнбәт

Нәкый Исәнбәт
улы режиссёр Празат белән

Татарстан радиосы фондында татар әдәбиятында һәм сәнгатендә якты эз калдырган олуг шәхесләрнең язмалары бар. Күпләре инде якты дөньядан китеп барса да, төрле вакыйгалар уңаеннан ясаган чыгышларында аларның мөбарәк тавышлары, фикерләре саклана. Шулар арасында Нәкый Исәнбәтнең 1966 елда (ярты гасыр элек!) Тукай-Кырлай мәктәбе укучылары алдында сөйләгән сүзләре, безнеңчә, бүген дә аерым игътибарга лаек…

Рөстәм Акъегет

Тукай турында сөйләгәндә, аны Пушкин белән чагыштырырга һәм аны **«Татарның Пушкины»** дип атарга яраталар. Турыдан-туры мәгънәдә булмаса, бу чыннан да шулай. Чөнки Пушкин урыс поэзиясенә нигез салса, Тукай – татарның яңа шигърияттен тудыра.

Мәгълүм булганча, Пушкинның әдәби мирасы һәрьяклап тулысынча өйрәнелгән, тикшерелгән, барланган, хәтта аның әсәрләренең сүзлекләренә хәтле бар. Бу хакта борчылмаска мөмкин. Ә менә Тукайга килгәндә моны әйтеп булмый.

Тукай теле хакында... Белгәнебезчә, Тукайның **«Мөхәммәдия» дәвере**, ягъни борынгы китаплардагычарак югары стильдә гарәп, фарсы сүзләрен мул кулланып иҗат иткән чоры бар. Ул чорда

язылган әсәрләр шактыйга җыела. Алар күп, алар — шагыйрьнең мирасы. Бу әсәрләрне мин бик җиңел укыйм. Хәтта күбесен күңелдән, яттан да сөйләп бирә алам, чөнки мин Тукайның замандашы. Ә менә хәзерге яшьләр, балаларыбыз Тукайның бу телен аңлый, үзләштерә алырмы? Алсалар, ни дәрәҗәдә? Әйтерләр: «Нигә кирәк ул? Тукай үзе дә бу телдән ваз кичеп чын татарча яза башлаган бит», — диярләр. Шулай. Ләкин Тукайга бүгенге әдәби телнең нигезен салу өчен элеккеге әдәби телне, аның традицияләрен ныклап өйрәнергә, иҗади үзләштерергә кирәк булган. Тукайның *«Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата»* дигән фәкать бер шигырь юлы да бу фикерне раслый булса кирәк.

...Без беләбез, Тукай Казанда яшәгәндә **«Болгар»** номерларында да торган. Номерның тәрәзәләре татар халкының риваятьләренә кергән атаклы Кабан күленә караган. Кабан күле нинди серләрен сөйләгән соң шагыйрьгә? Искә төшерик әле:

Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян,
Таки яшьрән күл төбе булсын гаян.
Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр,
җиз карьяләр,
Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк.
Су анасы — бик явыз, йөзе кара, —
Ел да бер угланны йә кызны ала.
Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.
Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар, Барча малны ушбу күлгә сачтылар.
Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».
Шул заманнан бирле, кем,
алтын-көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.
Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр, —
Дип гакыллы зур хәкимнәр сөйлиләр.
Киптисә, бер дәфга кузгалып бары —
Күл буеның мәдрәсә талибләре
Барча байлыкны җыячаклар, имеш,
Һич һөнәрсез бай булачаклар, имеш».

Күрәсезме, Габдулла Тукай серле Кабан күле аша, риваятьләрдә сурәтләнгән әкияти күренешләр аша Казанның тарихын, татар халкының тарихын ачкан да салган. Уйлап карасак, бер кечкенә генә шигырьдә никадәр гыйбрәт, никадәр фаҗига ята. Ни өчен барган бу сугышлар? Ни өчен күпме кеше һәлак булган да нихәтле халык кырылган, корбан булган? Байлар, ханнар өчен сугышмаган безнең изге бабаларыбыз, алар Ватан өчен, нәселебез өчен, халкыбыз өчен, туган телебез, мәдәниятебез өчен кан койган, башын салган. Без мәдәниятле, тарихлы һәм мираслы халык. Шуны саклау өчен сугышкан татар халкы...

...Сезнең яшьтә Тукай кем булган? Ятим бер бала. Хәзерге кебек тәэмин ителгән әйбәт тормышта яшәмәгән. Аңа хәзерге кебек мәктәп ишекләрен киң ачып, рәхим ит, дип тормаганнар. Безнең әдипләребезнең, безнең шагыйрьләребезнең тормышлары бик шәптән булмаган. Аларны бу яктан бәхетле санап булмый. Аларның күбесе тумыштан ятим булган. Тукай ятим, Мәҗит Гафури ятим, Акмулла ятим. Күп язучыларыбыз бичара, үксез кешеләр. Халкыбызның шагыйрьләре дворян баласы булып тумаган, тук тормышта үсмәгән. Безнең халык шагыйрьләре ташка баш бәреп, ташны баш белән ярып, тормышта үз юлын алганнар. Үз көчләре, үз тырышлыклары белән тарихыбызны, мирасыбызны өйрәнеп, традицияләребезне, рухи байлыкларыбызны барлап шушы әдәбиятны торгызганнар.

Хәзер без ятим түгел инде, үзебезнең җөмһүриятебез, хөкүмәтебез бар, мәктәпләребез бар. Инде Тукай мирасын гына укырлык, аңларлык дәрәҗәдә булырга тиешбез. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

КАДЕР КИЧӘСЕ – Күп кенә галимнәр фикеренчә, Рамазанның 27 нче кичәсе, *ләйләт әл-кадер*. «Кадер кич» тә диләр. Шулай да Кадер кичәсенең кайсы төнне булганы төгәл итеп кенә билгеләнмәгән, ул сер булып саклана. Пәйгамбәр үзе Кадер кичәсен Рамазанның соңгы 10 көнендә эзләргә киңәш иткән.

Бу кичәдә изге гамәлләрнең савабы башка кичәләргә караганда күпкә артык дип исәпләнә, чөнки Мөхәммәд галәйһиссәламгә Коръән-Кәрим аятьләре («Галәк» сүрәсенең биш аяте) шушы кичәдә иңдерелә (вәхи килә) башлаган. Кадер (кадир, ягъни кодрәт) кичендә тәүбә кылган бәндәнең барлык гөнаһлары ярлыканыр. Мөселманнар бу төнне йокламый үткәрәләр: мәчеттә намаз укыйлар, дога кылалар, Коръән-Кәримне укыйлар. Бу кичәдә Аллаһы һәр бәндәсенең язмышы турында, аның тәкъвалыгына һәм догаларына нисбәтән, карар кабул итә.

«Кадер кичәсендә Мөхәммәд галәйһиссәламнең җаны, җиргә иңү өчен, Аллаһы Тәгаләдән рөхсәт сорар. Аллаһы Тәгалә рөхсәт бирер, гареш астыннан Мөхәммәд галәйһиссәламнең җаны иңәр, һәр мөселман-мөэмингә сәлам бирер». (Җәмаледдин Бикташидан.)

Халык арасында бу кичәдә күктә якты күренә һәм шул балкышны күзәткән кешенең барлык теләкләре кабул була, дип ышану бар. Гомумән, бу төннәрдә төрле гаҗәеп хәлләр, могҗизалар булырга мөмкин икән.

Коръән-Кәримдә 97 нче сүрә «Кадер кич сүрәсе» дип атала, аның өченче аятендә: «Ләйләтү-л-кадри хәйрун мин әлфин шәһрин», ягъни «Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк», диелгән.

Гомумән, Мәүлана Мөхәммәд Али комментарийларында ләйләт әл-кадер рамазанның 25 нче, 27 нче яки 29 нчы кичәсенә туры килә, дип искәртелә (Исламның төрле мәзһәпләрендә).

Тукайның «Кадер кич» шигыре бар. Текстолог Рашат Гайнанов фикеренчә, бу шигырь «Кадер» сүрәсендәге һәм кайбер башка сүрәләрдәге аятьләрнең татарча шигъри яңгырашыннан гыйбарәт.

//Һәр кешене Хозыр Ильяс дип бел, һәр кичне кадер киче дип бел. Сөләйман Бакыргани.

КАЗАН АДМИРАЛТЕЙСТВОСЫ (АДМИРАЛТИЯСЕ) *тар.* – Пётр I фәрманы буенча, 1718 елда Казансу буенда *Елантау* тирәсендә *(Бишбалта бистәсе)* Идел һәм Каспий флотилияләре өчен кораблар төзү өчен оештырылган. Кораблар төзергә йөзьяшәр нарат һәм имәннәрне ки-

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

Адмиралтия бистәсе

сеп кайтару өчен бик күп халыкны, нигездә татарларны шушы адмиралтиягә беркеткәннәр. Аларны алман сүзе белән — *лашманнар* дип атаганнар.

Кораблар өчен кайтарылган агачны адмиралтия тирәсендәге чокырда «тозлаганнар».

1710 елда Казанда Балтыйк диңгезе өчен «Орёл», «Солнце», «Полумесяц», «Северная звезда», «Город Казань» кораблары, аннары Азов диңгезе өчен 8 кораб төзелгән.

Казан адмиралтиясе 1829 елга кадәр эшләп килә. Тулаем алганда, биредә Каспий һәм Балтыйк флотлары өчен 400 чамасы төрле кораблар — фрегатлар, бриглар, люгерлар, аллиотлар һ.б. төзелә. Адмиралтия конторасы 1827 елда Әстерханга күчерелгән.

Соңрак та әлеге урын *Адмиралтия бистәсе* дип атап йөртелә. 1767 елның 26 маенда Казанга Идел буйлап Екатерина II «Тверь» исемле галерада килә һәм бу зур ишкәкле корабны Казанда калдырып китә. Галера озак еллар *Адмиралтия бистәсендә* (совет чорында — *Кызыл армия бистәсе* дип тә йөртелгән) агач ангарда тарихи ядкяр сыйфатында саклана һәм 1963 елда ут төртеп яндырыла. (М.Глухов «Казанский ретро-лексикон»ында бу ангар бала-чага шуклыгы аркасында 1955 елда янган дип яза, башка чыганакларда 1954 датасы да очрый. «Тверь» галерасының моделе Татарстан дәүләт музеенда бар.

Император Павел I Идел аркылы чыккан ботик та «Тверь» галерасы белән бергә торган, ул да шул вакытта харап була. Бусы Казан верфьләрендә төзелгән һәм сакланып калган бердәнбер судно булган.

КАЗАН ЕГЫЛГАН КӨН *тар.* — Һиҗри белән 959 нчы, миляди белән 1552 нче елда, шәүвәл аеның 22се, ягъни 1 октябрь (сишәмбе көн). Унике еллык (төрки) хайван календаре буенча Сычкан елының Гакрәб аенда булган фаҗига.

Сугышта 150 мең кешедән торган Мәскәү гаскәре катнаша. Казанны 33 мең яугирдән торган милли гаскәр саклый (3 меңе нугайлар, чирмешләр дә күп булган).

//«Рас килде — фаразлар хаклыгын кара син! /Ачып хәтернең тоз сибәр ярасын. /Кан һәм сөякләр түшәлгән бу кала /Котырган этләргә каласы…» дигән тетрәндергеч юллар бүгенге шагыйрьнеке (Мөхәммәт Мирзаныкылар). *Яна Казан! Дөрлидөрли яна. /Утта яна изге Коръән, әфтиякләр. /Җиргә чүгә-чүгә тәре үбә /Сатлык җанлы, зәгыйфь аңлы бәкләр.* Флёра Гыйззәтуллина. ■

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Әгъзам Фәйзрахманов

«1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советы сессиясендә Республиканың Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителде. Без хәзер 30 августны ел саен Республика көне буларак билгеләп үтәбез.

Декларация Татарстанны суверен дәүләт дип белдерде, үз территориясендә республика законнарының өстенлеге танылды. Җир, табигать хәзинәләре һәм башка ресурслар республикадагы күпмилләтле халыкның мөлкәте итеп беркетелде. Бу чара Татарстанда яшәүче милләтләрнең мәнфәгатьләренә тулсынча җавап бирә иде. Декларация республикада милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга китерде.

Парламент хәбәрчесе буларак, миңа депутатлар белән даими аралашып торырга, алар әзерләгән проектлар, кабул иткән законнар, карарлар турында әңгәмә корырга туры килде. 1990 нчы елларда депутатлар бүгенгеләрдән шактый активрак иде, дип саныйм. Без күп кенә очрашуларны редакциядә үткәрдек. Алар һич тә икеләнмичә билгеләнгән вакытка килеп җитәләр иде. Менә бу рәсемдә депутатлар **Рәшит Вәгыйзов** (хәзер пенсиядә), **Илшат Гафуров** (хәзер КФУ ректоры) һәм **Разил Вәлиев** (ул бүген дә Дәүләт Советы комитеты рәисе) **«Шәһри Казан»** редакциясендә минем эш бүлмәмдә очрашуга килгәч алынды».

***

«Республика районнары һәм шәһәрләре җитәкчеләре дә 1990 нчы елларда дәүләтчелегебезне ныгыту буенча журналистлар белән кулга-кул тотынып эшләделәр. Теге яки бу законның әлеге төбәккә ни-нәрсә бирүе турында сөйлиләр иде. Икенче рәсемдә дә Авиатөзелеш районы хакимияте башлыгы **Фоат Ибәтуллин** бистәләрне төзекләндерүнең әһәмиятен раслаучы дәлилләр китерә, мин диктофонга язып утырам».

***

«Быел Декларация кабул ителүнең үзенчәлекле бер бәйрәме, дөресрәге юбилее — 25 еллыгы. Декларация белән бергә Казан шәһәренең татар телендә чыгарылган беренче рщсми газетасы «Шәһри Казан» да үзенең 25 еллыгын билгеләп үтә. Ул да милли хәрәкәт, суверенлык дулкынында туды. Аны ныгытуда турыдан-туры катнашты. Бүген дә газета редакциясе шушы традицияне дәвам итә.

Милли газетаны оештыруда, формалаштыруда ул чорда Казан мэры булып эшләгән **Камил Исхаковны** аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Камил Шамил улы редакциягә килеп, коллектив белән сөйләшеп һәрнәрсәне үз күзе белән күрергә ярата иде. Бу фото Камил Исхаков Россия Президентының Ерак Көнчыгыш округында вәкаләтле вәкиле итеп билгеләнгәч, Казанга кайткан вакытында төшерелде.

Бәйрәмнәребез мөбарәк булсын!» ■

Салих, Вячеслав (өстә), Долория, Ольга Яковлева

Фото Фәрит Баттал архивыннан

БЕР «ЛӘКИН»...

Хөрмәтле редакция!

Журналыгызның быелгы июнь-июль санында (№ 6-7) Фәнзаман Батталның «Кадерлеләр һәм кадерсезләр» исемле мәкаләсен бастыргансыз. «Тарихта, архивларда казынырга ярату» һаман мактауга лаек, тулаем алганда мәкалә дә яхшы язылган кебек, әмма фактларга нигезләнмәгән искәрмәләр аның дәрәҗәсен беркадәр төшерә. 59 нчы биттән өзек китерик:

«Язучылар союзына килгән телеграммаларның берсе Приморскидагы Фроловкадан. «Срочно» диелгән һәм болай дәвам ителгән: «Телеграф аша ашыгыч рәвештә Яковлеваның Казандамы-түгелме икәнен минем адреска хәбәр итегез. Баталов». Исеме күрсәтелмичә, фамилиясе бер генә «т» белән язылган булса да, монысының кем икәнен чамалау кыен түгел. Ул, әлбәттә, горур һәм берчакта да вакланмаган, һәр җәһәттән кыю, башбирмәс Салих Баттал булырга тиеш!.. — Һәм, Баттал биографиясенең төп моментларын телгә алгач дәвам итә: — *Белгәнемчә, Салих Баттал дүрт мәртәбә өйләнеп, бер-бер артлы Мәрьям, Ольга, Кадрия, Мәдинә исемле хатыннар белән яшәгән. Башкаларын тагын кем белгән... Язучылар союзыннан менә шул Ольга дигәнен барлатмадымы икән?»*

«Башкалары»н белсәң, әйтергә, белмәсәң, шомлы нәтиҗәләргә урын калдырмаска иде. Хатыннарының исемнәреннән тыш, алар белән аерылышу сәбәпләрен дә белергә кирәктер, бәлки. Мәдинә апа белән Салих абый ахырга кадәр яшәгән.

Соңгы сорау да урынсыз, дияр идем. Телеграмма авторын җиңел билгеләп, аның булган хатыннарын тезеп чыга алгач, тагын нинди Ольга турында сүз барсын соң? Телеграмма Язучылар берлегенә җибәрелгән бит, шул елларда әгъза булган бердәнбер «Баталов»ның кем булуын анда, әлбәттә, яхшы белгәннәр. Телеграмма тулысынча китерелгән булса, һичшиксез, Яковлеваның да кем икәнлеге аңлашылыр иде. Салих абыйның бөтен текстлары (шулар арасында хатлар да) анык язылган, ә монда «үзсүзле түрә» стиле килеп чыккан.

Шулардан соң журнал укучыларның күбесе: «Салих Баттал дистәләп хатын белән торган икән. Архивларда казынган өлкән яшьтәге мөхтәрәм автор белеп язгандыр инде!» — димәсме?

Ихтирам белән,
Салих Батталның туганнан туганы
Фәрит Баттал

Рәсемдә: халык командасы дип йөртелгән «Спартак»! Уңда – аның капитаны Галимҗан Хөсәенов. 1969 ел

НӘНИ ГИГАНТ ГАЛИМҖАН

Атлас Гафиятов

Дөнья күләмендә беренче номерлы спорт булып футбол санала. Шулай да үз осталыклары белән стадионнарга һәм телевизор каршына меңнәрчә тамашачыларны җыйган футболчылар бармак белән генә санарлык. Дөнья күләмендә болар – Пеле, Марадона, Платини, Беккенбауер, Зидан... Безнең илдә исә Яшин, Стрельцов, Блохин, Дасаев... Милләттәшебез Галимҗан Хөсәенов та шундыйлар рәтенә керә.

Татарстанның Октябрь районындагы Яңа Иглай авылында туып, гаиләләре Самарага күчкәч, шундагы «Крылья Советов» командасында, аннан соң атаклы «Спартак»та (Мәскәү) 36 яшенә кадәр туп типкән Салих малае Галимҗанның спорт биографиясендә истә калырлык җиңүләре, соклану уята торган мизгелләре шактый. Буе 1 метр 64 сантиметр гына булуга карамастан (хәзер мондый буй белән икенче лига командасына да алмыйлар), ул 10 елдан артык данлыклы «Спартак»

командасының капитаны булган һәм СССР җыелма командасында 40тан артык уен үткәргән шәхес. Гадәттә, көндәшләре капкасына тупны баш белән бәреп озын буйлылар кертә. Ә менә Хөсәенов СССР кубогының ике финалында — 1965 һәм 1971 нче елларда командасына җиңү китергән хәлиткеч тупларны нәкъ менә башы белән бәреп кертә. Шуннан соң иптәшләре аны шаяртып «һава короле» дип йөртә башлыйлар.

Футбол уйнаучыларны командада сакчы, ярым сакчы һәм һөҗүмчеләргә бүләләр. Галимҗан исә тренер кая куя — шунда уйный: сакчы да, ярымсакчы да, уң як, сул як һәм үзәк һөҗүмче дә була. Ә инде ун ел буе атаклы «Спартак»ның капитаны вазифасын башкаруы аның гадел, таләпчән, иптәшләре арасында абруй казанган футболчы икәнлеге хакында сөйли.

СССР беренчелегендә 100 һәм аннан да күбрәк туп кертүчеләрне берләштерә торган «Григорий Федотов» дигән символик клуб бар. Менә шул исемлектә, ил җыелма командасында һәм кубок ярышларында керткәннәрен дә кушып, Г.Хөсәенов 142 туп белән сигезенче урынны алып тора. Янәшәсендә — Эдуард Стрельцов, Рамаз Шенгелия, Константин Бесков, Эдуард Маркаров кебек осталар. Танылган журналист, футбол белгече Лев Филатов үзенең «Форварды» дигән китабында милләттәшебезгә сокланып болай дип яза: «Хөсәенов күп голларын капка алдында торып түгел, ә еш кына капкадан уңда яисә сулда торып кертте. Ул көче белән түгел, ә күбрәк төгәллеге белән алдырды. Әмма тамашачылар аның гол кертүен түгел, ә голга ничек килүен күбрәк хәтерлиләр. Ул тупны көндәшенең аягыннан бик җиңел генә «каерып ала» да, үзенекенә «ябыштырып куя». Бу вакытта ул туктапып тормыйча алга ыргыла, кыска аяклары белән аңа каршы куелган бик күп аякларны сикереп үтә. Әгәр һөҗүм барып чыкмый икән, ул икенчесен башлый, аннан өченчесен... егерменчесен — шулай гол керткәнгә кадәр».

1966 елгы дөнья беренчелегендә Чили командасына каршы уенда икенче таймда, Михаил Воронинны алыштырып, көндәшләре капкасына гол керткән Хөсәенов турында әлеге ил газеталары: «Советларның яшерен коралы дөньяга чыкты!» — дип яздылар.

...Малай чакта без хәзергеләр кебек телевизор, интернет каршында утырмый идек, ә буш вакыт булуга туп тибә һәм кәшәкә суга идек. Шулай да телевизор аркылы Хөсәеновның берничә матчтагы уенын карарга туры килде. Миңа атаклы милләттәшебезнең ветераннар командасында уйнавын якыннан күзәтергә һәм бер елны Мәскәү Сабан туена баргач, үзен дә күреп сөйләшү мөмкинлеге эләкте.

1986 елның җәендә Чистайда үткән «Авыл егетләре» дип аталган ярышлар тәмамлангач, стадионга җирле футболчылар һәм «Спартак»ның ветераннары чыкты. Алар арасында Хөсәенов та бар иде. Шунда «Восток» сәгать заводы стадионына җыелган тамашачылар атаклы уенчыларның 45-50гә җиткәч тә туп белән ювелирларча оста идарә итүләренә сокланып утырдылар. Гадәттә мондый иптәшләрчә матчлар ничьяга тәмамлана. Әмма бу уенда 1:0 исәбе

«Ул тупны көндәшенең аягыннан бик җиңел генә «каерып ала» да, үзенекенә «ябыштырып куя». Бу вакытта ул тукталып тормыйча алга ыргыла, кыска аяклары белән аңа каршы куелган бик күп аякларны сикереп үтә. Әгәр һөҗүм барып чыкмый икән, ул икенчесен башлый, аннан өченчесен... егерменчесен – шулай гол керткәнгә кадәр».

белән «Спартак» ветераннары яшьләрне җиңде. Тупны Хөсәенов биргән пас белән Георгий Ярцев кертте.

Мәскәү Сабан туен, ягъни Измайлово паркында үткән милли бәйрәмебезне моннан егерме еллар чамасы элек атаклы футболчы белән янәшә утырып карадык. Ул милли көрәшне, уеннарны бик игътибар белән күзәтеп, кызыксынып карап утырды. Минем сорауларга да бер-ике сүз белән тыйнак кына җавап кайтарды (әйе, гадәттә күп эшләүчеләр аз сүзле булалар). Мин: «Ничек яшисез, хәзерге тормышыгыздан канәгатьме?» — дип сорагач, бер сүз белән: «Нормально», — дип кенә әйтте. Шулай дисә дә, заманында ил даны өчен шактый сәламәтлеген биргән спорт ветераннарының күбесенең хәлләре бик үк шәп булмавын белеп, күреп торабыз. Соңыннан аны белүче мәскәүлеләр Хөсәеновның хатыны белән гап-гади ике бүлмәле фатирда яшәп ятуын әйттеләр. Бердәнбер кызлары балконнан егылып төшеп үлгәч, Галимҗан абыйның үзенең дә депрессиягә бирелеп урын өстенә егылуы, берничә тапкыр «Спартак» клубы ярдәме белән Германиядә дәваланып кайтуы билгеле.

2007 елның 27 июнендә татар футболчыларыннан беренче булып СССРның атказанган спорт остасы исемен алган, 5 тапкыр ил чемпионы, 4 тапкыр ил кубогы хуҗасы, 1966 елда дөнья беренчелегеннән бронза медальләр алып кайткан командада уйнаган милләттәшебезгә 70 яшь тулды. Аны барлык укучыларыбыз, футбол сөючеләр исеменнән тәбрикләп «Татарстан яшьләре» газетасында күләмле язма да бастырган идем.

Ни кызганыч, 2010 елның 5 февралендә танылган милләттәшебез бакыйлыкка күчте. Никадәр авыр булса да, бу хакта да «Татарстан яшьләре» газетасында язып чыгарга туры килде. Ә «Комсомольская правда» үзенең мәрсиясен (некрологын) «Легенда китте» дип исемләгән иде... Әйе, мондый легендар шәхесебез йөз елга бер генә туа.

Футбол мәйданында дан казанган татар егетләре аз түгел. Ренат Дасаев, Вәгыйз Һидиятуллин, Руслан Нигъмәтуллин, Алмир Каюмов, Динияр Билалетдинов, Марат Измайлов, Эльмир Нәбиуллин, Ленар Гыйльмуллин, Руслан Мөхәммәтшин исемнәре дә тамашачыларга яхшы таныш. Ә менә Галимҗан Хөсәенов күп кенә күрсәткечләре белән алардан өстен тора. Ул — шундый зур үрләр яулаган, тамашачылар ихтирамына ирешкән татар футболчыларының беренчесе. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның август ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Садыйк мелланың казый булу ихтималы

Сафа мәхдүмнең мөфтилеккә тәгаен ителүе мөнәсәбәте белән казанлы Садыйк мелла Иманколый Сафа мәхдүмгә тәбрик телеграмы җибәргән вә каршысына «Мөфти Баязитов» имзалы тәшәккер телеграмы алган. Казан имамнары даирәсендә сөйләнгән хәбәрләргә күрә, моның асылы түбәндәге вакыйгадан гыйбарәт икән: Садыйк мелла Петроградка барганда Сафа мелла аңар: «Мин мөфти булачакмын, шуннан соң сине казыйлыкка чакырырмын», — мәфһүмендә [эчтәлегендә] вәгъдә биргән икән. Сафа мелланың мөфтилеккә тәгаен ителүе белән хәзер инде Садыйк мелланың казыйлыкка чакырылачагы мөгайин имеш. Садыйк мелла Петроградтан кайтканнан бирле Сафа мелланың кандидатурасына муаффәкыятьсез [уңышсыз] сурәттә өндәп йөри торган булган.

Сугыш җиреннән качканнарга

Ошбу августның 3ендә Казан губернасының һәммә авылларында сугыш җиреннән качканнар файдасына яңа арыштан иганә җыюлар ясарга уйлана икән. Бу иганә яңа ашлыктан берәр чүмеч җыелачак һәм җыелган арыш амбарларга салынып, сугыш җиреннән качканнарга ярдәм өчен сарыф ителәчәк. Сугыш җиреннән качканнардан байтак гаиләләр Казанга киләләр. 2 нче август көнендә бер поездда гына 16 гаилә Казанга килгән.

Кояш. — 1915. — №675. — 5 август.

Мәдрәсәи «Мәрҗания» идарәсеннән

Киләчәк 1915-1916 нчы уку елында мәдрәсәи «Мәрҗания»нең ибтидаи кыйсеме августның 19ында чәһәршәмбе көн ачылып нәһари [көндезге] һәм кичке сыйныфларга шәкертләр кабул ителеп дәресләр башланадыр.

Рөшди вә игъдади[1] сыйныфларында сентябрь башыннан кабул башланып 15ендә дүшәмбе көн дәресләр башланачактыр. Мәдрәсәгә керер өчен паспортлы булмак, мәдрәсәнең һәрбер канун вә низамнарын кабул итмәк тиеш буладыр. Һәм югары табәка [катлау] өчен җиде тәңкә, түбән табәка өчен биш тәңкә дөхулия[2] алынадыр.

Кояш. — 1915. — №768. — 9 август.

[1] Игъдадия — мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү сыйныфлары.
[2] Дөхулия — берәр җиргә керү өчен алына торган хак.

Мандолина өчен нота мөгаллиме

Байтактан бирле көйләребезне нотага салып килмәктә вә боларны нәшер итмәктә булган Гыйләҗетдин әфәнде Сәйфуллин тарафыннан ошбу исемдә нәшер ителгән 2 нче җөзә [кисәк] рисалә [җыентык] идарәбезгә тапшырылды. Бу нота мөгаллименең икенче җөзә беренче җөзәнең дәвамы буларак, яңа көйләр тезмәсе итеп нәшер ителмештер. Бу җөзә баштанаяк рәкым ысулы белән (цифрлы системада) ясалган. Мөрәттиб [төзүче] вә нашир әфәнде көйләргә якыннан таныш кеше булганлыктан көйләрнең дөрес язылуына (нотага салынуына) дикъкать иткән. Рисаләдә түбәндәге көйләрнең ноталары бар: «Сакмар суы», «Ашказар», «Сүнде дәрт», «Җамал көе», «Әй-ли чияме», «Зиләйлүк», «Берсе алма, берсе хөрмә», «Галиябану», «Мәрьям туташ», «Беренче сада (марш)», «Нарасый бала», «Байкал күле», «Татарский полк».

Кояш. — 1915. — №777. — 19 август.

Концерт

21 августта Новый клуб залында Фәттах Латыйпов вә Сатирә ханым Әхмәдиева тарафыннан концерт бирелде. Концертның программасы бик муаффәкыятьсез сайланган: үз көйләрен яхшылап аңларлык рәвештә музыка тәрбиясенә ия булмаган безнең халыкка әллә нинди сарт вә азәрбәйҗан көйләре тәкъдим кыла, бигрәк тә алардан эчпошыргыч тәрәкъкыйпәрвәр сүзлеләрен санлау һәр җәһәттән килешсез вә мәгънәсез бер хәрәкәт, дип уйлыйбыз. Шулай да Фәттах әфәнде Мотыйгыйга[3] караганда бик оста. Бу көйләр концертларның бөтенлегенә аннан көтелгән тәэсиргә бик күп зарар иттеләр.

Бу ел Фәттах Латыйповның шактый тәрәкъкый итүе сизелә. Озын көйләр, аның былтыргы калтыратуыннан, төрле мөгезләр чыгаруыннан бөтенләй үк азат була алмасалар да, шактый шомарып чыга башлаганнар. Шулай да озын көйләрне көйләвендә аның күп кимчелекләре бар әле. Ләкин кыска көйләр алай түгел. Фәттах Латыйпов кыска көйләрне яхшы җырлый. Сатирә ханымның Казанда беренче чыгышы әле. Аның тавышы саф булса да, сәхнәгә чыгып җырлар өчен кечкенә. Ул җырлаганда аңар бераз тавыш өстисе килә. Дуэтлардан «Галиябану» белән «Сүнде дәрт», аеруча «Галиябану» бик шәп чыкты. «Былбылым» белән «Сызла күңелем»не Фәттах Латыйпов үзе аксатты. Бу мөнәсәбәт белән, каты кайгы тулы көйләрне көйләү өчен Фәттах Латыйповта рухани хәрәкәт җитми торгандыр ахры, дигән фикер башка килә. Аның мондый хәсрәткә күмелгән озын татар көйләрен җырлавындагы кимчелеге дә, алар өчен тавышының эшләнеп җитмәвеннән башка, рухани хәрәкәт азлыгыннан аларның хәсрәтләренә бирелеп җитә алмавыннан булуы бик ихтимал. Шулай да Латыйпов әфәнденең тавышы кечрәк булуга да карамыйча, Мотыйгыйга караганда күп өстенлеген икърар итми мөмкин түгелдер. Концертта халык җәйге сезон өчен күп иде. Икесе дә алкышландылар. З.Н.

Кояш. — 1915. — №782. — 25 август.

[3] Мотыйгый — Камил Мотыйгый.



КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

Туфан МИҢНУЛЛИН

РОБАГЫЙЛАР

Карап торам. Карап-карап туймый торам,
Соклануудан сүз кушарга кыймый торам.
Язмыш сине көнче ирдән саклый күрсен —
Матурлыгың көн дә тотып кыйный торган.

«Ак» белән «кара» кавышса, мулат туа,
Тешле-тешле кәкре тимер урак була.
Бүтәннәрне җүләр, диеп уйлаучылар
Асылында натуральный дурак була.

Күк капусы ачылганны күрмәдең шул,
Алтын чөйгә затлы туның элмәдең шул:
Нәчәльнигең тозсыз мәзәк сөйләгәндә,
Эчләреңне уа-уа көлмәдең шул.

Яши-яши киттем инде картаеп та,
Ара-тирә мәс тә булдым һәм аек та...
Шуны белдем: әдәбият дөньясында
Бүре, кәҗә һәм кәбестә бер каекта.

Ишегеңне ача идек дер калтырап, —
Телең белән ташлый идең безне турап.
Бүген нишләп кул сузып елмаясың?
Безнең янга төштең мәллә? Нихәл, бырат?

Мичкә — пүлән, самавырга шакмак кирәк,
Бии-бии җырлар өчен такмак кирәк.
Албастылар, җен-пәриләр туй иткәндә
Афәрин, дип хуплар өчен ахмак кирәк.

МИНИ-ХИКӘЯЛӘР

Филологик хикәя

Башкорт теленең Бишбалта диалектында сөйләшүче галим Сәйәргол Бәйрәмголовның кызы Альбина татар теленең Бөрьян диалектында сөйләшүче галим Мөхәммәтҗан Әхмәтҗановның улы Альберт белән очрашты.

— Ты меня любишь? — дип сорады кыз үз телендә.

— Я тебя очень люблю, — дип җавап бирде егет үз телендә.

Психологик хикәя

Түбән оч Зиннәт сугыштан кайтты. Күрше хатыны Зәйнәп аның хәлен белергә керде. Сугыш турында, сугышка Зиннәт белән бергә киткән ире турында сорашты. Зиннәт үзе бик аз сүзле кеше булганга, аның өчен күбрәк хатыны Мәфтуха сөйләде.

Зәйнәп Зиннәтләрдән чыгып барганда, аңа икенче бер күрше хатыны очрады.

— Ничек соң, Зиннәт ниләр сөйләде? — дип сорады.

— Зиннәт түгел, Мәфтухасы кайткан сугыштан, ул бөтенесен сөйләп бирде, — диде.

Хәрби хикәя

— Шушында гына булырга тиеш, — диде армия генералы.

— Тегендә булуы да ихтимал, — диде генерал-полковник.

«Армияне әзерлектә тотарга», дигән фәрман бирелде. Йөз мең офицер һәм солдат, бронетранспортёрларга төялеп, һөҗүмгә күчте. Аларга самолётлар һәм вертолётлар кушылды. Туплар залпы яңгырады, миналар шартлады, ядрәләр чәчелде. Фәрман арты фәрман бирелде.

Операция уңышлы үтте. Ниһаять, тотыласы кешене тоттылар. Аның буе 1 метр да 50 сантиметр, авырлыгы 48 кило ярым иде.

Нияз Хаҗиәхмәт шаржы. 1996 ел

Әдәби хикәя

Язучы Әпкәлиевне Тукай премиясенә тәкъдим иткәннәр иде, бирмәделәр.

— Җыен әтрәк-әләмнәргә бирәләр Тукай премиясен. Ул премиягә лаеклар читтә кала, уртакуллар лауреат булып йөри. Премия өләшүчеләр талымлырак булсыннар иде, — дип сүгенеп йөрде Әпкәлиев.

Икенче тапкыр тәкъдим ителгәч, премия Әпкәлиевкә дә эләкте. Аны алгач, яңа лауреат:

— Премиянең дәрәҗәсен төшермәскә кирәк, иптәшләр! Һәрбер кешегә Тукай премиясе өләшергә димәгән. Вакламыйк Тукайны, — дип сөйләнеп йөрде.

ИСКЕПЕРИМЕНТ

12 юллык шигырь

Абыйлардан калган чалбар күптән тузды,
Сакал диеп төкләр кырган чаклар узды,
Бала-чага «әти» диеп кулын сузды,
Яшь гомерләр әкрен генә үтә имди.
Бер шайтаны хатын иткән минем кызны,
Оныкм көтеп йөрер заман җитә имди.
Әмма ләкин азгын күңел тызды-бызды —
Кичә генә бер матурга нәфсен сузды,
Кыз елмаеп карады да… аннан сызды.
Гәрәй Рәхим кешни-кешни көләр имди.
Бу юлларны Тмин дигән шагыйрь язды.
Р.Миңнуллин көнләшүдән үләр имди.

КОТЛАУЛАР

Бурсык авылында яшәүче алдынгы карашлы, берничә яшь буынны тәрбияләгән укытучы, яраткан бабаебыз Колсәетов Гыйбадулла Колахмәт улына 80 яшь тула. Кадерле бабаебыз, Сине олы юбилееӊ белән котлыйбыз. Киләчәктә дә үрнәк татар гаиләсенеӊ куанычы булып яшә.

Улыӊ Фердинант, киленеӊ Гертруда, оныкларыӊ Эрик, Варвара, Лимузин.

Дустыбыз Гөрлия! Кияүгә чыгып, башлы-күзле булуыӊ белән котлыйбыз. Бәхет телибез. Исән-сау гына әйләнеп кайтырга язсын. Привет Вадиму.

Дусларыӊ.

Любимый внучек Рубчик! Желаем тебе агромного счастья. Мы надиемся, что ты будешь дастуйным прадалжателем нашего замичательного рода.

Твой дедушка Солимгарай и бабушка Хуббуниса.

ТҮРӘЛӘРГӘ

……………………………………………………
Барысы да мактый мине түрәләрнеӊ.
Бәхәсләшмим, кемлегемне беләләрдер.
Мин шулчаклы даһи булгач, нигә инде
Фатирларны миннән башка бүләләрдер?
……………………………………………………

Мирасворд

Галимҗан … (дин галиме, педагог)

Борынгы «комбайн»

Биш вакыт намазның өченчесе

… юлны якын итеп

Сугыш атын ярaланудан саклау дирбиясе

Театраль бию сәнгате

Ги … Мопассан

Хан фәрманы

Тамыры эфир маена бай тропик үлән

Элек укучыга куелган иң начар билге

Зур ашлык савыты.

… Урда

Чигү чиккәндә тукыманы тарттырып куя торган рам

Сальвадор … (испан рәссамы)

1913-1914 елларда Казанда чыккан педагогик журнал

Урта Азия халыкларында шагыйрь-импровизатор, җырчы

Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога

Бензин маркасы.

Сәетгәрәй, Ильяс

Кара тактага язу әсбабы

Таләпләргә җавап бирерлек

Алтын Урда ханы

Өй, бина (иск.)

Борынгы Кытай патшалыгы

Арча районындагы авыл

Мезозой эрасының иң беренче чоры

Рус әдибе

Урта гасырларда яшәгән төрки телле халык

Математик гамәл

Мәҗит…

Шигырь үлчәве, ритм (иск.)

Реформа (иск.)

Кытай тормасы

Җырчылар төркеме

Тарих, география.

Киҗемамык тукыма

Халыкара ясалма тел

Каен кайрысы

Әйткән сүз — аткан …

«… хокукы» китабы (Г.Морат)

Ут рәвешендә йөри торган рух

… Бәһман

«… - дза — дза!» фильмы

Рәис Габдулла төзеде.

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Гамбәр, Сөббух, Ык, бүре, чуман, Кол, Икария, Иво, округ, гәп, Суоми, ярен, архар, «Нур», би, го, Еники, Галиев, Зәйни, Әсма, Лоа, туар, нун, яр.

Өстән аска: бензин, Бикчурин, най, «Гасыр», Ромашкино, өке, Рики, илд, кяр, Хо, Бабич, уна, «Улигер», Рәхимов, Әлмәт, Акопян, сур, егу, мая, «Шөгеровлар».

Казан. 1990 елның 30 августы. Алгы планда – шагыйрь Мәхмүт Хөсәен

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / август

190 ел элек (1825)

Шагыйрь, мөдәррис Шәмсетдин Зәки (1825-1865) дөньяга килә.

130 ел элек (1885)

1 августта татар театрына нигез салучыларның берсе, актёр, Хезмәт Батыры Нури Сакаев (1885-1927) дөньяга килә.

95 ел элек (1920)

Әгерҗе шәһәрендә Шамил Усманов хөрмәтенә клуб ачыла.

85 ел элек (1930)

12 августта язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев (1888-1930) вафат була.

75 ел элек (1940)

Фатих Әмирханның тууына 55, үлүенә 15 ел тулуны билгеләп үтүне оештыру өчен Татарстан Язучылар союзы каршында Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт, Фәтхи Бурнаш, Хәсән Хәйри һәм Зәйни Солтановлар составында мирас комиссиясе төзелә.

СССР Халык Комиссарлары Советы рөхсәте белән сәнгать эшләре комитеты 1941 елның ахырында Мәскәүдә татар сәнгате декадасын үткәрү хакында карар чыгара.

50 ел элек (1965)

Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Риза Ишморат һәм Мөхәммәт Садри Казан шәһәр Советының архитектура бүлегендә Муса Җәлилгә ачылачак һәйкәл проекты белән таныша, фикер алыша.

45 ел элек (1970)

Памир тавындагы бер пикка Муса Җәлил исеме бирелә.

25 ел элек (1990)

30 августта Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителә.





Сара ханым улы Илдар белән.
Киндер, майлы буяу. 1937

БАКЫЙ УРМАНЧЕ

Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә Казан губернасының Тәтеш өязе Кул-Черкен авылында туа. 1907-1914 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем эсти. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында армиягә алына: Казакъстанга эләгеп, андагы Австрия әсирләреннән рәсем сәнгатеннән беренче дәресләр ала. 1919-1920 елларда Казандагы сәнгать училищесында укый. Бакый Урманче — татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучы, рәссам, график, скульптор һәм архитектор, Татарстанның һәм Русиянең халык рәссамы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

1990 елда вафат була.

«Сепаратор янында».
Киндер, майлы буяу. 1927

«Салтык болыны».
Киндер, темпера. 1979

АЛДАГЫ САННАРДА:

«Без азык-төлеккә мохтаҗ идек. Бер утарда запас хром итекләрне ярты сынык икмәккә һәм ун данә йомыркага алыштырдык. Совет акчасына азык-төлек юнәтү мөмкин хәл түгел, беркем берни дә бирми, кием-салымыңны, итегеңне сорыйлар, безне, солдатларны, бер-туктаусыз артка чигенгән өчен ачуланалар...»
ГОБӘЙДУЛЛА САЛИХОВ. «ТОРМЫШ ЮЛЫМ»

«Борынгы заманда бер падишаһ бар иде. Табигате белән төшенке күңелле, кызу канлы иде, әшәкелек-дуңгызлыкта тиңе юк иде, һаман саен халыкны рәнҗетер иде. Халык-тан ишеткән сүзне хәтерендә саклады, алдагы көндә шуны дәлил итәр иде, «фәлән вакыт шулай димәдеңме?» дип хөкем итәр иде. Шуңа күрә, аның янында булган кеше артыгын сөйләмәс иде».
«КАЙГЫСЫЗ ПАДИШАҺ ҺӘМ КАЙГЫЛЫ ВӘЗИР ТУРЫНДА ХИКӘЯТ»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 19 һәм 29/11) кибетләреннән сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172